ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

**Илгиз Кадыйров**

# МОҢ ДӨНЬЯСЫНА СӘЯХӘТ

*Экспедицияләр көндәлеге*

Казан
2025

**УДК 392.5**
**ББК 82.3(2=632.3)**
**К 13**

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*Гыйльми советы тәкъдиме белән басыла*

*«Татар халкының милли үзенчәлеген саклау»*
*Татарстан Республикасы дәүләт программасы кысаларында*
*әзерләнде һәм нәшер ителә*

Китапта *И.Ш. Кадыйров* һәм *Д.Н. Арсланова*
төшергән ноталар файдаланылды

Ноталарны компьютерда җыючылар:
*Д.Н. Арсланова, Н.Х. Нургаянова*

**Рецензентлар:**
Н.Х. Нургаянова, И.Г. Гомәров

**Кадыйров И.Ш.**
**К 13** **Моң дөньясына сәяхәт:** экспедицияләр көндәлеге / төз.: И.Г. Закирова, Г.Г. Гыйлемҗанова; И.Г. Закирова ред. – Казан, 2025. – 256 б.
ISBN 978-5-93091-518-1

Бу китапта 1968–1977 елларда Төмән, Томск, Омск, Новосибирск һәм Кемерово өлкәләренә оештырылган фәнни экспедицияләр вакытында татар музыкасы һәм фольклоры белгече Илгиз Кадыйров алып барган көндәлекләр һәм шушы өлкәләргә кергән 49 татар авылында яшәгән милләттәшләребезнең халык җырлары тәкъдим ителә. И. Ш. Кадыйров язып алган скрипка сарыннары китапта татар халкының уникаль инструменталь музыка мирасы үрнәге буларак урын алды. Максатыбыз – бу җырларны яңадан халыкка кайтару, милли моңга яңа сулыш өрү, яшьләрдә мәдәниятебезгә мәхәббәт, хөрмәт тәрбияләү.

Этнографик картиналар, информантлар турында мәгълүмат, экспедиция вакытында булган вакыйгалар турындагы язмалар аеруча кызыклы.

Басма фольклор һәм музыка белгечләренә, югары һәм урта уку йортлары укытучыларына һәм укучыларына, халык җырлары белән кызыксынучыларга адреслана.

**ISBN 978-5-93091-518-1**

© ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты, 2025
© Кадыйров И.Ш., 2025

*Чордашым, хезмәттәш дустым,*
*олпат галим, фольклорчы*
*Фатих Ибраһим улы Урманчеевның*
*якты истәлегенә багышлыйм.*

## СҮЗ БАШЫ


Чын асылы һәм кыйммәте ерактан торып кына бәяләнә торган күренешләр була. Алар бездән ерагайган саен, масштаблары ачыла гына бара. Халкыбызның мәдәни байлыгы, шул исәптән фольклоры, бигрәк тә музыкаль мирасы белән дә шулай. Сезнең кулларда халык музыкасы белгече Илгиз Кадыйровның Себернең Төмән, Новосибирск, Омск, Томск һәм Кемерово өлкәләрендә милләттәшләребез яшәгән авыллар буйлап узган экспедиция көндәлекләрен һәм галимнең шундагы табышларын колачлаган басма. Анда истәлекләр, мемуарлар, ярты гасырдан да элегрәк яшәгән әби-бабаларыбызның тере тавышы… Еллар узган саен кыйммәте арта гына бара торган рухи мирас.

Әлеге китапны чыгару идеясе Илгиз Кадыйровның күпсанлы фәнни экспедицияләрдә туплаган материаллары нигезендә «Татар халкының туй җырлары. Себер ареалы» һәм «Татар халкының музыкаль-эпик иҗаты. Себер ареалы» дигән җыентыкларны әзерләү барышында туды.

Илгиз Кадыйров, татар фольклорын җыйганда, халык тормышының әһәмиятле якларын – көнкүрешен, йола-традицияләрен дә игътибарсыз калдырмый. Экспедиция көндәлекләрендә белгечнең күзәтүләре, авыллар тарихы, риваять-легенда үрнәкләре, халык йолалары, информантлар, музыкаль инструментлар турында мәгълүмат та теркәлә барган. Шулай ук мәкаль-әйтемнәр, диалекталь сүзләр, информантларның сөйләм үзенчәлекләре дә фольклорчының игътибарыннан читтә калмаган. Шунда ук Себер татарларының ризык культурасы белән дә танышырга мөмкин.

Китапта информантлар турында мәгълүмат белән беррәттән, иң матур һәм яңалык булырдай үрнәкләрнең аудиоязмалары бирелә. Бу язмаларны QR-кодлар аша кереп тыңларга мөмкин. Әлеге басма Илгиз Кадыйров туплаган материаллардан төзелгән өченче китап булу сәбәпле, кабатлаулардан качу өчен, барлык җырларның да сүзләре һәм ноталары тулысынча бирелми. Ярты гасырдан артык вакыт узу сәбәпле, кайбер аудиоязмаларның сыйфаты югалган. Аудиовариантлар сакланмаган очраклар да бар. Аларның Илгиз Кадыйров тарафыннан кәгазьгә төшерелгән сүзләрен һәм ноталарын бирергә тырыштык. Бер үк җырның дистәләгән вариантлары бар. Бу очракта иң уникаль тавышлы җырчыларга яки көйнең иң уңышлы вариантларына өстенлек бирелде.

Аудиоязмаларда ярты гасырдан артык архивта саклanган җыр-моңнар җанлана. Җырчыларның тере тавышын ишетү



Экспедиция көндәлеге битләре

укучыны шул чорга алып кайта. Язмаларда Себердә яшәгән милләттәшләребезнең моң дәрьясы, җырлаучының тембры, башкару манерасы ачыла. Язмалар шул чор атмосферасын саклый. Бу – ясалма рәвештә барлыкка китерелгән, реставрацияләнгән көйләр түгел, ә ярты гасыр элеккеге чынбарлык. Шуның белән алар уникаль һәм кадерле дә.

Җырлар һәм скрипка көйләре белән танышканнан соң, халыкның башкару традицияләренең никадәр күптөрле булуын, еллар узу белән аларның ни рәвешле үзгәрүен дә күрәбез. Бу халык музыкасын өйрәнүчеләрне уйланырга һәм традицион сәнгатьтәге процессларга яңача карарга мәҗбүр итәр.

Язмалар – галимнәргә киләчәктә халык көйләрен өйрәнү өчен материал гына түгел, ә башкаручылар өчен кыйммәтле чыганак та. Татар музыка сәнгатенең иң күркәм үрнәкләрен сәхнәгә чыгару халыкның, бигрәк тә яшьләрнең зәвыгын тәрбияләп кенә калмас, яңа иҗат өчен дә өлге булыр дип өметләнәбез. Бу – чит илләрдән кергән, чит мәдәнияткә хас юнәлешләргә альтернатива булырлык мирас. Шул ук вакытта әлеге хезмәт фольклорчы һәм сәнгатьче галимнәр өчен дә гаҗәеп бай рухи хәзинәбезне барлап, яңадан халыкка кайтаруда бер этәргеч



И. Кадыйровның эш дәфтәреннән

булыр, аларны яңа фәнни эзләнүләргә рухландырыр дип уйлыйбыз.

Китапта татар халкының инструменталь музыка үрнәкләре – скрипка көйләре, ягъни скрипка сарыннары да урын алды. Татар халкының инструменталь музыка үрнәкләре әлегә кадәр аз өйрәнелгән. Бу китапта аларның аудиоязмалары һәм берничә көйнең ноталары да тәкъдим ителә. Скрипка сарыннарын музыка белгече Дания Арсланова нотага төшерде.

Хезмәттә тугыз экспедициянең дә материаллары тулысынча бирелми. Чөнки соңгы өч экспедиция материалларының аудиоязмалары әлегә табылмады. Киләчәктә бу материаллар ачыкланып, китапның икенче басмасы да дөнья күрер дип өметләнәбез.

Әлбәттә, көндәлек язмаларын да кыскартып, кабатлаулардан арындырып бирдек. Кайбер очракларда мәгънәне, эзлеклелекне торгызу өчен шактый эзләнергә туры килде. Географик атамалар, информантларның исем-фамилияәре, ялгызлык исемнәрне бирүдә автор транскрипциясен сакларга тырыштык.

Себердә татар авылларының рәсми кабул ителгән татарча атамалары юк. Бер үк авыл берничә төрле аталып, аның өчәрдүртәр татарча исеме булырга мөмкин. Текстларда очраган төрлелектән китәргә омтылсак та, экспедиция маршрутын билгеләгәндә, һәр авылның берничә исеме булуы да искәртелә.

Китап музыка сөючеләргә дә, галимнәргә дә файдалы булыр, Себердә яшәүче милләттәшләрбезгә дә барып ирешер һәм җырлаучыларның тере тавышларын аларның балалары, оныклары ишетер, дигән өметтә калабыз.

*Илсөяр Закирова,*
*Гөлназ Гыйлемҗанова*

# БЕРЕНЧЕ ЭКСПЕДИЦИЯ

## ОМСК ӨЛКӘСЕ
*(1968 елның 26 июне – 14 июле)*

## Ишем Тамак (Усть-Ишим) районы

### *Зур Тибенде авылы*

Бүген 2023 елның 26 июне. Моннан нәкъ тә 55 ел элек бу көнне без Фатих Урманчеев белән Омск өлкәсе Ишем Тамак (русча Усть-Ишим) районы Зур Тибенде авылына килеп төштек. Менә ике ел рәттән Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты Себер татарлары фольклорын өйрәнү буенча фәнни кыр экспедицияләре оештыра. 1967 елда Новосибирск өлкәсендә булганнар. Ә быел фольклор һәм сәнгать секторы фәнни хезмәткәрләре, халык



Зур Тибенде авылы. 1968 ел

хәзинәсе эзләп, Омск өлкәсендәге татар авылларына юл тоттылар.

Себер татарларының музыкаль фольклор үрнәкләрен беренче булып шагыйрь Мөхәммәт Садри җыеп алып кайта. Ул 1940 елда Көнбатыш Себергә оештырылган фәнни экспедиция вакытында фонограф валикларына Омск һәм Новосибирск өлкәләрендә яшәүче татарлардан күпсанлы җырлар һәм көйләр язып ала (кызганычка каршы, бу язмалар әлегә кадәр табылмаган). Соңрак композитор А.С. Ключарев бу язмаларны нотага төшерә һәм кырыктан артык җыр-көйне «Татар халык көйләре» җыентыгына туплый (Казан, 1955 ел).

Себер татарларының берничә җырын киң җәмәгатьчелеккә композитор Җәүдәт Фәйзи алып чыкты («Халык җәүһәрләре», 1971 ел).

Зур Тибенде авылы Иртеш елгасы буена урнашкан. Авылның гомуми күренеше гаять матур. Елга яры буйлап гәрәбәдәй сары нарат бүрәнәләрдән салынган алты почмаклы йортлар тезелеп киткән. Иртешнең аргы ягындагы күренеш аеруча гүзәл. Кичке уеннар тирәсендә тирә-якны шаулатып гудок тавышы яңгырый. Бу – көн саен үтеп китә торган су трамвае үзенең якынлашуы турында хәбәр итә. Авыл халкы су буена трамвай каршыларга җыела. Бирегә кешеләр үз туганнарын һәм якыннарын каршылау яки озату өчен генә төшмиләр. Бу үзенә бер матур традициягә әйләнеп, күренешнең исеме дә халыкта «Трамвай каршылау» дип атала. Бу – очрашу, яңалыклар белешү, күрешү урыны да. Авыл клубындагы чаралар да трамвай килеп киткәннән соң гына башлана.

Килүебезнең максатлары белән таныштыру, гомумән, авыл халкы белән очрашып сөйләшү өчен, кичен клубта «Татар халык җырлары» дигән темага лекция-концерт куярга булдык.

Клубка бардык. Безне Роза исемле завклуб каршылады. «Кич лекция-концерт куябыз, белдерү язып элегез», – дип

әйттек тә тиз генә китеп бардык. Бераздан әйләнеп килдек, белдерү һаман юк. «Абыйлар, мин белдерүнең нәрсә икәнен белмим», – дип тора бит безнең Розабыз!

Кичен клуб халык белән шыгрым тулы иде. Фатих трибуна артына басып сөйләп тора, мин баянда сыздырып уйнап торам. Клубта бик эссе, икебез дә шыбыр су булдык...

Кичәбез бик күңелле узды. Биредәге халыкның мондый чараларга сусаганлыгын күрдек. Безне сәхнәдән төшерәселәре килми. Кичәне дәвам итеп, соңыннан баян белән күмәк җырлаштык, бию кичәсе булды.

Беренче көнне үк без Зур Тибенде авылының көй-моң, бай халык иҗаты хәзинәсе дөньясына кереп чумдык. Иң беренче җырчыбыз **Абитов Биктимер абый** (1919 елгы) шушы Зур Тибенде авылында туган. Әтисе Мәлик бабай тирә-якта дан тоткан җырчы булган. Тубыл, Тара һәм башка шәһәрләргә ямщик булып йөргән, бәхет эзләп, күп җирләр гизгән, моң-зарларын үзенең җырларына сеңдереп барган. Безне таң калдырганы тагын шул булды: Мәлик бабай үлем түшәгендә ятканда да, улын янына утыртып, җырларын өйрәткән. Менә кайда музыкаль традициянең көче, менә кайда саекмас чишмәләр! Бу бит бер хикәя өчен әзер сюжет!



Абитов Биктимер.
Зур Тибенде авылы. 1968 ел

Биктимер абыйның үз тормыш юлы кызыклы да, катлаулы да. Ул Бөек Ватан сугышында пулемётчы һәм разведчик булган, офицер дәрәҗәсенә күтәрелгән. Авылда

яши. Музыкага булган ихтирам аның балаларына да күчә бара. Улы Төхфәт – тирә-якта иң оста баянчыларның берсе, тракторчы. Үзешчән сәнгатьтә актив катнаша.

Биктимер абыйның татар халкының борынгы көйләрен дә, хәзерге заман җырларын да белүенә соклandык. Безне алда татар музыкасы белән бәйле яңа ачышлар – әлегә кадәр билгеле булмаган көйләр, җырлар көткән икән. «Җиктем күк юрга», «Ямщиккәй», «Иске пасхуд» («Иске болын»), «Сәвә» (хатын-кыз исеме), «Уракчы», «Милай Мәхмүзә», «Исәт» һ. б.ның көйләре гаять үзенчәлекле булулары белән безгә таныш көйләрдән аерылып тора.

***Җиктем күк юрга***

*Җиктем күк юрга, тимерле чана,*
*Исән-сау булың, туганнарым, күп елга,*
*Исән-сау булың, туганнарым, күп елга.*
*Алыплар бирим, сылуым, ак сабын,*
*Иртән сагынмасаң, кич сагын.*

*Түгәрәк, ай, тояк, җилгер лә тайларда,*
*Алтыннар йөсек Касанна байларда.*
*Алыплар бирим, сылуым, ак сабын,*
*Иртән сагынмасаң, кич сагын.*

*Сары аткаем, саслар буентай,*
*Җис камутлары аның муйнындай,*
*Җис камутлары аның ла муйнындай.*
*Егеткәй кая? Кыслар куенындай,*
*Кыс беләкләре егетләр муйнындай.*
*Алыплар бирим, сылуым, ак сабын,*
*Иртән сагынмасаң, кич сагын.*

*Җиктем күк юрга.*
*Биктимер Абитов башкара*

***Иске пасхут (Иске болын)***

*Иске лә пасхут әй тар булса,*
*Әй куар итем төлке мал булса,*
*Әй куар итем төлке ләй мал булса.*
*Ташламам, туганым, и ташламам,*
*Гасис башкайларым сау булса,*
*Гасис башкайларым сау булса.*

*Иске пасхут.*
*Биктимер Абитов башкара*

Ул якларда яңа үзенчәлекле җырлар юк», – дип әйткән кайбер иптәшләрнең хаксыз булулары ачыкланды. «Көйдемяндым», «Зөләйха кыз бәете», «Мустафа мулла бәете»н дә ишеттек. «Зөләйха кыз бәете» белән «Мустафа мулла бәете» татар халкында популяр бәетләрдән булып, алар милләттәшләребез яшәгән барлык төбәкләрдә дә мәгълүм. Ә менә «Ак каен» бәетен шушы якта гына беләләр. Әйтүләренә караганда, Тибендедән 30 чакрымда урнашкан Уват авылында аклар бер ир баланы асып киткәннәр. Бу фаҗигалы вакыйгага багышлап, халык шунда ук бәет чыгарган.

Биктимер абыйдан язып алынган җырлар тематик яктан төрле. Тормыш-көнкүреш һәм тарихи җырлар, ямщик моңнары, уен-бию җыры һәм такмаклар да бар. Әлбәттә, иң күбесе – мәхәббәт җырлары. Бу җырларның көйләренә якты мажор лады, эчтәлекләренә тирән фәлсәфи мәгънә хас.

Биктимер абый башкаруында шулай ук безгә мәгълүм булган «Касимский Ибрай», «Әрәмә», «Кара урман» кебек җырлар да язып алдык. Алар бер үк җырның вариантлары буларак кызыклы. Биредә «Салкын чишмә» җырының иң матур вариантына тап булдык. Җырның баштан алып кушымтага

кадәр өлеше – куплеты яңа үзенчәлекле көйгә җырлана. Безнең карашка, үзенең аһәңе белән ул төп нөсхәдән бер дә ким түгел.

Биктимер абый репертуарына караганда, Себер татарларының җыр иҗатында Идел буе, Оренбург, Томск һәм башка як этник төркемнәренең аһәңнәре дә ишетелә, мишәр татарларының, казах һ. б. халыкларның моңнары үтеп керүе сизелә. Аның җырлары арасында төрле якларның җырлары да бар. Әйтик, «Щадринский Фатыйма» җырын элекке шахтёр Сабирметов Садри Оренбургтан алып кайткан, «Иркутск татарлары җыры»н Биктимер абый сугышта Иркутск егетеннән өйрәнгән һ. б. Бу күренеш җырларның географиясе киңәюен күзәтергә мөмкинлек бирә.

Биктимер абыйдан без 43 (!) көй язып алдык. Бу искиткеч бай хәзинәдән кайбер үрнәкләрне Фатих Урманчеев белән кичке лекция-концертта магнитофоннан халыкка да тыңлаттык.

Атна буе яза-яза хәлдән тайган 15 килолы магнитофоныбыз түзә алмады, ахыр чиктә ватылып, тынып калды. Бездән бигрәк, Биктимер абый кара кайгыга батты: инде җырлар Казанга китмичә, аның күңелендә генә калачакмыни? Колхоздан тиз генә машина юнәтеп, район үзәге Ишем Тамакка барып, магнитофонны төзәтеп кайттык.

Биктимер абый җырлар арасында төрле тарихи вакыйгалар турында да, риваять-легендалар да сөйләп ала.

Абитов Биктимер абый сөйләгәннәрдән:

*1. Әлеккә дигән кеше булган. Аны князь Әлекке, Әликкәй дигәннәр. Йармак аңарга кунакка килгән. Бу князь Йармакка каршы сугышмаган. Күчем бирегә Концетаңдан килгән. Кайчандыр аның турыда җырлар булган. Халык аңа яхшы караган.*

*2. Иртеш – бер җәнлек булган. Аның тешләре зур булган. Шуннан тешләре табылган да, елгага Иртеш дип куйганнар.*

*3. Суат елгасы булган. Тобольскины шунда ясамакчы булганнар. Елгада су авыр булса, шунда шәһәр төзегәннәр. Монда урыслар шәһәр төземәкче булганнар да, татарлар аларны куып җибәргәннәр.*

*4. Элек авыл бу җирдә булмаган. Иртеш буенда Юллар дигән җир булган. Шунда юлчылар килеп, авыл салганнар. Анда хәзер дә урыннары бар. Анда күп булган. Юллар янында остров бар. Безнең авыл урынында зур табун йөргән. Мал тибенеп туенган. Шуннан Тибенде киткән. Юллардан бирегә күчеп, авыл ясаганнар. Малый Тибенде элегрәк булган. Аннан соң Большие Тибенде булган. Тибенделәр 470 еллар элек булган.*

Бу авылда яшь балага картатасы – әтисенең әтисе исемен кую гадәте бар икән. Әтисенең әтисен, ягъни безнеңчә бабайны биредә картата дип атыйлар. Ишектән бер кечкенә укучы бала килеп керде. Әтисе Уразали аңа үз әтисе Ниязалинең исемен кушкан. Димәк, туу турында таныклыкта ул Әбусагитов Ниязали Уразалиевич дип язылган. Тик аны өйдә, мәктәптә һәм авылда да Ниязали дип түгел, ә картата дип йөртәләр. Чөнки авылдагы гадәт буенча, үлгән кешенең исемен атарга ярамый. Шулай итеп, Ниязали Картата исеме белән гомер буе яшәячәк.

Казанга кайткач, бу җырлар 1972–1985 елларда Казан телевидениесендә үзем алып барган «Халык җәүһәрләре» тапшыруында, радиотапшыруларда, Вильнюс, Улан-Удэ, Репино (Ленинград өлкәсе), Иваново, Чабаксар, Казан, Төмән һ. б. шәһәрләрдә узган Бөтенсоюз фольклор фәнни конференцияләрендә яңгырады. Шулай итеп, алар халыкка таралды.

Абитов Биктимер абый безгә картлар телендә бик популяр булган «Сәйфелмөлек» җырын да яздырды. Бу – мәгълүм дастанның аерым бер өзеге, күптән җыр булып мөстәкыйль

яши башлаган. Алга таба без әле «Йосыф–Зөләйха», «Бүз егет», «Таһир–Зөһрә» һ. б. дастаннарның җырлары белән дә танышырбыз.

***Сәйфелмөлек***

*Яшел сантык эчләрендә алтын кашык,*
*Күсең берлән кашыңгай бултым гашыйк,*
*Күсең берлән кашыңгай бултым гашыйк.*
*Күс өстентә кашың кара сөселмәс,*
*Синең өчен газиз җаным өселмәс,*
*Синең өчен газиз җаным өселмәс.*

*Синең дәртең миңар дәрмандан артык,*
*Сиңар кол булганым солтантин артык.*
*Бер илә кеше лаек булырмы,*
*Очар кошкай адәм гашыйк булырмы?*
*Очар кошлар очар китәр авадан,*
*Канатым юк, калырсың мөтәәссиф[1].*

*Сәйфелмөлек.*
*Биктимер Абитов башкара*

Биктимер абыйның иң бәхетле җыры – «Ямщиккәй» . Ул Татарстан дәүләт фольклор музыкасы ансамбле репертуарында үз урынын алды. «Татарстан – Яңа гасыр» һәм «Мәйдан» каналлары аша җыр бик тә үзенчәлекле шаян клипка бәйләп күрсәтелә башлады. Бу җырны дөнья читләренә барып тапкан, магнитофонга яздырып, Казанга алып кайткан, нотага төшергән һәм аның турында радио-телевидение аша сөйләп,

[1] Мөтәәссиф – кайгыру, кызгану, үкенү белдерү.

җырлап һәм баянда уйнап халыкка җиткергән кеше турында ләм-мим сүз әйтүче булмавы гына йөрәгемне әрнетте.

Халык җырының да туган авылы була, ул шунда туй-мәҗлестә, кунак-төшемдә беренче мәртәбә яңгырый, Сабантуй, аулак өй, кичке уеннарга күчә. Бераз чиркану алгач, сәүдәгәрләр, шәкертләр, күчеп китүчеләр, чит авылга кияүгә чыгучылар, солдатка алынучылар, сөргенгә сөрелүчеләр, шахтёрлар, зимагурлар һәм тагын әллә кемнәр аркылы күрше авылга, өязгә, шәһәргә, чит төбәкләргә таралып яшәвен дәвам итә. Шуларның иң «җәүһәр вә якутлары» гына гомумтатар җыр капчыгына җыйнала бара. Ә капчыкка аларны кем сала соң? Беренчеләрдән, әлбәттә, бөек шагыйребез Тукай! Һәм халык көйләрен эзләү, саклап калу, яңадан халыкка кайтарып популярлаштыру максатын куйган фольклорчылар, музыка белгечләре.

**Уразов Зәйнулла абый** да Зур Тибендедә туган, ул 1909 елгы. Укый-яза белми. Көтүче. Кечкенәдән үк бик күп авырлыклар күреп үскән, 14 яшеннән, тамагын туйдырыр өчен, ялчылыкта йөргән. Алтын приискаларында бәхет эзләгән. Зәйнулла абый үзенең комсомолда тәрбияләнүе турында горурланып сөйли. Хәзер ул маллар көтә. Эштән бик арып кайтуына карамастан, караңгы төнгә кадәр безгә үзенең җыр капчыгын чишеп, хәзинәсеннән берәм-берәм генә алып, микрофонга яздыра башлады.

Зәйнулла абый «Урал тавы» җыры турында болай дип сөйләде: *1914 елда чыккан җыр. Николай бу як татарлардан солдат алмаган. Безнең кешеләр Рига янына трудармиягә җибәрелгәннәр. Бу җырны шулар чыгарган. Түмән өлкәсе Исәт авылы кешесе җырлаган. Армиядә йөргән кеше богауланган кеше кебек йөри.*

Зәйнулла Хәсән улы Бөек Ватан сугышында катнашып, орденнар һәм медальләр алган. Сугышта да авылның иң данлыклы «Җиктем күк юрга» көен көйләп йөргән:

*Чыктым базарга ла, алдым ла күк юрга,*
*Исән-саулар булыңчы, туганнар, күп елга.*
*Күл буйларында-лай балалы ла үрдәк,*
*Илләрдин чыккач-лай янадыр йөрәк.*

Зәйнулла абый безгә үзе яратып, күптәннән җырлый торган җырларыннан «Осталар махмал[1] кисә»[2], «Тарлык җыры», «Атлап барып, атка утырдым», «Сәва», «Сахраларда» һәм тагын берничә авыл көе яздырды. Бу җырларны ул сузыбрак, үзенчә тәмләбрәк җырлый.

Зәйнулла абыйның бичәсе **Кучатова Мәликә апа** да иреннән калышырга теләмәде. Мәликә ападан без «Эскадрон» һәм «Уел»ның яңа бизәкләргә бай вариантларын язып алдык. Мәликә апа укытучы булган, хәзер пенсиядә. Ул безгә язучы Галимҗан Ибраһимовны һәм җырчы Гөлсем Сөләймановны күрүләре турында истәлекләр дә сөйләде. Гап-гади авыл кешеләре бит!

Магнитофонга яздыргач, җырлаучыларның үз тавышларын тыңлап караулары – бик күңелле күренеш, «нәкь тә үз тавышы ич!» дип әйтүләре ни тора!

Зур Тибендедә мәктәптә укыткан, хәзер интернатта тәрбияче булып эшләгән **Әбусагитова Шаһидә апа** (1921 елгы) Тевриз районының Кип-Куллар авылында туган һәм шул авылның клуб сәхнәсендә җырлый башлаган. Ул безгә «Уракчы кыз»ның бу якларда киң таралган искиткеч матур яңгырашлы вариантын җырлап күрсәтте. Җырның Нәкый Исәнбәт язган сүзләре үзгәрешсез сакланган. Себер татарлары калыбына салыбрак көйли ул аларны.

Шаһидә апа өч авыл көе җырлады. Шуларның берсе Заһидулла ага Яруллинның «Тукай маршы» булып чыкты! Шаһи-

[1] Махмал – маһмал, хәтфә яки бәрхет.

[2] «Осталар махмал кисә» җыры Татарстан дәүләт фольклор ансамбле репертуарына кертелгән.

дә апа бу җырны 20 нче елларда сәхнәгә чыгып та җырлаган икән. Барыбызның да күңел түренә кереп урнашкан бу легендар маршның туган җиргә мәхәббәт турындагы текст белән җыр булып яңгыравы безнең өчен көтелмәгән яңалык булды.

Шаһидә апаның ире **Әбусагитов Хәлил абый** (1922 елгы) да оста җырчы булып чыкты. Без аларда кичен чәйләп тә утырдык. Шаһидә апа һәм Хәмит абый безгә яшь вакытта, парлап, уен вакытларында җырланган «Көянтә» җырын уйнап-җырлап күрсәттеләр.

***Көянтә***

Хәлил:

*Алмы синең көянтәң,*
*Гөлме синең көянтәң?*
*Үзең кебек матур гына*
*Бардыр синең сөяркәң.*

*Алчәчәк белән гөлчәчәкнең*
*Кайсысын таратасың?*
*Хәллә белән Хәмитнең син*
*Кайсысын яратасың?*

Шаһидә:

*Алчәчәк белән гөлчәчәкнең*
*Икесен дә таратам;*
*Хәллә белән Хәмитнең мин*
*Икесен дә яратам.*

Шаһидә апа үзенең туган авылы көен дә җырлап күрсәтте:

***Кипкуллар көе***

*Әнә килә автомобиль,*
*Төягәне – дилбегә.*
*Ямьле Иртеш буйларында*
*Тавышым калсын билгегә.*

Гаилә дуэты «Кил утырыйк» җырын шулкадәр дулкынланып башкарды ки, безгә дә бераз ямансу булып китте. Чөнки иртәгә без Зур Тибенде белән хушлашып, Савыргачка күчәргә тиешбез.

*Кил, утырыйк, кил, утырыйк,*
*Кил, утырыйк киретәгә, шул;*
*Кил утырыйк, сөйләшәек,*
*Аерылырбыз иртәгә.*

Зур Тибенде урамы белән барганда, бер олырак яшьтәге апа туктатып сорады: «Сезгә “Йар-йар!” җырлары кирәкме?», – ди. Магнитофонны өстерәп, аның артыннан киттек. Бу **Хәкимова Бәдигыйльҗамал апа** (1900 елгы, 68 яшьтә). Барып җиттек, башта чәй куйды.

«Йар-йар!» – туй җырларыннан. Аны кияү кызны алырга килеп, аны ата-анасы йортыннан алып чыгып китәр алдыннан җырлыйлар икән. Җырлаганда, хатын-кызлар елыйлар.

Миңа Көнбатыш Себердә магнитофон тасмасына әлеге атаклы туй җырының тугыз вариантын язып алу насыйп булды. Зур Тибендедә теркәлгәне миңа аеруча якын һәм мин аны үземнең чыгышларымда һәрвакыт аудиотасмада уйнатам яисә үзем җырлап күрсәтәм.

***Йар-йар***




*Кара сыер мейгесен*
*Каермагыс, йар-йар!*
*Анасыннан баласын*
*Аермагыс, йар-йар!*

*Килер-килмәс юлыңа*
*Киндер чәчтем, йар-йар!*
*Киндер китән*[1] *булганчы*
*Килмәм, атам, йар-йар!*

Борынгыдан килгән яшәеш кагыйдәләре буенча, күпчелек очракта килен читтән, башка авылдан, башка нәсел-ырудан алынган. Чөнки ыруглык кагыйдәләре сакланган Себер татарларында бер авыл кешеләре бер-берсе белән туган-тумача саналган. Бу чынлап та шулай, бер авылда бер нәселгә караган гаиләләр күп.

Күп очракта кыз этиләре өенә бер елдан соң гына, ире белән бергә, яшь баласын күтәреп килгән.

*Ак төенгә төйгәнем*
*Алтын мите*[2], *йар-йар!*
*Айлык йиргә саткалы*
*Атам мите, йар-йар!*

Себер татарларында, башка күп халыклардагы кебек, кыз белән яшь киленне чәч толымына карап аерганнар. Кызлар чәчне – бер, яшь киленнәр ике толым итеп үрергә тиеш булганнар. Чәч аеру йоласы кыз озатканда мәҗбүри йолаларның берсе исәпләнгән. Ул болай үтәлгән. Кияү нүгәрләре, ягъни кияү егетләре белән кыз алырга килгәч, җиңгәләре чыбылдык эчендәге кызның чәчен махсус тарак белән тарап, икегә аерып үрә башлыйлар, һәм шул вакытта кызның туган-үскән йорты, ата-анасы, дус-ишләре, туган-тумачалары белән хушлашу-саубуллашу сәгате җиткәнне аңлатып, «Йар-йар!» әйтелә башлый.

---

[1] Китән – ак киндер тукыма.
[2] Алтын мите – алтынмы иде, атам мите – атаммы иде.

Бәдигыйльҗамал мамай[1] менә шундый куплетын да өстәп куйды:

*Бер чиләк бузаңыс*
*Ас булмасын, йар-йар!*
*Кияү башын ачып багың,*
*Тас булмасын, йар-йар!*

Безнең киләчәктә язып аласы вариантларда, мәсәлән, Төмән өлкәсенең Түбән Тауда районы Байкал (Бохара) авылында ул болайрак яңгырый:

*Ике ястык, бер түшәк*
*Аз булмасын, йар-йар!*
*Чыгып карагыз кияүне,*
*Таз булмасын, йар-йар*!

Туй җырларындагы шаян рухка казах язучысы Мохтар Ауэзов та игътибар итә: «Башка халыклардагы кебек үк, казах халкының туй җырлары үзләренең ритуаль-көнкүреш әһәмиятеннән тыш, тантанага җыелганнарның күңелен күтәрү өчен дә җырлана. Шуңа күрә аларның кайберләре, мәсәлән, «Жар-жар!» һәм «Бит-ачар» җырлары бер үк вакытта тантаналы да һәм шаян характерда да була»[2].


Бәдигыйльҗамал мамай Зур Тибендегә якын гына урнашкан Уба авылыныкы. Анда «Йар-йар!»ның яңадан бер куплетын кушып җырлыйлар икән:

*Пәйгамбәрнең пер кысын*
*Али[3] алты, йар-йар!*
*Тастармаллык туй[4] кылман*
*Шуннан калты, йар-йар!*

[1] Мамай, мама – апа, өлкән яшьтәге хатын-кызга мөрәҗәгать итү сүзе.
[2] *Мухтар Ауэзов.* Мысли разных лет. Алма-Ата, 1961. С. 79.
[3] Али – Гали ибне Әбу Талиб, Мөхәммәд галәйһиссәләмнең кияве.
[4] Тастармаллык туй – бирнә күрсәтү мәҗлесе, тастар – сөлге.

**Аптюкова Сәлимә апа** (1925 елгы) борынгы картлар җырын белүе турында безгә үзе килеп әйтте. Күптәннән үзенең бабасыннан ишетеп өйрәнеп калган икән. Ул «Утыртым лай уба сиңеренәй» дип башлана. Яздырдык һәм бик гаҗәпкә калдык. Бу бит уникаль көй! Мин шунда ук «Поэма для голоса соло!» – дип кычкырып куйдым. Барабаларны 1967 елда айкап чыккан Фатих та тел шартлатты, мондый озын көйне беренче ишетүен әйтте. Җырны «Борынгы җыр» дип үзебез атадык. Сузып җырлана торган, бераз ирекле метро-ритмдагы эпик яңгырашлы бу озын көй 1968–1974 елларда узган экспедицияләр вакытында, ягъни безнең «Себер эпопеясы»нда язып алынган җыр-көйләрнең иң матур үрнәге иде. Аны Көнбатыш Себер татарлары җыр хәзинәсенең йөзек кашы дип әйтү дә һич арттыру түгел. Һәм 1973 елны бу уникаль көйне Лена Бичарина, acapella (баянсыз) җырлап, Казан телевидениесе аша бөтен татар дөньясына яңгыратты. Соңрак композиторлар М. Шәмсетдинова да, К. Хөснуллин да үзләренең симфоник әсәрләренә төп тема (төп партия) өчен бирүләрен үтенгәннәр иде. Бирмәдем, басылып чыкканнан соң гына файдаланырга мөмкин икәнлеген әйттем. Менә, ниһаять, бу китап басылып чыгу белән, әлеге мөмкинлек ачыла.

### *Борынгы җыр*






*Утыртым лай уба[1] сиңеренәй[2],*
*Каратым гуй суның инүенә.*
*Су килүенти ич файта юк,*
*Тәкътир яскан эшләргә иц цара юк.*
*Тәкътир яскан эшләргә иц цара юк.*

*Агыйтел лә алкын, сулары салкын,*
*Ак үртәккәйләр-гуй каршы ла йөсәлмый.*
*Эцләрем тулы ай кайгы-лай-хәсрәт,*
*Бер йырламыйца күңлем түсәлмый.*
*Бер йырламыйца күңлем түсәлмый.*

## ***Савыргач авылы***

1968 елның 3–6 июлендә Орджоникидзе исемендәге колхозга караган, Загваздина авыл советына кергән Савыргач авылында булдык. Барлыгы 86 хуҗалык, ул – колхозның бер бригадасын тәшкил итә. Авыл халкы мал асрый, игенчелек белән шөгыльләнә. Тагын бер шөгыле урманчылык белән бәйле.

*Савыргач авылы тарихы*

*Кайчандыр биредә бер әби яшәгән. Моннан берничә йөз ел элек. Ул әбинең балалары булган. Әби үлгәч, аны бер җирдә җирләгәннәр дә шунда нарат утыртканнар. Әнә шул нарат*

---

[1] Уба – калкулык.

[2] Сиңер – тау сырты.

*астында калган, ди ул әбинең кабере. Ул нарат хәзер бик зур, өч-дүрт йөз яшьләрдер бугай. Савыргач исеме әнә шул әби исеменнән калган, ди.*

*Авылдан ерак түгел Колчак заманында казылган окоплар сакланган. Монда каты сугышлар булган.*

*Авылда, нигездә, шушы як татарлары – җирле халык яши. Ара-тирә Казан якларыннан күчкән, яки ата-бабалары шул яктан килгән кешеләр дә очрый. Әмма бу якта Идел буе халыклары – ул яктан күчеп килүче татарлар Бараба якларындагы кебек күп түгел.*

*Информант – 10 нчы классны тәмамлаган*
***Зимагулова Илсөяр** (1949 елгы)*

Дүрт көн дәвамында Илсөяр безгә җырчыларны табарга ярдәм итте, Савыргач зиратындагы изгеләр каберлеген – астананы күрсәтте. Астаналарны махсус җаваплы кешеләр карап тора икән.


Илсөяр сөйләгән әби Салиха-биби булырга тиеш. Бу турыда Төмән университеты профессоры Хәнисә Алишина яза. Кирманнан[1] килгән Мөслехетдин шәехнең ике кызы була. Олы кызы Салиха-биби Савыргач авылы янындагы Чарби дигән җирдә шәһид китә һәм җирләнә[2].

Савыргачның иң данлыклы җырчысы – **Разулев Шәфикъ абый** (1913 елгы), 2 класс белеме бар, колхозда каравылчы булып эшли. Шәфикъ абыйның безгә җырлаган беренче җыры – «Туктасын качкы».

Шәфикъ абый сөйләгән буенча, *Туктасын атлы кеше караваннан – баржа сөйрәүдән качып киткән. Ул үзенең җырын җырлап йөргән. Минем ерак бабамның – атамның атасының атасының якыны булган. Моннан 200 елга якын элек булган бу хәлләр.*

[1] Кирман – Ирандагы Кирман шәһәре турында сүз барырга мөмкин.

[2] *Алишина Х.Ч.* Ономастикон сибирских татар: (на примере Тюменской области). Ч. 1. Тюмень: Изд-во Тюмен. гос. ун-та, 1999. 240 с.

Савыргач авылы кешеләре. 1968 ел



Шәфикъ һәм Сафия Разулевлар. Савыргач авылы. 1968 ел

Баржа сөйрәүчене бу якларда *караван сөйрәү* дип йөрткәннәр. Караванчы – бурлак була инде.

**_Туктасын качкы_**

*Ераккай йиртә-гуй, мин йөрәймен-гуй, әйе-вай,*
*Ай, туган-үсгән илләремәү-гуй, хат ясып,*
*Ай, туган-үсгән илләремәү-гуй, хат ясып.*

*Йер ераклардай-гуй, мин йөримен-гуй, әйе-вай,*
*Әй, туган-үсгән илләрем ят итеп,*
*Әй, туган-үсгән илләрем ят итеп.*

*Агыйделләргәй төшгәнемтә, гуй, әйе-вай,*
*Вай, каеккау*[1] *ментем-гуй, ат язып,*
*Вай, кайыккау ментем-гуй, ат язып.*

*Шулып лай баштау, вай, карлугач, әйе-вай,*
*Вай, атыпкай лау алтым-гуй, карным ач,*
*Вай, атыпкай лау алтым-гуй, карным ач.*

*Ни ашасам да, вай, карным ач, әйе-вай,*
*Вай, ятып калды-гуй, туганым Карбигәч,*
*Вай, ятып калды-гуй, туганым Карбигәч.*

*Кара урманнарга кергәнемдә-гуй, әйе-вай,*
*Ай, сызгырты урманның киеге,*
*Ай, сызгырты урманның киеге.*

*Туктасын качкы.*
*Шәфикъ Разулев башкара*

[1] Кайык – каек, агачны чокып ясалган көймә.

Шәфикъ абый җырлап күрсәткән «Солдат җыры» озын көйгә җырлана. Шәфикъ абый сүзләренчә, бу җыр Герман сугышында чыгарылган, ягъни 1914 елгы сугыш вакытында җырлана.

**_Солдат җыры_**

*Без киткән уакыт нидәй-гой уакыт,*
*Уай, йирләр туң гына агачның тамыры мән.*
*Солдат ла ята казармата, уай,*
*Тар шинилләрен ябынып.*

*Җыламай, әтием, җыламай, әнием,*
*Уай, солдат бултым Алланың әмере мән;*
*Солдат лай мескен, уай, төш күрә,*
*Уай, туган-үскән илләрен сагынып.*

*Солдат җыры.*
*Шәфикъ Разулев башкара*

Шәфикъ абыйга кушылып, **Ганиев Вәлиулла абый** (1908 елгы) да җырлап җибәрә. Ул – авылның тимерчесе. «Туктасын качкы»га да кушылып җырлап утырды. Җырламый түзә алмый!

Бу авылда «Мәрәтнең җыры» да бик популяр.

Мәрәт исемле егет, имеш, бер кызны яраткан. Кыз башка кешегә кияүгә чыккан. Мәрәт кызга багышлап җыр чыгарган.

***Мәрәтнең җыры***




*Әй чаныем, йыр йырлаем,*
*Дәлил урауларын пашлап:*
*Раслап минү сөйгән пулсаң,*
*Китмәгел ятларгай ташлап.*

*Туктабашта син торасың,*
*Сине күрсәм кай түзә алмаем,*
*Сине өнәмәй түсә алмаем,*
*Сине өнәмәй түсә алмаем,*
*Шикәр чәйнәп йота алмаем.*
*Сине өнәмәй түсә алмаем,*
*Шикәр чәйнәп йота алмаем.*


*Башыңа-лай япкан ак яулыгың*
*Яңа яуган кардин артык.*
*Сиба пуең, матур йөсең,*
*Буйдак йөргән кысдан артык.*

*Мәрәтнең җыры.*
*Вәлиулла Ганиев башкара*

Икенче көнне, Шәфикъ абый эштән кайткач, кич белән «Башмагым»ны яздык. Бөтен татар дөньясында билгеле җыр,

артык ис тә китмәскә мөмкин. «Җизнәкәй» җырын да беләбез. Татар халык иҗатында бу төр җыр-диалоглар шактый. Шулай да Шәфикъ абый һәм аның хәләле Сафия апа егет-кыз булып чыгып баскач (җитмәсә, матур киемнәрен дә киеп), без шаккаттык. Өй эче тулы халыкны урамга чыгардык һәм барлык тәрәзәләрне ачып куйдык. Шәфикъ һәм Сафия Разулевлар Савыргачтагы өйләрен сәхнә итеп, элгәреге туй-мәҗлесләрдәгечә бөтен фасонын китереп, артистлар кебек рольгә кереп, барлык юмористик төсмерләр белән «Башмагым»ны егет белән кыз булып, назланып-иркәләнеп җырлап бирделәр. Алар әйтүенчә, бу галәмәт «артистлану» туй-мәҗлесне җанландырып җибәрү өчен кирәк булган. Үзенә күрә «театральләшкән» тамаша. Юкка гына Россиядә татар театры руслардан кала икенче булып барлыкка килмәгән икән шул! Алга таба без аны «Хан кызы» җырында да күрербез әле.

***Башмагым***




Сафия:

*Башмагымның башы башка,*
*Басмас итем мәрвәр ташка;*

*Мин алдандым башым яшькә,*
*Бирче, егет, башмагымны.*
*Бер башмагым – простой чуклы,*
*Бер башмагым – яшел чуклы.*

Шәфикъ:

*Әйтеп-сөйләп йермә юкны,*
*Мин алган юк башмагыңны!*

Сафия:

*Атлас юрганнар ябыем,*
*Мамык мендәрләр салыем,*
*Үбеп-кочып йоклатырмын,*
*Бирсәнә, егет, башмагымны.*

Шәфикъ:

*Мамык мендәрләр салсаң да,*
*Атлас юрганнар япсаң да,*
*Үбеп-кочып йоклатсаң да,*
*Мин алган юк башмагыңны!*

Сафия:

*Ат якшысы ала була,*
*Алалары кола була;*
*Әткәм тойса, бәла була,*
*Бирсәнә, егет, башмагымны!*

«Башмагым» – татар халкының классик җырларыннан берсе. Хәзерге вакытка кадәр төрле регионнарда узган экспедицияләр вакытында бу җырның күпсанлы вариантлары очрый. Жанрына карата фольклорчылар арасында ике төрле караш яши. Мәсәлән, Х. Ярми аның бәет жанрына каравын әйтә[1], И. Надиров кара-каршы җырлана торган

[1] *Ярми Х.* Бәетләр. Казан, 1960. Б. 192.

җырлар рәтенә кертә[1]. Татар халкының лиро-эпик жанрларына караган татар бәетләрен өйрәнгән Ф. Урманчеев исә «Башмагым»ны игътибарсыз калдыра[2].

М. Нигъмәтҗанов җырның килеп чыгышын бәеткә бәйли. «Гәрчә аларда бәетнең структур нигезе ачык күренеп торса да, кайбер бәетләрнең көйләре, еш башкарылып, озын җырларга әверелде. Мәсәлән, «Тәфтиләү», «Башмагым»[3]. А. Ключарев[4] һәм М. Мозаффаров[5] «Башмагым»ны җырларга кертәләр.

Г. Тукай да үз заманында гаять популяр булган «Башмак көе»н бәет дип күрсәтми, ә «Сак-Сок» турында исә «бәет вә көе» дип яза: «Бу “Башмак көе” дә мөфти вә мирзаларыбыздан зур фамилияле бер кешегә чыгарылган көй булырга кирәк. Ләкин тәгаен кемгә вә ни хосуста чыгарылганын, мәгаттәәссеф, тәфтиш (тикшерү) итә алмадым. Бу көй, зан идәрсәм (уйлыйм ки), бер заман хөкүмәт тарафыннан җырланырга мәнгы да ителгән (тыелган) иде бугай»[6].

«Башмагым» җырының шигыре революциягә кадәр дә һәм аннан соң да күп мәртәбәләр төрле китапларда басылган. Аны 1901 елда Хельсинки шәһәрендә фин галиме лингвист Х. Паасонен «Татар җырлары» исеме белән немец телендә басылган хезмәтенә дә кертә. Ул текст 1899 елда элекке Самара губернасы Бөгелмә өязе Чагатай авылында Мөбәрәкша җырлаганча бирелгән.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгендә җырның фольклор экспе-

---

[1] *Надиров И.* Татар халык җырлары. Казан, 1955. Б. 220.

[2] *Урманчеев Ф.* Халык авазы. Казан, 1974.

[3] Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М.: Наука, 1967.

[4] Татарские народные песни / сост. и собиратель А.С. Ключарев. Казань: Таткнигоиздат, 1955. С. 200.

[5] Татарские народные песни». С. 47.

[6] *Тукай Г.* Әсәрләр: дүрт томда. 2 т. Казан: Таткнигоиздат, 1955. Б. 258.

дицияләре вакытында язып алынган күпсанлы вариантлары саклана. Х. Ярми шуларның бер нөсхәсен «Бәетләр» китабына кертә.

«Башмак көе» зур сәхнә әсәрләренең музыкаль лейтмотивына да әйләнде. Мәсәлән, 30 нчы елларда драматург, композитор Хәбибулла Ибраһимов һәм композитор Мөсәлим Вәлиев[1], 1942 елда композитор Җ. Фәйзи «Башмагым» исемле музыкаль комедияләр язалар.

Бу урында шуны әйтеп китү урынлы булыр: «Башмагым» көе татарлар яшәгән барлык регионнарда да очрый. Җырның сүзләрен төрле елларда фольклорчы галимнәр Халидә Гатина, Фатих Урманчеев, Илсөяр Закирова Омск, Төмән, өлкәләрендә язып алалар. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге фольклор фондында җырның экспедицияләр вакытында язып алынган шактый вариантлары саклана.

Шәфикъ абый һәм Сафия апа безгә бу якларда иң популяр җырларның берсе – «Җиктем күк юрга»ны да парлап җырладылар.

***Җиктем күк юрга***

*Чыктым базарга ла, алдым ла күк юрга.*
*Исән-саулар булыңчы, туганнар, күп елга.*
*Зәңгәр күлмәккәй кесә лә куймадым.*
*Синең лә нурлы йөзеңне күреп тә туймадым.*

*Ишек-ләй алдымда-лай бәйләнде сары ат.*
*Илләрдин киткәчтин, каерыла канат.*
*Күл буйларында-лай балалы үрдәк,*
*Илләрдән чыккач, янадыр йөрәк.*

---

[1] *Атанова Л.П.* Масалим Валеев. Уфа: Башк. кн. изд-во, 1970. С. 10.


*Түмән чанага җиктем лә күк юрга.*
*Исән-ләй сау булың, туганнар, күп елга.*
*Ашларым ла аш бармай йөрәкләрем янганга.*

*Чыктым гой урманга, кистем гой бер каен*
*Газиз гой, әнкәем, сагынам көн саен.*
*Ниләр булды икән безнең туратка.*
*Йитәсе йирләргә йитеп лә булмады.*

80 яшьлек **Абдразякова Бибе мамай** безгә «Бүз егет» дастанын яздырды. Дастанны әби әкият формасында сөйли. Шулай ук «Йосыф – Зөләйха» һәм «Таһир – Зөһрә» дастаннарының да өзекләрен хәтерли ул.

«Бүз егет»нең бер вариантын **Шәрипова Хәтимә мамай** да (1905 елгы, 63 яшьтә) җырлап бирде. Көе бераз лирик җырларга тартым.

***Бүз егет***



*Ташла, ирегәм, ташла, ирегәм,*
*Ташла, ташлыйсың килсәй;*
*Мин синий шуныта ташларым,*
*Тар каберләргә керсәм.*

*Бу балтамны чабып куйтым,*
*Талның тамырларынай.*
*Ал гөлләр сибеп үстереӊ*
*Минем каберләремә.*

*Сандугачым сайрый-сайрый,*
*Канатын айрып тарый.*
*Ай, туганым, шунысы кыен,*
*Күсеӊ моӊаеп карый.*

Җырның көе бер октава диапазонында. Иң югары ноктадан түбән таба шуыша-шуыша, төп тавышта төшеп туктый. Бераз елау интонацияләре дә ишетелә. Мөнәҗәткә дә тартымлык бар.

Хәтимә мамай мәктәптә укымаган. Бу авыл җырларын бик яхшы хәтерли. «Туганым», «Борынгы җыр» («Мин ышандым»), «Түгәрәк өстәл», «Чирмешәкәй», «Алсу» – аның яраткан җырлары, ул аларны туй-мәҗлесләрдә дә башкарган.

**Әйтмөхәммәтов Хөҗәтелислам абый** (1920 елгы) бу якларда сирәк очрый торган «Йерәнчеккәй атларым» һәм «Хафизаләм, иркәм»нең бер вариантын «Кама белән кондыз» исеме белән яздырды. Ә «Йерәнчеккәй атларым» Новосибирск өлкәсе Бараба татарларында бик популяр булып чыкты. Мин бу җырны шушы 1968 елның көзендә аларга баргач, бик күп таптым.

Инде **Рәҗәпова Бәйрә апа** (41 яшь) җырларына тукталыйк. Ул безгә «Кайдадыр шунда», «Иске шахтёр көе» һәм бер «Авыл көе»н җырлады.

### *Кайдадыр шунда*

*Кайдадыр шунда – шәһәр читендә*
*Эшче гаиләдә мин тудым;*
*Абыйлар белән, түтәйләр белән*
*Бергәләшеп эшкә тотындым.*

*Күпкә бармады вакыт көннәре,*
*Канлы сугыш тиздән башланды;*
*Кырык өч яшендә безнең әткәбез*
*Ут эченә илтеп ташланды.*

*Бердәнбер көнне кара урманда*
*Ишетелә мылтык тавышы;*
*Дәү абый белән бәләкәй абый*
*Атышалар кара-каршысы.*

*– Атма, туганым, куй мылтыгыңны,*
*Син бит минем газиз туганым.*
*– Юк, – диде теге, – бүгенге көндә*
*Туганым да түгел син минем.*

*Син үзең теләп киттең акларга,*
*Аклар халкы өчен кан түгеп;*
*Гомер буена байларга эшләп,*
*Байлар халкы өчен интегеп.*

*Шулай диде дә, мылтыгын алып,*
*Чәтмәсен тартырга кыймады;*
*Шул җитешкәнче, бәләкәй абый*
*Күкрәгенә китереп кадады.*

*Кызарып пешә кызыл алмалар,*
*Кояш кызуында болында.*

*Каргалар белән козгыннар гына*
*Калды туганымның янында.*

*Кайдадыр шунда.*
*Бәйрә Рәҗәпова башкара*

Рәҗәпова Бәйрә җырны яшь вакытта Даутова Галиядән отып алган. Җырның нинди уңай белән чыгарылганын һәм кайдан килгәнен белми.

Бу җырның тарихы шактый кызыклы. Аның сүзләре татарча беренче тапкыр 1965 елда дөнья күргән «Татар халык җырлары» китабында басыла[1]. Җырга искәрмә дә бирелгән: «Кайдадыр шунда, шәһәр читендә». Гражданнар сугышы чорының популяр җыры. Шушы ук сюжет рус халык поэзиясендә дә бар. Җырның татар телендәге вариантын 1955 елда ТАССРның Тәмте районы Көрәле авылында Равилева Луизадан экспедиция әгъзасы Ә. Сафиуллина язып алган.

Җыр «Ике туган бәете» исеме һәм башка көй белән Җ. Фәйзинең «Халык җәүһәрләре» китабында да басыла. Ул 1951 елда Татарстанның Мамадыш районы Яңа Камазан авылында Рәшит ага Мозаффаровтан язып алынган. «Рәшит ага аның бер генә куплетын хәтерли иде. Ул тирәдәге күп кенә кешеләрдән сорашып карасак та, калган сүзләрен таба алмадык. Көен белүчеләр дә табылмады. Хәер, Көек-Ерыкса авылыннан Фәрхшатова Камәр апа “Ике туган бәете”н кайчандыр җырлаганнарын әйтте. Сүзләрен исенә төшерә алмады, әмма көен шыңшып күрсәтте. Аның көе Гражданнар сугышы елларында бик популяр булган рус халык көе

[1] Татар халык җырлары. Казан, 1965. Б. 345–346.

“Яблочка”ның татарчалаштырган варианты иде», – дип яза Җ. Фәйзи. Ул җырның сүзләрен «Татар халык җырлары» китабыннан алган.

«Кайдадыр шунда, шәһәр читендә» дип аталган җыр һәм «Ике туган бәете»нең эчтәлеге белән дә, строфаларының тәңгәллеге белән дә вариантлар булуына шигем калмады. Чөнки Р. Мозаффаровтан язып алынган бердәнбер куплеттагы:

*Мылтыгын сузып олы абыем*
*Кече абыйга каршы атлады.*
*Хәйлә-мәкерле бәләкәй абый*
*Кинжалы белән аңа кадады,* –

дигән юллар, аз гына үзгәреш белән, И. Надиров вариантында да кабатлана. «Кайдадыр шунда, шәһәр читендә» дип башланган сүзләргә карап та, бу җыр «Кирпичики» дигән рус халык җырының татарчага тәрҗемәсе түгелме икән? дигән сорау туа. «Кирпичики» җырын руслар да, башка милләтләр дә, шул исәптән татарлар да заманында бик яратып җырлаганнар бит.

Шулай да бу җырның татар халкына рус фольклорыннан керүе бәхәссез. Ул – А.М. Астахова тарафыннан Заонежьеда (Беломорское побережье) язып алынган «Два брата» җырының татарчалаштырылган варианты[1].

Чагыштырыр өчен җырның берничә строфасын бирәбез:

*Во селенье, в крестьянской избушке,*
*Жили мирно два брата с отцом.*
*Обожала их вся деревушка,*
*И хозяйства их был полон двор.*

[1] *Астахова А. М.* Фольклор гражданской войны // Советский фольклор. 1934, №1.

*Революция огненным пламенем*
*Пронеслась над миром грозой,*
*За свободу и волю народа*
*Но кровь проливалось рекой.*

*Отобрали лошадку, коровку,*
*Старший брат в рядовые ушел,*
*Дали младшему брату винтовку,*
*Добровольцем он к белым пошел.*

Югарыда әйтелгәннәрдән җырның гаять популяр булганлыгы аңлашыла. Бу дөрестән дә шулай. Мәсәлән, 1974 елны Казан артына оештырылган фәнни экспедиция вакытында Арча районы Олы Бәрәзә авылында да аның бер варианты табылды. Җырны башкаручы Сабитова Зәкия апаның (1919 елгы) әйтүенә караганда, «Кайдадыр шунда»ны Ватан сугышына кадәр сәхнәдә җырлаганнар.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре бу җырның төрле вариантларын әле дә очратып торалар. Бәеткә якын эпик эчтәлеге, татарга хас булмаган көе белән җырның хәзергәчә популяр булуы аңлашылып та бетми.

### ***Ихсиңер (Эбаргүл) авылы***

Ихсиңер авылына 7 июльдә килеп җиттек. Авыл зур түгел, нибары 55 хуҗалык бар. «Ленинская искра» исемендәге колхозга керә. Халык сөйләве буенча, биредә Ибәрде исемле кешенең нәселе яши.

Бу авылда **Бакиев Гайнулла абый** (1892 елгы) чынчынлап «җыр капчыгы» булып чыкты. Без аның башкаруында «Гүзәл хан мәчете», «Бүз егет», «Сәйфелмөлек» һ. б. җырлар һәм дастан назымнары язып алдык. Бу якларда борынгы дастаннарның өзекләре аерым җыр буларак халык телендә

яшәвен дәвам итә. Алар яңа яңгыраш алып, халык лирикасының бер өлеше буларак хезмәт итә! Ә бу бик тә әһәмиятле күренеш бит. Димәк, Себер – борынгы дастани моңнар – назымнар иле дә! Һәм безнең Көнбатыш Себернең саз – тайга – Тубыл – Иртеш – дала киңлекләрен айкап йөрүебез юкка түгел икән. Юкка түгел!

***Гүзәл хан мәчете***

*Чын хурлыкдай торсаң да син*
*Күп еллар буе, Казан,*
*Сөембикә манараңдау*
*Әйтелә бүген азан.*
*Сөембикә манараңдау*
*Әйтелә бүген азан.*

*Сөембикә базулари,*
*Киң сахраларда ятулары;*
*Бу кыюмәтләргә чумди*
*Шанлы татар гаскәри.*
*Бу кыюмәтләргә чумди*
*Шанлы татар гаскәри.*

*Әй, манара, шатлан бүген,*
*Шатлана торган көнең;*
*Инде синдә гает укый*
*Татар гаскәри бүген.*
*Инде синдә гает укый*
*Татар гаскәри бүген.*

*Әй, манара, ач пәрдәңне,*
*Кара монда бер багып;*
*Дошманнарның әлләрендин*[1]
*Алдык сәни без тартып.*

[1] Әл – кул.

*Дошманнарның әлләрендин*
*Алдык сәни без тартып.*

*Гүзәл хан мәчете.*
*Гайнулла Бакиев башкара*

***Бүз егет***

*Ник янасың, яшь йөрәгем,*
*Бу эшләр гади генәү;*
*Чөнки дуслар дус булалар,*
*Ак бәхет килсә генәү.*
*Чөнки дуслар дус булалар,*
*Ак бәхет килсә генәү.*

*Оныттыңмы зарифаңны*[1] *–*
*Төштә күргән ярыңны;*
*Әллә синең сөйгән ярың*
*Башка берәүне сөйдеме?*
*Әллә синең сөйгән ярың*
*Башка берәүне сөйдеме?*

*Мин сине көттем җиһанда,*
*Бүз егет, килалмадың;*
*Ничә тапкыр хат язсам да,*
*Урыныңнан кузгалмадың.*
*Ничә тапкыр хат язсам да,*
*Урыныңнан кузгалмадың.*

*Ташла, иргәм, ташла, иргәм,*
*Ташла, ташлыйсың килсә;*
*Мин сине шунда ташлыйм,*
*Тар каберләргә керсәм.*

[1] Зарифа – ягымлы, нәзакәтле, чибәр.

*Мин сине шунда ташлыйм,*
*Тар каберләргә керсәм.*

*Бүз егет.*
*Гайнулла Бакиев башкара*

Ихсиңердә дә туй-мәҗлес җырлары Савыргач һәм Зур Тибенде авылларындагы кебек үк, иң популяры «Җиктем күк юрга» икән. Аны безгә **Уразова Гайниҗамал мамай** (1916 елгы) җырлады. Бераз туй турында да сөйләп алды. Ә безгә таныш «Һаваларда йолдыз» җырын «Суда сусар» дип **Бакиев Ситдыйк абый** (1894 елгы) башкарды.

***Суда сусар***

*Сулар алдым, ай, таштин,*
*Сәүдәгәрләр булдыек яшьтин,*
*Сәүдәгәрләр булдыек яшьтин,*
*Айрылмаек каләм каштин.*
*Ауаларта ти йолтыс,*
*Ауаларта ти йолтыс,*
*Ничә лә баксам ла шунчадыр.*

«Сәйфелмөлек»нең бер вариантын Зур Тибендедә тапсак, Ихсиңердә аны Гайнулла абый белә икән. Аңардан язып алган вариант сүзләре белән дә, көе белән дә аерылып тора.

***Сәйфелмөлек***

*Яшел чарбан*[1] *эчендә гөл ярадды,*
*Мәне сайрап аны былбыл ярадды.*
*Мәнең сайрамагыл гөл яр эчендә,*
*Сәнең сайрамагың дидар эчендә.*

[1] Чарбан – фарсы сүзе, су каналлары белән дүрткә бүленгән бакча.

*Кара сачең төшәр микән йөзеңә,*
*Сәлам әйтсәм, йитәр мигән үзеңәү.*
*Каш астында кара күзең сөзеләү,*
*Сәне күрсәм, азиз җаным өзелә.*

*Азиз җаным, җәмалыңни*[1]*, гүзәлем,*
*Сәне күрмәй нихәл итеп түзәрмен.*
*Сәне сөйдем, кибеп калдым бәладән,*
*Рәхим әйләгән икәнсең мөдәтәләгә.*

*Бу сүзләрне китапта күргәнем бар,*
*Хыял бәндәнең арыскы*[2] *булды.*
*Сәне янда яраддың, мәне анда яраддың.*
*Арабызга мөхит дәрья*[3] *яраддың.*

*Сәйфелмөлек.*
*Гайнулла Бакиев башкара*

Ихсиңер авылында Бакиев Нәбиулла (1895 елгы, 73 яшьтә) скрипкада уйнады.

*Иске пасхуд*
*(Иске болын).*
*Скрикада Нәбиулла*
*Бакиев башкара*

*Авыл көе*
*(туй-мәҗлес көе).*
*Скрикада Нәбиулла*
*Бакиев башкара*

*Башмагым*
*(туй уены җыры).*
*Скрикада Нәбиулла*
*Бакиев башкара*

---

[1] Җәмал – матурлык, гүзәллек.
[2] Арыскы – ырыс сүзеннән, бәхет, шатлык.
[3] Мөхит дәрья – дөнья океаны.

*Карурман. Скрикада Нәбиулла Бакиев башкара*

*Шахта. Скрикада Нәбиулла Бакиев башкара*

*Авыл көе. Нәбиулла Бакиев скрипкада уйнап җырлый*

Экспедицияләрнең техник ягы да бар бит әле. Шуңа күрә әзерлек эшләре алдан ук башлана. Магнитофонны бик җентекләп, яхшылап карау, чистарту сорала. Моны бары радиоательеда гына эшләп була. Барлык кирәк-яракларны складтан алырга кирәк. Стационар аппаратлар өчен магнитофон тасмасы исә зур бабинка-тәгәрмәчләргә чорналган килеш килә. Шул озын тасманы кечкенә кассеталар өчен тураклыйсың. Күп вакытны ала һәм нервларны ашый торган эш бу. Ә кечкенә кассеталар складта юк, магазиннан үз акчаңа аласың.

Көнбатыш Себер өлкәләренең административ карталарын Фазыл абый Фәсиевтән алып тора идем. Ә карталарда татар авылларының күбесе юк. Экспедициядән кайткач, йөргән маршрут буенча отчётны шушы карта буенча бирәсең, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы баш бухгалтеры Антонин Епифанович үзе отчёт ала! Ул кулына линейка тотып, карта буенча авыллар арасын миллиметрлап үлчи һәм һәр сантиметрга өч тиен түли! Ул чорда командировочный акчасы авыл өчен – бер сум егерме дүрт тиен, шәһәр өчен ике сум кырык тиен исәбеннән түләнә иде.

Магнитофон тасмасы димәктән. Ф. Урманчеев экспедициягә магнитофонсыз гына чыга, димәк, ул складтан плёнка алмый. Без язып алган җыр, әкият һ. б. минем плёнкага языла бара. Мәсәлән, Омск өлкәсе Ихсиңер авылында Хамма-

тов Әхмәт бабайдан 20 әкият язып алдык! Бу турыда без «Социалистик Татарстан»да язып чыктык.

Бу язмаларны мин Фатихның үзенә тапшырдым.

### ***Илчебага авылы***

«Красный партизан» колхозы бу. 120 ләп йорттан тора. Әлегә без булган иң зур авыл. Заманында Илчебага авылы Иртеш буендарак урнашкан була, аннары шушы урынга күчә. Авылга 300–400 яшь булса кирәк, диде **Әминкаев Гарифулла абый** (1900 елгы).

Безгә кадәр Илчебагага соңгы 25 ел дәвамында Казаннан бер кеше дә килмәгән булган икән. Шуңа күрә авыл халкы безне бик зурлап каршы алды. Мәктәп директорының хатыны һәм Фатих Урманчеев Омск педагогия училищесында бер курста укыганнар булып чыкты. Килгән көнне кич белән алар безне кунакка алдылар.

Кунак икенче көнне дә дәвам итте. Авыл халкы безнең хөрмәткә, атап, сыер суйды. Мондый кадер-хөрмәтне бер генә фольклорчы да күрмәгәндер. 85 яшемне тутыргач, шуларны искә төшереп язып утырам.

Көндезләрен авыл буйлап йөреп, җыр-әкият язабыз. Кичләрен өч көн рәттән авыл клубында лекция һәм концерт оештырабыз. Тема бер – татар халык иҗаты. Фатих күзлегеен төзәтә-төзәтә сөйли, мин гармунда уйнап җырлыйм. Өч көн буена бер үк лекция, бер үк концерт – бер үк сүзләр, бер үк җырлар. Шуңа да карамастан, клуб көн саен шыгрым тулы. Илчебагада өч көн буе бәйрәм – җыр бәйрәме, халык иҗаты бәйрәме гөрләде.

Арып-талып өйгә кайтабыз. Безне пилмән пешереп каршылыйлар. Директор белән хатыны килә, тирә-як күршеләр керә. Мин яңадан баянны кулга алам. Иң беренче итеп «Сәрмән»не сызып җибәрәм. Таң ата, Иртеш буйлап гудокларын кычкырта-кычкырта пароходлар үтеп тора. Без тукталган йорт тәрәзәләре Иртешкә ачыла… Өстәлдә иң

кадерле кунакларга гына чыгарыла торган маринадлы чөгә балыгы. Аны кайбер авылларда кәреш дип тә атыйлар. Чөгә балыгы авызда эреп китә. Безнең Татарстан елгаларындагы стерлядь тәме белән башкарак иде.

Илчебага – үзенең шул исемдәге җыры белән бөтен татар дөньясына билгеле авыл. Җырны 1940 елны шагыйрь М. Садри Омск өлкәсенең Тәвриз районы Тау авылында «Илчебага (Курты) авылы җыры» дип язып ала. Башкаручы бу җырны Илчебага авылында туйда 1928 елны ишеткән була. Җырны без **Әйтбагин Уразмөхәммәттән** яздырдык. Ул аны 1928 елда Илчебага авылында туй вакытында ишеткән.

***Илчебага авылы җыры***

*Алма турыйм, алма турыйм,*
*Алманың түгәрәген, шул.*
*Хәзер нинди уй уйлыйсың,*
*Мәхәббәт күбәләгем?*
*Әй, һилләй, һилләлиләй,*
*Әй, һилләй, һилләли.*

Илчебаганың тагын бер җыры бар икән. Аны безгә **Хисмәтуллина Зөләйха апа** (1893 елгы, 75 яшьтә) җырлады. Авыл көе дип тә йөртелә икән ул.

***Авыл көе***

*Мин каеннар булса идем,*
*Кырыларда торса идем;*
*Их, мин ак каеннар булып,*
*Син болыт булып кунсаң!*

*Сикереп ментем тәрәскә*[1] *лә,*
*Гөл яфрагы кирәккә,*
*Гөл яфрагы дару диләр,*
*Ярсып янган йөрәккә.*

---

[1] Тәрәс – тәрәзә төбе.

Зөләйха мамайның тормыш юлы бик гыйбрәтле.

*Безнең әби-бабаларыбыз Бохара ягыннан килгәннәр. Үргәнч тигән шәһәртән. Үзебез монда туып-үскән. 11 яшемтә ятим калдым. 18 яшемтән тормышта тордым. Ирем өстемдән өч хатын алды. Берсен ала, анысы китә, икенчесен ала. Бер көндәшем белән биш ел тордык. Бер дә талашмадык. Үзе чыгып китте. Картым үлгәч, алты бала белән калтым. Шул балаларны укыттым, ак кәгазьне карага буярлык мәгълүмат бирдем.*

Бу авыл җыр-моңга аеруча бай. Зөләйха апа безгә тагын «Сагынам туган-үскән илемне» дигән җыр җырлады. **Хисаметдинов Шакирҗан абый** «Биек кенә тауның башлары» һәм Себердә киң таралган «Ак куяннар кача шар белән» («Кычкырма ла кәккүк»), **Шәрәпов Сөбәйер абый** (1918 елгы) «Ак тирмә буе» («Тәфтиләү»), **Сәетов Сөнгатулла абый** (1920 елгы) Җ. Фәйзинең «Нигә, нигә» җырын һәм хромка гармунында «Талы, талы», «Бишле бию» һ. б. уйнады. **Маматуллин Хәмидулла абый** (1921 елгы) «Тула басу көе», «Авыл көенә», «Җырны сатып алмыйм акчага», «Ай, милинкий», **Әминкәев Гарифулла абый** (1900 елгы) авыл турында бераз сөйләп, бик тә үзенчәлекле «Биек кенә тауның башларында» җырын җырлап, скрипкада «Галиябану» көен сыздырды.

Скрипкада яңгыраган көйләрне аудиоязмалардан музыка белгече Дания Арсланова нотага төшерде. Бу китапта әлеге ноталар беренче тапкыр тәкъдим ителә.

*Галиябану.*
*Скрипкада Гарифулла Әминкәев башкара*

## *Галиябану*





Һәр авылда без бик талантлы кешеләргә юлыгабыз. Илчебагада бу **Шәмсетдинов Салих бабай** (1897 елгы) булды. Ул – бездә иң тирән тәэсир калдырган әкиятче, бәетче, җырчы. Без аннан «Искәндәр әкияте», «Даниял» һәм «Куян һәм аучы» әкиятләрен ишеттек. Без әлеге информантыбыз турында болай дип язган идек: «Аннан язып алынган әкиятләр – төрле характердагы сюжетларны берләштергән миф, легенда, әкият сюжетларыннан торалар. Шул ук вакытта алар – мондый төрле элементларны органик рәвештә бергә оештырган катлаулы әсәрләр. Ул аларны бик оста сөйли, төрле персонажлар ролен башкарып, еш кына үзе дә шул әкият геройлары арасында йөри, алар белән сөйләшә, бәхәсләшә. Салих абыйны һич икеләнмичә әкиятче-артист дип әйтергә мөмкин»[1].

[1] *Урманчеев Ф., Мәхмүтов Х., Кадыйров И., Ибраһимов Н.* Себер энҗеләре // Социалистик Татарстан. 1968. 18 август.

Салих абыйдан берничә җыр да язып алдык: «Сап-сары», «Ак каен», «Сеңелесе әйтер тутасына». «Сап-сары» җыры «Яз да була» дигән мәгълүм җыр көенә башкарыла.

***Сеңелесе әйтер тутасына***

*Әй!..*
*Җилдертепкәй килеп ат бәйләтем,*
*Сеңелесе әйтер тутасына:*
*– Син түз, тутай, мин барыйм! – дип,*
*Имәнтин лә булсын ла касыгы-ай.*
*Имәнтин лә булсын ла касыгы-ай.*

*Ай, тимләмәс лә җиргә, ай, тимлиләр.*
*Сеңелесе әйтер тутасына:*
*–Син түз, тутай, мин барыйм! – дип,*
*Тимләүчегә булсын лай, ясыгый!*
*Тимләүчегә булсын лай, ясыгый!*

*Әй!..*
*Фәләнкәй лә тауның, әй, башынта,*
*Сеңелесе әйтер тутасына:*
*– Син түз, тутай, мин барыйм!– дип,*
*Нинтәй колхозның кыла карбусы.*
*Нинтәй генә бай колхозның карбусы.*

*Ак беләккәйләрен ястык итеп,*
*Сеңелесе әйтер тутасына:*
*– Син түз, тутай, мин барыйм! – дип,*
*Ята микән җаныем ялгызый.*
*Ята микән җаныем ялгызый.*

*Сеңелесе әйтер тутасына.*
*Салих Шәмсетдинов башкара*

Шәмсетдинов Салих абыйдан язып алынган «Ак каен» җыры Көнбатыш Себер татарлары арасында гаять киң таралган. Ул күренекле татар шагыйре Х. Туфан сүзләренә җырлана. Халык арасында икенче бер «Ак каен» дигән җыр да яши. Ул – башкорт композиторы М. Вәлиевнең татар шагыйре З. Ярмәки шигыренә 1926 елда язылган җыры. Шигырь 1915 елны «Ак юл» журналында басылып чыккан.

1968 елда без 8 кеше, өч отрядка бүленеп, Ишемтамак, Тәвриз, Знаменка һәм Тара районнарында булганбыз. Бу экспедиция турында «Себер энҗеләре» дигән мәкаләдә болай дип язган идек: «Безне – фольклор экспедициясе членнарын – үзебез булган районнарның географик һәм экономик хәленнән бигрәк, аларда яшәүче татарларның поэтик иҗаты күбрәк кызыксындырды. Бер айга якын вакыт эчендә без йөзләрчә кешеләр белән очраштык һәм аларның күңелләрендә саклanучы поэтик энҗеләрне, бер бөртеген дә югалтмыйча, җыеп алырга тырыштык. Без быелгы экспедициядән Институт фондына 51 әкият, 48 бәет, 215 лирик озын җыр, 2 меңнән артык кыска җыр, йөзләрчә мәкаль, табышмаклар, халык уеннары, йола, риваять һ. б. әсәрләр алып кайттык. Зур күләмле әсәрләр, нигездә, магнитофон тасмасына һәм стенография ярдәмендә язылды. Бу исә халык иҗаты әсәрләрен сөйләүченең яки җырлаучының үз интонациясе, үз стиле, диалекталь үзенчәлекләре белән язып алырга мөмкинлек бирде»[1].

Экспедиция вакытында язылган материалларның күбесе – традицион әсәрләр. Яшьләр татар халык көйләрен һәм җырларын бөтенләй белмиләр дип булмый. Ләкин татар җырлары һәм музыкасы акрынлап икенче планга күчә һәм бу табигый да. Татарча китап-журналлар бу якка сирәк һәм

---

[1] *Урманчеев Ф., Мәхмүтов Х., Кадыйров И., Ибраһимов Н.* Себер энҗеләре // Социалистик Татарстан. 1968 ел, 18 август.

бик аз килә. Безгә җыр, бәет, әкият яздырырга килүчеләр, гомумән авыл халкы, Казанга кайткач, язучыларга, композиторларга, артистларга мөрәҗәгать итеп, шул турыда әйтүебезне үтенделәр. Бу якларга алар килмиләр, күренмиләр икән. Артистлар аз, алар бар җиргә дә өлгерә алмыйлар. Авыллар да зур түгел, аралары да шактый ерак. Шуңа күрә монда, авыл халкының рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен, башка юллар эзләргә кирәк, күрәсең. Әйтик, безнең Казанда гына күпме үзешчән түгәрәкләр бар. 4–5 кешедән торган концерт бригадалары оештырып, алар Омскига һ. б. өлкәләргә җибәрелсә, бик файдалы эш булыр иде. Шулай ук Казан радиосы да бу юнәлештә бик күркәм бер эш эшли ала. Әйткәнебезчә, авыллар барысы да радиолаштырылган. Әгәр радиокомитет композиторлар әсәрләреннән һәм татар халык җырларыннан зур булмаган концертлар төзеп, аларны магнитофон тасмасында Омск яки Төмән радиокомитетларына җибәрсә, бу концертларны, билгеле бер расписание төзеп, өлкәдә яшәүче татар тыңлаучыларына ишеттерү кыен булмас. Бәлки, шушы мәсьәлә буенча аерым культура учреждениеләре тарафыннан шефлык оештыру формасы үзен аклар?

«Татарстан яшьләре» газетасының 1968 елдагы 10 декабрь санында минем «Кайда халык – шунда моң» дигән мәкаләм чыкты. Ул бик тә җылы сүзләр белән тәмамланган: «Себер татарлары музыканы бик яраталар, сабантуйлар, бәйрәмнәр һәм туйлар оста җырчы, скрипкачы һәм гармунчысыз үтмиләр.

Җыеп шуны әйтергә кирәк: Себер татарларының җырларын, бәетләрен, әкиятләрен һәм мәкаль-әйтемнәрен, гомумән этник группа булу ягыннан тикшерү фән өлкәсенә киләчәктә бик бай мирас өстәр».

1968 елгы беренче экспедициядә йөргәндә иң истә калган кешеләрнең берсе Савыргачтан **Абайдуллина Ураза Назыр**

**кызы** булды. Без Ураза мамайда фатирда тордык. Иртән иртүк безне тәмле коймак, кайнар чәй белән уята иде. Аның Гомәр Хәйям фикеренә тиң әйтеме бар: «Түшәк – тормышта бөек нәрсә ул!» Үзе дә безне мамык түшәктә генә йоклатты. «Казанга кайткач, сагынып сөйләрлек булсын!» – дия иде. Һәм шулай булды да. Фатих белән әле бик озак еллар, күрешкән саен, түшәк турындагы бу илаһи сүзләрне искә төшереп елмая идек. Урының җәннәттә булсын, Ураза мамай! Синең каймак, йомырка һәм балык пирогыңның тәмнәре әле дә онытылмый!

Балык пирогын бу якларда гаҗәп тәмле итеп пешерәләр! Бөтен балык, дөресрәге бер табага берничә балык салып пешерелгән бу пирогны иртнек яки эртнек дип атыйлар. Эртнекне табан балыктан пешерәләр. Тоз, борыч, суган һәм лавр яфрагы салып, әче камырдан пешерелгән шулпалы эртнекне ашап туеп булмый.

# ИКЕНЧЕ ЭКСПЕДИЦИЯ

## НОВОСИБИРСК ӨЛКӘСЕ
*(1968 елның сентябре)*

### Чаны районы

1968 елның сентябре бик матур килде. Без кыр экспедициясе белән Новосибирск өлкәсе Чаны районы Тармакүл, Кошкүл, Белекте авылларында Бараба татарларының җыр-көйләрен җыеп-яздырып йөрибез. Бу якларда 1940 елда шагыйрь М. Садри Тел, әдәбият һәм тарих институты һәм Казан музыка фольклоры кабинеты оештырган экспедиция вакытында фонографка «Карчыга, «Камыш» һ. б. җырлар яздырып алган.

Ул Себердән алып кайткан җырларын 1941 елның мартында ук профессиональ җырчыларга тапшырган да, алар Казан радиосыннан яңгырый башлаган. 2021 елның март аенда бу тарихи вакыйгага 80 ел булды.

Омск өлкәсен иңләп йөргәндә, Фатих Урманчеев миңа барабалар турында шактый күп сөйләде. Чөнки быелтыр, 1967 елны, бер төркем фольклорчылар Новосибирск өлкәсенең берничә районында Себер татарларын өйрәнеп кайтканнар иде. 1968 елның сентябрендә мин, ике дә уйламыйча, шул якларга – Новосибирск өлкәсенең Чаны районына юл тоттым.

#### ***Белекте авылы***

Чаны районында безнең экспедиция төркеме иң элек Белекте авылына килде.

Кечкенә генә авыл. Урамнар таррак. Йортлар уртача зурлыкта. Бу Омск өлкәсендәге Иртеш буйлары түгел шул инде. Таза йортлар бар барын, тик сирәк алар.

Дала, Бараба даласы. Тирә-якта күлләр бик күп. Бу якның бер үзенчәлеге ул. Авылның килеп чыгуы турындагы риваять буенча, борынгы заманнарда бу авыл урынында күл булган. Бу күл ярында бер ялгыз йорт урнашкан. Анда яшәгән кешене халык бик зирәк, акыллы дип белгән һәм бөтен эшне аның белән киңәшеп эшләгәннәр. Киңәшкә тирә-як авыллардан да килгәннәр. Ул тирәдә татарлар яшәгән, әлеге кешене татарча «Белекле» дип йөрткәннәр. Ягъни «күп белүче кеше». Вакытлар узу белән әлеге атама күлгә күчкән, аннан соң күл янындагы авыл да Белекле дип аталган. Тора-бара атама Белекте булып үзгәргән, рус теленә ул «Белехта» булып күчкән.

Мине Нәгыймә апа үзләренә сыендырды. Бик ачык ханым. Балалары читтә яши икән. Көн саен мин төшке ашка кайтуга күл балыгы белән шулпа пешереп куя. Кичен мин кибеттән конфет ала керәм. Тәмләп чәй эчә-эчә, ул миңа, назымы белән көйләп, «Мөлтәл» әкиятен сөйли, җырлап та ала. Мине Юсупова Шәмсенур һәм Хәсәнова Зәйтүнә апалар белән таныштырды. Нәгыймә апа фатир өчен түләргә дигән акчамны да алмады. «Синең бу хезмәтеңә әле без үзебез түләргә тиеш! Юл кешесенә акча артык булмый ул», – диде. «Синең бу хезмәтеңә!» – әлеге сүзләр йөрәгемә май булып яттылар. Себердә 49 авылда булып, көчемнән килгән кадәр тырышып, юллы-юлсыз җирләрдә җәфа чигеп, авыр магнитофон өстерәп йөргән бу фәкыйрегез аңа кадәр дә, аннан соң да үзенең хезмәтенә моннан да югары бәя ишеткәне булмады. Казанга кайткач, Нәгыймә апага матур гына бандероль юлладым.

**Әхмәтҗанова Нәгыймә апа** (1901 елгы) Белекте авылындагы беренче информантым да булды. Ул ашыкмый гына, бик тәмләп, яшь вакытларын искә төшерә-төшерә, «Йар-йар!»ны яздырды. Эшне төгәлләп, язманы яңадан тыңлап кына бетердек, **Юсупова Шәмсенур апа** (1900 елгы) килеп керде. Үзенең бераз карлыккан, ләкин тигез матур тембры белән «Тамчы тама» җырын җырлап бирде:

***Тамчы тама***

*Тамчы тама, тамчы тама,*
*Бөркән шәлең тамчий тамганчи,*
*Мин китәмен ерак сәфәрләргә,*
*Озатып кал күзең талгынчи.*
*Мин китәмен ерак сәфәрләргә,*
*Озатып кал күзең талгынчи.*

*Кыйбла яктин кара болыт чыгай,*
*Явар микән инди күкерәп.*
*Башларыма төшти зур хәсерәт,*
*Күтәрәлми минем күкерәк.*
*Башларыма төшти зур хәсерәт,*
*Күтәрәлми минем күкерәк.*

*Тамчы тама.*
*Шәмсенур Юсупова башкара*

Себер татарларының музыкаль фольклорын өйрәнгәндә кайбер бәхәсле җырлар да очрый. «Тамчы тама» шундыйлардан. Аның көе С. Габәши, В. Виноградов һәм Г. Әлмөхәммәтовның «Эшче» операсыннан Нигъмәт ариясе музыкасы белән тәңгәл килә. Җырлаучының әйтүенә караганда исә, бу көй авылда бик күптәннән, «бабайлар заманыннан» билгеле.

Көйнең Себердә бик популяр булуын чыгышы белән төп Себер татары **Тәминдаров Сәгыйрь** (1888–1975) дә раслады. Аның әйтүенчә, Кемерово өлкәсендә яшәүче калмаклар[1] бу җырны туй җыры буларак – яшь кәләшне кияү һәм нүгәр егетләре кияү өенә алып китәр алдыннан, кызның чәчен ике

[1] Татар халкының Кемерово һәм Томск өлкәсе авылларында яши торган зур булмаган этник төркеме.

толымга аерып үргәндә, кызны һәм җыелган барлык халыкны елатыр өчен җырлаганнар.

1969 елның көзендә узган экспедиция вакытында Кемерово өлкәсе Юрга районы Кышлау авылына бу фактны ачыклау өчен махсус бардык. С. Тәминдаров исә күрше Эскәтем авылында туган. Авылның иң олы кешесе 87 яшьлек **Шулаяков Гафур** «Кыз озату» җырын яздырды. Бу җырны ул яшь вакытта туйларда нүгәр егете булып җырлап йөргән икән. Димәк, җырның ким дигәндә алтмыш еллык гомере бар. «Эшче» операсы исә 1930 елны сәхнәгә куела. Бу көйне башкарак сүзләр белән яшьрәк буын вәкиле **Мансурова Нәкыя** (1904 елгы) дә башкара.

Әлеге көйнең Себер татарларында җырлануы – гаять кызыклы күренеш. Төптәнрәк уйлап карасаң, әлеге факт мәшһүр М. Глинканың «Музыканы халык тудыра, ә без, композиторлар, аңа бизәкләр генә өстибез», – дигән сүзләрен раслый кебек.

Нигъмәт ариясенең музыкасы турында С. Габәши язмалары билгеле түгел, һәрхәлдә, әлегә табылмаган. Шуңа күрә бу көйне Себер татарларыныкы дип өзеп әйтергә дә ашыкмыйк. С. Габәши – халык җырларын җыючы һәм өйрәнүче, музыкаль фольклорны гаять тирәнтен белгән кеше. Әгәр дә композитор үзе белгән һәм җыйган йөзләгән көйнең берсен операда файдалана икән, бу профессиональ музыка өлкәсендә табигый хәл санала. Күпвакыт автор көйнең кайдан алынуын да әйтеп тормый. Мәсәлән, Җ. Фәйзи 1952 елда Әлмәт шәһәрендә язып алынган «Сагынам» җырының көен «Тапшырылмаган хатлар» операсында Галия ариясендә генә файдаланып калмый, операның төп музыкаль лейтмотивы итә.

**Хәсәнова Зәйтүнә апа** (1928 елгы) «Иске көй» дип «Гөлбакча» һәм «Агыйделләр кичтем» җырын яздырды. Һәм Бараба даласының иң матур көй үрнәге – «Әйтүкә» җыры вариантларын җырлап күрсәтте:

*И... Буйны ла озын әй бус торына?*
*Әллә нигә төрле бузнайтыр ла.*
*Уйны[1] ла йөрдем, кырны ла йөрдем,*
*Мөкәтдәр[2] дә язмыштин узмайтыр ла.*

*И... Әтерне[3] лә тарытып укылар атытым*
*Кырда гына йөргән киекләргә.*
*Газиз генә башны хурлар кыйлып,*
*Дуып калыпсың киекләргә.*

**Сөнгатуллин Дәрҗеман абый** (1900) – данлыклы скрипкачы, Белектедә һәм башка авыллардагы туй-мәҗлесләрдә ул иң кирәкле кеше. Себер полькасы «Бабочка»ны ул әле дә искитмәле итеп сыздырып җибәрә!

***Сибирская полька-бабочка***




[1] Уй – уйсулык.
[2] Мөкәтдәр – язмыш.
[3] Әтер – җәя.



*Сибирская полька-бабочка.*
*Скрипкада Дәрҗеман Сөнгатуллин башкара*

Шунда ук «Әйтүкә» җырының көен дә кушып җибәрде. Барабаларда бер генә туй мәҗлесе дә бу җырчыдан башка үтми.

***Әйтүкә***



*Әйтүкә.*
*Скрипкада Дәрҗеман Сөнгатуллин башкара*

Мәҗлестә кунакларны сыйлаганда башкарыла торган «Гөл чәчәкләре» («Гөлбакча») көе дә шактый үзенчәлекле яңгырый. Тик Дәрҗеман абый аның сүзләрен хәтерли алмады.

Бераз көттергәч, Дәрҗеман абый «Казанны алу көе»н сыздырып җибәрде. Бу көйнең ике варианты бар икән. Берсе

кайгылы, икенчесе бераз җиңелчәрәк. Беренче көй борынгырак икән. Бу көйләр минем өчен зур табыш булды.

### ***Казанны алу көе***




*Казанны алу көе. Борынгы көй.*
*Скрипкада Дәрҗеман Сөнгатуллин башкара*

## *Казанны алу маршы*




*Казанны алу маршы.*
*Скрипкада Дәрҗеман Сөнгатуллин башкара*

## *Кошкүл авылы*

Авылның исеме үк кош-кортка бай күлләрне тасвирлый.

Кошкүлдә тирә-якта атаклы баянчы, курайчы һәм җыр остасы **Хәбибуллин Кәримулла абый** (1928 елгы) яши. Бу талантлы музыкант белән без тиз дуслаштык. Бик күп аудиоязмалар эшләп арыгач, бергә баянда уйный башладык. Өй тулы халыкка концерт куйдык. Шундый музыкантлар белән бөтен татар дөньясы тулган бит! Ә Кәримулла абый – барабаларның горурлыгы! Аның башкаруында «Гарифәкәй», «Шәрук» (баян белән җырлау), «Бер алманы бишкә бүләек», «Сандугач кара, муены ала», «Түбәтәй», «Мәскәү юлларында каенда» (курай белән), «Кара да гына елан», «Агаун», «Аяз да гына көнне», «Агыйделкәйләркәй, әй, камышы», «Хәнделдә гөлләр тамадыр», «Шәмшәриф», «Сак-Сок», «Сөмбел», «Урам көе» «Зәңгәр күлмәк», «Ак тәвә[1]», «Карлыгач» һ. б. җырлар Бараба татарларының музыкаль-поэтик иҗатын бөтен яклап диярлек колачлый.

Мин озак еллар Кәримулла абыйның хәлләрен белешеп тордым. 90 нчы елларда Новосибирскига баргач, махсус аның янына кереп тә чыктым. Ярты көн диярлек ерак еллар хатирәләрен яңартып утырдык.

### *Агаун*

*Әлмизәк күлмәге ал микән,*
*Аны алып кигән бар микән?*
*Агаун[2] коштай, әй, уйнаган*
*Ил өскәйләрендә бар микән?*

---

[1] Тәвә – дөя.
[2] Агаун – чәүкә.

*Агаун коштай, әй, уйнаган*
*Ил өскәйләрендә бар микән?*

*Агаун.*
*Кәримулла Хәбибуллин башкара*

## Курай

Себер киңлекләрендә курай тавышы да еш яңгыраган. Г. Курманов, И. Сөләйманов, К. Хәбибуллин аны әле дә курадан ясап уйныйлар. Алар әйтүенчә, элегрәк курайны бик күп ясаганнар. Ш. Курманов исә туйларда бик еш курайда уйнаганнарын хәтерли.

Курай Казан татарларында да гаять киң таралыш алган һәм халыкның борынгы милли уен коралы булып санала. Хәтта бу турыда табышмаклар да бар:

*Урманда кистем,*
*Эчен-бавырын уйдым,*
*Кабыргасын ике тиштем,*
*Әби көен ишеттем.*

Курай, шул исәптән Себер татарлары курае да, иң борынгы уен кораллары рәтенә куелырга тиеш.

Икенче информантым **Сәлимҗанов Гыйльман бабай (**1889 елгы) «Мулла Гали бәете», «Елашмагыз, туганнарым» һәм «Бараба җиренә күчкәндә Йәдүгәр мулла җыры»н яздырды. Гыйльман абыйның һәр җыры халык тарихының бер сәхифәсен яктырта. «Бараба җиренә күчкәндә Йәдүгәр мулла җыры»нда татар халкының, туган илен ташлап, билгесезлеккә чыгып китүе, бу күчешләрнең трагедиясе сүз

белән дә, көй белән дә шулкадәр тирән итеп ачыла, шул чорның, шул вакыйгаларның сулышын тоясың.

***Бараба җиренә күчкәндә***
***Йәдүгәр мулла җыры***

*Биек кенәй кырның, әй, башында*
*Борлыгадыр богдай орлыгы.*
*Карындаш тугандин, әй, айрылган,*
*Әй-хайы гынай дөньяның хурлыгы.*

*Бараба ла җире, әй, мал җире,*
*Беснең Сембер җире – ут җире;*
*Ут җире дә булса китмәс идем,*
*Бар да – бер Ходайның тәкъдире.*

*Утырдым чананың, әй, төбенәй,*
*Дилбегәй генәмне кулыма алып,*
*Өч мең чакрым җиргәй бән барамын,*
*Әҗәл генәемне кулыма алып.*

*Өч бубаска[1] йектем, әй, китәргә,*
*Барабай иленәй китәргә;*
*Туганнарым әйтми, әй, китәргәй,*
*Белмәймен үк нихәл итәргә.*

*Бараба җиренә күчкәндә...*
*Гыйльман Сәлимҗанов башкара*

Гыйльман бабайның әйтүенә караганда, бу – Себергә күчкән мишәрләр җыры. Йәдүгәр исемле мулла Сембердәге

[1] Бубаска – «повозка» сүзеннән.

бөтен бер авылны үзенә ияртеп, Бараба далаларына алып киткән. Татар халкының ил белән күченүләренең сәбәбе берничә: ачлык, җир җитмәү белән бәйле Столыпин реформасы һ. б. Каторгага җибәрелгән ирләре артыннан, кечкенәгә чанага яки арбага балаларын утыртып, җәяү Себергә чыгып киткән хатын-кызлар да аз түгел.

Гыйльман бабай янында 1961 елда ук танылган археограф һәм тарихчы галим Миркасыйм Госманов булып китә. Ул бу җырның сүзләрен «Бараба ла җире, әй, мал җире» дигән исем белән язып ала да «Совет әдәбияты» журналында (1962, 6 нчы сан) бастырып чыгара.

Бу авылда минем өчен **Мөхәммәтшин Аллаяр абый** зур табыш булды. Ул мине өйләренә үзе чакырды. Шаян, оптимист рухлы, уен-көлке яратучан бу абый үзе бер артист инде. Шулай булса да, бер җыры бик җитди булып чыкты аның. Ул Бараба татарларында кызны кияү йортына озатыр алдыннан җырланган махсус җырны белә икән. Бу – «Кыз озату җыры». Аллаяр абый сөйләве буенча, бу җырны кыз озату йоласында катнашкан теләсә кем, хәтта кәләш үзе дә җырларга мөмкин.

***Кыз озату җыры***

*Имәнчә туга, көрәң ат,*
*Тартыпы чай салар көчем йок;*
*Касис ләй башым эшкә төшкәч,*
*Йолыпы чай алыр кешем йок.*

*Алтын чай вийәр, көмеш каш,*
*Китеп лә барай газиз баш;*
*Китсә лә китсен, әй, газиз баш,*
*Исән-сау калсын карынташ.*

*Алтын чай көмеш – байларда,*
*Йомырча туйакы – тайларта.*

*Тай тигәнләрем, әй, ат пулты,*
*Үс туганларым ят пулты.*

Аллаяр абый 1894 елгы, аңа 74 яшь. Аның хатыны **Һава апа** да җырларга ярата икән. Аллаяр абый туй мәҗлесләрендә бик тә еш җырлана торган «Карама туга, кара йурга» җырын артистларча шаянлык белән җырлап күрсәтте.

***Карама туга, кара юрга***

*Юргалайтыр кибет алтынтау.*
*Пуе ла сифа пер матур кыс*
*Иркәләйтер егет алтынта.*
*Пуе ла сифа пер матур кыс*
*Иркәләйтер егет алтынта.*

*Карама туга, әй, җиз колча*[1]
*Шыңгыртайтыр тартып йеккәнтәй.*
*Аусы ла уймак, бите коймак,*
*Сулкылтайтыр суырып үпкәнтә.*
*Аусы ла уймак, бите коймак,*
*Сулкылтайтыр суырып үпкәнтә.*

*Агыйтелләрнең аръягынта*
*Селәүсеннәр*[2] *чыгар уенгау;*
*Селәүсен кебек матур ярлар*
*Качан керер песнен куенга.*
*Селәүсен кебек матур ярлар*
*Качан керер песнен куенга.*

*Һавата очкан ойа лачын,*
*Айасынта гөрли күгәрчен;*

[1] Колча – кыңгырау.
[2] Селәүсен – бал корты.

*Шул күгәрченнәр нигә гөрли,*
*Песнең кебек моңлый, күрәсең.*
*Шул күгәрченнәр нигә гөрли,*
*Песнең кебек моңлый, күрәсең.*

*Карама туга, кара юрга.*
*Аллаяр Мөхәммәтшин башкара*

Я Хода! Нинди талантлы минем халкым!

## ***Тармакүл авылы***

Институт тарафыннан оештырылган 1940 елгы фольклор экспедициясе составында Тармакүлгә М. Садри да килгән. Ул бу авылдагы табышлары турында болай дип яза: «Тармакүл авылында мин фонографка “Агыйделкәй”, “Юлбикә”, “Җаныем, сылуым, бибием”, “Карчыга”, “Әйтүкә җыры”, “Мансур җыры”, “Юнан җыры” һ. б. исемдәге барлыгы берсеннән-берсе матур, моңлы борынгы уналты көй язып алдым. Мондый җырларны минем бервакытта да, беркайчан да ишеткәнем юк иде... Тармакүлдә халыктан җырлар язып алу бик уңышлы булды... Аннары укытучылардан Гыйззәтуллин Ислам, Сираҗетдинов Даут, акушерка Мөхәррәмова Гөлшәйдә, Әхтәриев Нәфикъ иптәшләр җырладылар...»

Мин 1968 дә, 28 елдан соң, менә яңадан **Сираҗетдинов Даут абый** каршында утырам. Ул 40 нчы еллар турында дулкынланып сөйли, ә мин аңа шул елны аңардан М.Садри язып алган «Карчыга» һәм «Камыш көе»н җырлап күрсәтәм.

Бу ике җыр А. Ключаревның 1955 елда чыккан «Татар халык җырлары» китабында басылган иде. Моңа Даут абыйның бик күңеле булды. Казанга кайткач, М. Садрига кайнар сәламнәр тапшыруымны сорады.

Бер кешедән бер үк музыкаль әсәрне 28 елдан соң язып алу – музыка фольклористикасында сирәк очрый торган күренеш. Мин Мөхәммәт аганың эшен дә дәвам итәм бит әле!

Себер татарларының музыкаль-поэтик иҗатының 40 тан артык нөсхәсен валикларга язып алган һәм 1941 елның мартында инде Казан радиосы аша ул җырларны Г. Сөләйманова, М. Рахманкулова, М. Сафин, У. Әлмиев башкаруында татар дөньясына таныткан бу гаҗәп үзенчәлекле иҗат кешесе киләчәктә татар фольклористикасында дәрәҗәле урынын алырга тиеш. Кызганыч, Себердә аны белмиләр.

Сиражетдинов Даут абый шулай ук «Шәмшәриф», «Карлыгач», «Камыш җыры» һәм «Мәкәрҗә» җырларын яздырды.

*Шәмшәриф. Даут Сиражҗетдинов башкара*

*Карлыгач. Даут Сиражҗетдинов башкара*

*Камыш җыры. Даут Сиражҗетдинов башкара*

«Мәкәрҗә» – Тармакүл авылы халкының туй-мәҗлесләрдә яңгырата торган күркәм җыры. Даут абый үзе катнашкан мәҗлесләрдә аны әле дә, «тамашачылар» соравы буенча, бик рәхәтләнеп җырлый икән.

***Мәкәрҗә***

*Әй, дускаем, сиңа ниләр бирим,*
*Мәкәрҗәдин килгән ләй малым юк;*
*Йаннарымны җарып бирер идем,*
*Җандин башка яшәр лә хәлем юк.*

*Башкаеңа кигән түбәтәең,*
*Укаларын салып кем уйган?*
*Акылларың камил, буең зифай,*
*Исем-шәрифләреңне кем куйган?*

*Мәкәрҗә.*
*Даут Сиражетдинов башкара*

Җырның көе минем җаныма шулкадәр кереп урнашты ки, еллар узса да, мин әледән-әле ул җырны үзем генә моңаеп-боегып җырлап утырырга яратам.

Җыр көендә гомумтататар моңы бар. Меңләгән татар җырын күңел шүрлегенә менгезеп куйсам да, бик сирәкләре генә минем күземнән яшь китерә, фани дөнья мәшәкать-борчуларын сукыр бер тиенгә әйләндерә, музыкаль аһәңнең Күкләрдән иңгән бик тә көчле рухи дулкын икәненә ышандыра. Әдәби тел дә, сөйләм теле дә, хәтта югары шигърият тә андый тылсымлы көчкә ия түгел! Минем өчен бу! Мин шулай уйлыйм, шулай хис итәм. Мин теләсә кем белән бу турыда учак ягып бәхәсләшергә әзер. Менә бүген 2023 елның 8 августы. 83 яшьне тутырган башым белән, азапланып булса да, күрер-күрмәс күзләремне чекерәйтеп, сызлаган аякларымны әвеш-тәвеш китереп, авырткан билемне шәл белән бәйләп, миңа исләре дә китмәгән Себер татарлары турындагы истәлекләремне кәгазьгә төшереп утырам.

Даут абый мине, җитәкләп, **Ишмакова Нәкыя апаларга** алып керде. Заманында Даут абый – директор, Нәкыя апа укытучы һәм завуч булып эшләгән.

Нәкыя апа – бик тә үзенчәлекле шәхес. Гомеренең соңгы елларында ул үзенең кызлары тәрбиясендә Казанда яшәде. Һәм без Нәкыя апа белән нәкъ тә 50 елдан соң, 2019 елның 2 мартында аларның М. Латыйпов урамындагы шәхси йортларында очраштык. Нәкыя апа 1920 елның 23 февралендә туган. Инде 2020 елның 3 апрелендә 100 яшен тутырып вафат булды.

Себердә татар җыры турында бик тә күркәм, үзенә күрә бик тә фәлсәфи әйтем бар: «Җырын алалмадың – серен алалмадың!». Нәкыя апа да җырны «Күңел сере» дип атый.

Инде аз гына Нәкыя апа нәселе хакында да язып китим. Мишәр илендә Карюков Сөләйман яшәгән. Аңа 90 яшь булган. Улы Арикол 1773 елда Себердә Карсак ханлыгы җирләренә килә. Хәзерге Новосибирск өлкәсе Чаны районы Тармакүл авылы янындагы Иске Карачи тирәсе. Сөләйман абыйның икенче улы Ибраһим абыйсы Арикол эзләреннән Себергә 1812 елда килеп чыга. Очрашалар болар. Ибраһим Сөләйман бабасын уллары-оныклары белән, Петербург аша, Себергә күчерүгә ирешә. Нәтиҗәдә, 90 яшьлек Карюков Сөләйман бөтен нәселе белән Себергә килеп, мәҗүси төрки кабиләләр арасында төпләнә. Нәкыя апаның әтисе Кашшаф абзый Ибраһим шәехнең оныгы була. Әнисе – Чүмбәле мишәре Галиулла кызы. Бабасы Хәбибулла Иркутск приискаларында 12 еллык солдат хезмәте үтеп, Кушкүлдән, Мәңлегол байның чакыруы буенча, 1857 елда бирегә килеп урнаша.

Нәкыя апа 1940 елдан 1983 елга кадәр Тармакүлдә укытучы, завуч, директор, РОНОда татар мәктәпләре буенча инспектор була. Сугышка кадәр бер ел Омск рабфагында укып, соңрак Томск татар педучилищесын тәмамлый. Бик яхшы укыса да, мулла кызы булуы аркасында, аңа Казанга институтка керергә юллама бирмиләр.

1940 елгы Себер экспедициясендә катнашкан Сәет Әмиров аның укытучысы була.

Бу авылда Бараба далаларында киң таралган атаклы «Кузы Көрпәч белән Баян-сылу» дастаны белән беррәттән, Әйтүкә атлы җырчы исеме белән аталган тарихи җырны да бик кадерләп һәм яратып саклыйлар. Тырыш һәм курку белмәс Әйтүкәнең (тулы исеме Әйтмөхәммәт) Фатыйма атлы сөйгән кызы була. Әйтүкә аны, иркәләп, Батыш дип йөртә. Фатыйма – бай кызы. Әйтүкә исә – ярлы карчык улы. Фатыйманың әтисе кызын бай егеткә бирергә тели. Әмма мәхәббәткә киртәләр юк...

Нәкыя апа Ишмаковадан «Әйтүкә»нең дүрт җырын язып алдык.

***Әйтүкәнең беренче җыры***

*И, кызылгач дигән, ай, җимешнең,*
*Эче генә ташлы, тышы татлы.*
*Нәмдә генә сөйгән шул Батышның*
*Күңеле каты, теле лә татлы.*

*Әйтүкәнең беренче җыры.*
*Нәкыя Ишмакова башкара*

***Әйтүкәнең икенче җыры***

*И, йөгерә-йөгерә җитәлмадым,*
*Тал читәнне үтә алмадым.*
*Тал читәнне үтәр идем,*
*Сезне генә ташлап китә алмадым.*

*Әйтүкәнең икенче җыры.*
*Нәкыя Ишмакова башкара*

### *Әйтүкәнең өченче җыры*

*Чаң бәйләдем дугагызга,*
*Ат бәйләдем кубагызга.*
*Карап кына торып исем китте,*
*Алтын ыштуф укалы якагызга.*

*Әйтүкәнең өченче җыры.*
*Нәкыя Ишмакова башкара*

### *Әйтүкәнең дүртенче җыры*

*И муйны ла озын, әй, бус торна,*
*Әллә нигә телләп бузнайдыр ла.*
*Уйны да гына йөредем, кырны йөредем*
*Мәкаддәрдә язмыштан узмайдыр ла.*

*Ай, кышкы ла буран, язгы буран,*
*Тармаклы буен алган сорау.*
*Сез җаныем уйлый-уйлый*
*Исәндәй генә башым булды сырхау.*

*Ай, Ябышкан буе ярлар микән,*
*Барыпчала күргән барлар микән.*
*Газиз дә генә башны хурлар кыйлган*
*Ян сөйгән Батыш ярлар микән.*

*И урманда кәккүк әй чакырадыр,*
*Язын да көзен дә һич белмәйдер.*
*Халыек та безне күп сөйләйдер,*
*Хак язмышын һич белмәйдер.*

*Хай, ара-тала томан, бер дә томан.*
*Кайгы-хәсрәт белән эчкенәем тулган.*

*Кырып ла калсын көн дәүләте,*
*Исән дә генә булсын ил дәүләте.*

*И, ашаган чакта бал да татлы,*
*Сөешкән чакта яр да яхшы.*
*Башкайларыңа эшләр төшсә,*
*Сөйләшкән чакта тел дә яхшы.*

*Әйтүкәнең дүртенче җыры.*
*Нәкыя Ишмакова башкара*

Мин Бараба татарларының горурлыгы булган бу җырны Тармакүлдә **Ишмакова Нәкыядән** (1928 елгы), **Нургалиева Вәйдәдән** (1899 елгы), Белекте авылында **Хәсәнова Зәйтүнәдән** язып алдым.

2019 елның 2 мартында, беренче очрашуга 50 ел үткәч, Нәкыя апа диктофонга «Әйтүкә»не яңадан сөйләп бирде. Кайбер фрагментларын оныткан да булып чыкты. Ә шулай да кызыклы факт: нәкъ 50 елдан соң бер үк әсәр бер үк башкаручыдан язып алынды!

Нәкыя апа – шагыйрә дә, «Күңелдән узган моңнар» җыентыгы[1] авторы. Бу җыентыкта Нәкыя апаның «Әйтүкә-Батыш» (поэма) әсәре дә урын алган. 600 юллык поэма, Әйтүкә – Батыш мәхәббәтенең бәхетсез язмышы халык теленнән әдәби телгә күчә.

Бараба татарлары безгә талантлы җырчы Закир Шаһбанны бирде. Ходай кушса, бәлки, берәр драматургны да бүләк итәр. Менә шуннан «Әйтүкә» дип аталган драма, музыкаль драма яки трагедия язылыр.

---

[1] *Ишмакова Нәкыя.* Күңелдән узган моңнар. Казан, Экспресс-формат, 2009.

2019 елның 2 мартында Нәкыя апа миңа бүләк итеп биргән китабына болай дип язган:

«Бүләгем, хөрмәтле Илгиз туганкаем,
Озын гомернең таңыннан;
Тәкъдиреннән боерыкның,
Ядкәр булсын кулымнан!

Нәкыя апаң, чын күңелдән».

Нәкыя апа «Зәйнулла абый көе» дип, бик тә үзенчәлекле җыр яздырды.

***Зәйнулла абый көе***

*Келүсез йозак һәр киз[1] ачылмас,*
*Төкәнгән гомерем һәр киз озаймас.*
*Муйныма таккан кайгу җепләрем,*
*Текәнеп череп, һәр киз өзелмәс.*

*Ясин тәбәрәк һәрдаим телемдә,*
*Синең сыйфатың һәр киз күңлемдә.*
*Күңлем туйганчы күрмәгән идем,*
*Нигә дип әҗәл килде лә сиңа?*

*Хак Тәгаләмә ярдәм ялварам,*
*Кавыштырса иде җәннәттә безне.*
*Торый күпмегә инде безләргә?*
*Әҗәлгә бәндә чарасыз түзә.*

*Зәйнулла абый көе.*
*Нәкыя Ишмакова башкара*

[1] Киз – вакыт.

Казанга кайтып, магнитофон язмасын кәгазьгә сырлаганда, кайбер сүзләрнең мәгънәсен төгәлрәк ачыклау кирәклеге беленде. Шундый максат белән Нәкыя апага хат юлладым. Анда бу җырның кайчандыр барабалар арасында булган «Җырлап елау» йоласы калдыгы түгелме икәнлеген һәм кайдан килүен ачыклау мәсьәләсе дә күтәрелгән иде. Мондый җавап алдым:

«Бу җыр үлгән кешегә багышланган, билгеле. Ләкин безнең тирә татарларда “Җырлап елау” йоласын язычниклар гадәте, диләр. Ул юк. Авылга беренче килүчеләр – Сембер губернасы Петрякс авылыннан. Бу җырны чыгаручы – Петрякстан ерак булмаган Куйсуы авылыннан килгән Гөлҗәүһәр әби. Авылыннан чыгып китү вакыты – 1850 еллар».

Гөлҗәүһәр әбинең туган якларына әйләнеп кайтсак, ничек булыр икән? Танылган этномузыколог Эльмира Каюмова «Җаен белсәң, көе килә» мәкаләсендә (Түгәрәк уен. 2012. № 4) Түбән Новгород өлкәсе татар-мишәрләренең музыкаль фольклоры турында мәкалә бастыра, «Нижгар мишәрләре», «Сергач мишәрләре»нең 35 авылда тупланып яшәүләре һәм ул авылларда җыр мирасын барлавы турында сөйли.

Әйтергә теләгән фикеребез шул: Тармакүл авылы халкының көй-моңнары элекке Ватаннарыннан – хәзерге Түбән Новгород өлкәсе Сергач якларыннан ук килә икән. Мишәрбараба музыкаль бәйләнешләрен киләчәктә җентекләп тикшерүчеләр булыр дип ышанып калам.

Минем үземә дә төрле елларда мишәр татарларының берничә җыр үрнәгенә тап булырга туры килде. Түбән Новгород өлкәсенең «Туган як» татар мәдәни үзәгендә хезмәт куйган **Абтюкова Зөһрә ханым** (1933 елгы) миңа үзе башкаруында җырлар яздырылган магнитофон тасмасын бирде. Мин аларның кайберләрен нотага да төшердем. Мәсәлән, «Сабый киявем», «Әксән гылава» һ. б. Зөһрә ханым да Сергач ягыннан,

Камка авылында туган. Икенчесе – Пенза өлкәсе Сосновый Бор районы Индирка авылыннан Венера Еренеева башкаруында «Чияле тау» җырын язып алдым. Волгоград шәһәрендә Түбән Новгород кызы Рита Сәяповадан (Юнисова) «Әбтелмән купис» һәм «Яңа карурман» (Р. Ваһапов репертуарыннан) җырларын язып алу да насыйп булды. Рита ханым белән мине Волгоград өлкәсе милли-мәдәни мохтарияте активы Таифә Мостафина таныштырды. Рита Сәяпованың әнисе Сергач ягындагы Анды авылыннан, әтисе – Олы Рбишчадан. Менә шул Рбишчадан Нижгар базарына килгән авыл кешеләре Риталарга керә торган булганнар. Мишәрләрнең аеруча популяр «Әбтелмән купис» җырын шулардан отып алган да инде ул. Таифә ханым үзе дә – чепчи мишәр кызы. Әле дә телефоннан хәлен сорашсам: «Тиха гына!» – дип җавап бирә. «Җил басылды» дип әйтәсе урынга «Җил тихарды» ди.

Тармакүл турында бит сүзебез. Нәкыя апа беренче булып «Әйтүкә»не җырлап күрсәтте. Менә шушы мизгелдән мин асыл барабалар иҗатын сиземли башладым. Дастаннарга тиң мәхәббәт! Барабаларның атаклы «Кузы Көрпәч белән Баянсылу» дастаны, шулай ук «Асыл кошлар», «Агаун», «Кара да гына елан», «Йар-йар» кебек искитмәле җырлары белән беррәттән Әйтүкә атлы җырчы егет исеме белән аталган җыр да бик кадерләп саклана.

Көндәлеккә «Бүген 1968 елның 21 сентябре» дип язып куйганмын.

Нәкыя апа мине **Мөхәррәмов Сәмигулла абый** белән күрештерде. Аның бик кайгылы көннәре иде. Күптән түгел генә хатыны Гөлшәйдә вафат булган. Ә Сәмигулла абый бик ерак җирләрдә калган, кайтып җитә алмаган. Гөлшәйдә апа акушерка булган. М. Садри 1940 елда аның җырлавында «Агыйделкәй», «Юлбикә» җырларын язып алган булган. Сәмигулла абыйның да тавышы үзенчәлекле. «Әйтүкә»,

«Газизәкәй», «Җибәрик атларны», «Шиновой колесо», «Майор атлары», «Асыл кошлар» көенә «Керәшен көе»н, «Ташмөхәммәт абый җыры»н сөекле хатынын исенә төшерә-төшерә, вакыт-вакыт күңеле тулып, матур гына җырлап утырды. Менә бит тормыш ничек икән ул! Җыр җырлата да, елата да. Олы яшькә җиткән Сәмигулла абый ничек ялгыз гомер сөрер икән? Ни кызганыч, аның язмышын белә алмадым....Тик язмышлар кабатлана икән. Менә бүген 2023 елның 8 августы. Сәмигулла абый янында әле генә булдым кебек. Баксаң, 55 ел үтеп киткән. Менә мин дә 15 ел инде өйдә ялгызым. 1971 елда Түбән ягындагы Лайтамакларга бергәләп җырлар язарга барган Миңлегөлемсез яшәп ятам. Сәмигулла абый! Яшь вакытта хәлеңне аңламаганмын, ә бүген синең хәлеңдә мин...

***Иске җыр***

*Нурлы ды гына кояш, һай тулган ай,*
*Бу фани ла дөньяның күгентә.*
*Исемеңне лә әйтеп җырлап йөрим*
*Пик моңаеп йөргән лә көнемтә.*

*Пер алманы бишкә бүләек,*
*Перебез өчен перебез үләек.*
*Алты ат җикмәк, биш атлар тарталмый,*
*Нужа күрмәй ир-егет картаймай.*

**Нургалиева Вәйдә апа** беренче очрашканда минем белән теләр-теләмәс кенә сөйләште, бүген кәефем юк, иртәләргә берәр җыр әйтеп карармын әле, диде. Мин магнитофон тасмаларына язылган җырларның аңлашылмаган урыннарын сорарга дип Нәкыя апаларга юнәлдем. Аның кызлары тиз генә чәй өстәле әзерләделәр. Бик күңелле итеп утырдык. Мин аларга Казан җырларын җырладым. Кем уйлаган, шушы

Нәкыя апа һәм аның уңган-булган кызлары белән 50 елдан соң Казан каласында кабат күрешербез дип!

Ике көн буе Вәйдә апаның бетмәс-төкәнмәс җырларын магнитофоным «йотып» бара. Искиткеч моңлы тембр. Бераз гына калтырый калтыравын тавышы. Ул тавыш менә бүген дә әле колагымда чыңлап тора. Дала җиле сызгырган сыманрак тоела иде миңа, бигрәкләр югары. Инде күпме еллар үтсә дә, Вәйдә апаның беренче яздырган «Җаныем, Бибием» җырын мин әле дә җырлап йөрим. Мин аны Казан телевидениесендә 13 ел барган (1972–1985) «Халык җәүһәрләре» тапшыруында үзем берничә мәртәбә җырлап та күрсәттем.

Вәйдә апага 70 яшь иде, ул 1898 елгы. Авылның бик тә дәрәҗәле җырчысы. Без җырлар яздырып утырганда яныбызда бер кечкенә малай йөгереп йөргән икән. Кем дисезме: киләчәктә Татарстанның атказанган артисты булачак Закир Шаһбан! Аның да тавышы тембр ягыннан нәкъ әбисенеке төсле.

***Җаныем, Бибием***

*Ай яктылары бигрәке якты,*
*Җаныем, сылуым, Бибием,*
*Утырып ук мәрҗәнләр төзәргәй.*
*Анадин матур син туырсың,*
*Җаныем, сылуым, Бибием,*
*Эч-үзәккәйләремне өзәргә,*
*Эч-үзәккәйләремне өзәргә.*

*Талдин лай басма салар идем,*
*Тал тамыркайлары ла сурылмай,*
*Тал тамыркайлары ла сурылмай.*
*Сезнеңләү күңел белмим ничек,*
*Җаныем, сылуым, Бибием,*
*Безнең күңел сезләрдин сүрелмәй,*
*Безнең күңел сезләрдин сүрелмәй.*

*Ишегем алды буй-буй такта,*
*Берселәү имән лә, берсе – тал,*
*Берселәү имән лә, берсе – тал.*
*Әтием – шикәр, әнием – бал,*
*Җаныем, сылуым, Бибием,*
*Бал-шикәрдин яхшырак сөйгән яр,*
*Бал-шикәрдин татлырак сөйгән яр.*

*Җаныем, Бибием.*
*Вәйдә Нургалиева башкара*

Нургалиева Вәйдә апа миңа түбәндәге җырларны яздырды: «Җаныем, Бибием», «Кызлар шәл яулыгы», «Бәдрелхәят», «Бакча эчләрендә», «Әсмабибкәй», «Ай яктысы», «Кара юрга» (Карчыга), «Әйтүкәнең икенче җыры», «Хәнделдә[1] шәмнәр янадыр», «Ак каен», «Керәшеннәр җыры», «Тәфтиләү», «Мөхәррәм мулла бәете», «Зиләйлүк», «Агаун» һ. б.

Вәйдә апаның тагын бер җыры озын көйгә башкарыла. Бу як кешеләрен солдат хезмәтенә алмаганнар. Шулай да 1917 елда бик күпләрне Рига шәһәре янында окоплар казырга җибәргәннәр. Шулар чыгарган җыр икән бу:

*Биек тә генәй биек керәлицамда*
*Самауырлар кайнайдыр җил берлән,*
*Әй, самауырлар кайнайдыр җил белән,*
*Шул самауырлар кайнап, чәйләр бешкәч,*
*Без эчәрбез шул чәйне кем берлән,*
*Әй, без эчәрбез шул чәйне кем берлән?*

[1] Хәндел – шәмдәл.

«Ак тәвәләр» (Ак дөяләр) дигән җырны 1845 еллар тирәсендә Тармакүлнең Фәннән атлы кешесе чыгарган. Бу сүзләрне Ишмакова Нәкыя апа да раслады.

***Ак тәвәләр***

*Ак тәвәләр килә бит, әй, пуснашып,*
*Путалары калгандыр бәйләнеп.*
*Ак тәвәләр кебеке пуснашсак та,*
*Үткән гомер килмәс бит әйләнеп.*

Ерак Бохаралардан мал-мөлкәт төяп килүче кәрваннарны онытмый Себер иле.

«Гарифәкәй» җыры мәхәббәт җыры, гашыйк булган егетнең хис-кичерешләрен бәян итә:

***Гарифәкәй***

*Тау аскайларында, әй, бөрлегән,*
*Гарифәкәем, сылуым,*
*Тау өскәйләрендә ләй, карлыган.*
*Шул карлыганнарны җыя-җыя,*
*Гарифәкәем, сылуым,*
*Буен сумлык*[1] *төшерәй калдырдым.*

Тагын бер иске көйне Тармакүлдән Хәлил җырлаган икән:

*Челтерләй челтере сулар ага,*
*Җенҗү-мәрежән ташина кагынып.*
*Кәлам ләү алып хатлары яздым,*
*Бинипая сезләргә сагынып.*

Вәйдә апа әйтүенә караганда, бу җыр исә кайсы яктандыр килгән булырга тиеш:

*Биек тауның башында*
*Бер йорт тора, аппагым,*

---

[1] Буй сумлык, буен сумлык – муенга таккан тәңкәләр.

*Сигез тәрәзәле ул,*
*Бигерәк матур берсе кантур.*
*Килгәндин бирле генә*
*Карап торам, аппагым,*
*Нәселегез белән үк,*
*Алтын алмам, бик матур!*

1968 ел.

Институтта эшли башлагач, мин беренче мәкаләмне язарга керештем. Аңа «Үзешчән композиторлар иҗаты» дип исем бирдем. Экспедициядә вакытта Фатих аны төзәткәләп, тәртипкә китереп тә бирде. Кайту белән «Социалистик Татарстан» газетасына кертеп бирдем. Әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире Рәшит Гарипов һәм шагыйрь Миргалим Харисов хуплап алып калдылар. Тик мәкалә күренмәде.



Казан телевидениесендә Себер татарлары җырларына багышланган тапшыруда катнашучылар

Күп еллардан соң гына, Рәшит миңа мәкаләнең серен чиште. Бер профессиональ композитор мәкаләне укып чыгып, «Бу егеткә иртәрәк әле болай язарга» дип бәя биргән икән. Мәкаләнең ахырында Сара Садыйкова, Фәтхерахман Әхмәдиев, Ифрат Хисамов, Зиннур Гыйбадуллин, Арыслан Батыршин һ. б. җыр сәнгатендәге урыннарына югары бәя бирелгән иде.

Мин язуымны дәвам иттем, соңрак шушы газетада гына 30 га якын мәкаләм дөнья күрде. Гонорарларның да мул түләнгән чоры иде.

1968 ел ахырында Казан телевидениесе аша Себер татарлары халык иҗатына багышланган беренче зур махсус тапшыру булды. Фатих Урманчеев, Хуҗиәхмәт Мәхмүтов белән бергәләп бик озаклап һәм җентекләп әзерләндек. Сценарийны да бергә яздык. Мин музыкага кагылышлы өлешен эшләдем. Тапшыруның режиссёры Клара Газизова, әдәби редакторы Эльс Гаделев, режиссёр ярдәмчесе Дания Гаязова, тавыш операторы Наил Сабиров булдылар. Тапшыру гаять уңышлы килеп чыкты. Җырлар белән беррәттән «Кузы Көрпәч белән Баян-сылу» дастаныннан бер күренешне Ринат Таҗетдинов белән Әнвәр Гобәйдуллин уйнап күрсәттеләр.

## Куйбышев районы

### *Яргүл (Яркүл) авылы*

Куйбышев районында урнашкан Яргүл авылының исеме үзенчәлекле. Ул рус телендә Бергуль булып, бер күл дигән мәгънгә ия. Татар телендә исә бу авыл исеме яр һәм күл сүзләреннән ясалган.

Мине Яргүлдә **Тимганова Талига апа** (1921 елгы) янына алып бардылар. Ул сөйләгән «Мөлтәл» экиятен һәм «Колган байның кызы идем» экиятенең көйләрен тиз генә магнитофон тасмасына яздырып алдым. Экспедициядән кайткач,

«Мөлтәл» әкиятен фольклорчы Флора ханым Әхмәтовага күрсәттем. Ул да әкиятне Талига апа башкаруында 1967 елда язып алган булган икән. Тиздән әкият «Ялкын» журналының 1969 елдагы 6 нчы санында дөнья күрде.

Талига апа үз авылында популяр бөтен җырларны белә икән. «Әкәчә-Шәкәчә», «Камалигә бар туры» дигән шаян җырларны, «Агаун», «Әйтүкә» һ. б. җырларны яздыру көне буена сузылды.

Яргүл авылында **Байкова Зөһрә апа** (1900 елгы, 72 яшьтә) «Асыл кошлар» дигән җыр һәм «Кузы Көрпәч белән Баян-сылу» дастаныннан назым җырлады.

*Асыл кошлар.*
*Зөһрә Байкова башкара*

*«Кузы Көрпәч белән Баян-сылу» дастаныннан назым.*
*Зөһрә Байкова башкара*

Бу төбәктә яшәгән информантларыбыз сөйләве буенча, *типсәү* сүзе туй йолалары вакытында уйный торган музыка уен коралын гына түгел, туй мәҗлесенең кияү килгәч уздырыла торган этабын да белдерә.

Бараба якларында кияү егете килгәч, ике якның да туганнары бергә җыелып, кунак мәҗлесе үткәрелә. Бу мәҗлесне типсәү дип йөртәләр. Ирләр бер урында, хатын-кызлар аерым урында типсәү ясыйлар: уйныйлар, җырлыйлар, бииләр. Егет белән кызны аерым урынга ябып куялар. Монда яшьләр, бала-чагалар булмый. Кайбер якта исерткеч эчемлекләр куелган, кайбер якларда бу тыелган. Кодаларны сыйларга мул та-

бын әзерләнгән. Мәсәлән, Куйбышев районы Яргүл авылында махсус куй суйганнар. Кодалар да, кунаклар да буш кул белән килмәгән, бүләкләр күп булган. Бу мәҗлесне «акчалы чәй» дип тә атаганнар. Типсәүдән соң инде кыз ягы туганнары, чиратлашып, үзләренә чәйгә чакыра башлыйлар.

Типсәүдә җыр күп булган. «Тәфтиләү», «Әйтүкә»не бер мәҗлестә дә җырламый калмаганнар.

Мәҗлестә кодаларга шәраб коеп йөрүче булган, аны Аякчы дип атаганнар. «Аяк кайтару» – шәраблы чокырларны алмашу, шул вакытта җырлап бирү ул.

## ӨЧЕНЧЕ ЭКСПЕДИЦИЯ

ОМСК ӨЛКӘСЕ
*(1969 елның 14 июне – 1 июле)*

### Большеречье районы

#### *Үләнкүл авылы*

1968 елның көзендә Бараба далаларының бер өлешен айкап кайткач, мин Себердә яшәүче татарларның сөйләшен, тел үзенчәлекләрен бераз аңлый башладым кебек. Магнитофон тасмаларындагы җыр-көйләр дә бераз күңелгә сеңә башладылар. Көйләрне нотага төшерү эше дә уңай гына бара кебек. Тик озын көйләрне «иярләү» шактый авыр. Моның сәбәпләре бик күп. Авыл җырчылары метро-ритм дигән нәрсәләрне уйлап та карамый, аларга исе дә китми – күңелләре ничек куша, шулай җырлый. Ә без шул көйне артыннан этә-төртә нота станы дип аталган калыпка салырга азапланабыз.

Быел да без Фатих Урманчеев белән бер төркемдә. Язмаларны Большеречье районы Үләнкүл авылыннан башладык.

Авыл советы да биредә урнашкан. Үләнкүл Омскидан 350 чакрым чамасы ераклыкта, төньякта урнашкан. Омск өлкәсендә 50 дән артык татар авылы бар икән. Курносовский авыл советына кергән Куйгалы авылында – 93 хуҗалык, Чабаклыга кергән Яланкүлдә – 100, Аубатканда – 42, Кумыслыда 30 хуҗалык бар. Ә Үләнкүл авыл советына кергән Каракүлдә – 52, Тусказанда – 82, Чорналыда – 76, Үләнкүлнең үзендә 158 хуҗалык исәпләнә.

Кичкә таба гына, арып-талып, Үләнкүл авылына килеп җиттек. Фатир табу кыенрак булды. Мин җырчы Рабига апа-

ның танышларына урнаштым. Фатихны авылның икенче очына алып киттеләр.

Үләнкүл шактый зур авыл. 1939 елдан бирле авылда урта мәктәп эшләп килә. Килүгә, беренче эш итеп, анда кереп танышып чыктык. Фатих үзе дә педучилище һәм пединститут бетергән кеше, мин дә пединститут тәмамладым. Шуңа күрә педагоглар белән бик тиз уртак тел таптык. Директорлары – Зәлифә Рахмангулова. Татар теле дәресләре барлык классларда да бар. Искерәк дәреслекләр белән булса да тәэмин ителгәннәр. Үзебез алып килгән берничә китапны бүләк итеп калдырдык. Балалар татарча бик матур сөйләшәләр. Укытучыларның сөйләме әдәби телгә якын булса, балаларның сөйләме диалекталь үзенчәлекләрне яхшы саклый.

Халык бай, таза тормыш белән яши. Тирә-якта урман. Яшәү өчен бөтен мөмкинлекләр бар. Һәр өй алдында әрдәнә-әрдәнә итеп кышка җитәрлек утын ярып, өеп куелган. Өйләр төзек, зур һәм күп тәрәзәле.

Авыл халкы үзләренең динле һәм укымышлы борынгы бохаралыларның варислары булуын горурланып сөйли. Бик борынгы нәселләр байтак, шуларның берсе – Шиховлар.

Ниязов Муса абый, Мөхәммәтова Рәҗия апа, Чумарова Наҗия апа безне өйләренә чакырып чәйләп чыгардылар.

Аш-суга бик оста үзләре. Төп ризык – ит. Ат ите, сарык ите, куян һәм поши итләре пешерәләр. Итле шулпа әзерлиләр. Аңа онаш, безнеңчә кулдан киселгән токмач, кайвакыт умач уып салалар. Ашны урамда ачык һавада казан асып та пешерәләр. Сөт кушып, йомырка өстәп, оннан пешерелгән пәтер безнең ипи кебегрәк. Шәңгә дә бик тәмле. Аны эремчек, бәрәңге яки кишердән әзерлиләр.

Иң истәлеклесе – Үләнкүлгә без Хәмит ага Ярми һәм Халидә апа Гатина – татар фольклористикасы корифейлары белән бергә килеп төштек. Алар белән һәр аралашу – үзе зур мәктәп. Мин Халидә апа янына кереп утырдым. Ул

сөйләүчене үзенең авызына каратып, матур гына елмаеп, йомак сөйләтеп утыра. Стенография алымы белән, кәкре-бөкре таякчыклар белән язып барырга да өлгерә. Менә шунда Халидә апа белән татар халкының җырлы-биюле уеннарын ноталары белән эшләрбез дип план кордык. Кызганыч, шулкадәр кирәкле эш сүздә генә калды.

Бүген 1969 елның 14 июне. Без **Рәшитова Рабига ападан** (1903 елгы) җырлар яздырабыз. Ул үзе оста әкиятче дә икән. «Мескен Гайшә бәете», «Авыл көе», «Йар-йар!» җыркөйләрен яздырып алдык. Һәм бер әкият тә сөйләде әле ул.

***Йар-йар!***

*Вый! Җемеҗем җан, җилвандин,*
*Сәнең дәртең – гамеңдин.*
*Диванамын, йар-йар!*
*Йар хәтерен белмәгән,*
*Калыр ялгыз, йар-йар!*

*Йар-йар.*
*Рабига Рәшитова башкара*

Җырның көе үзенең интонацион-лад төзелеше белән безнең былтыр Усть-Ишим районында язып алынган «Йар-йар!» җырларыннан аерылып тора. Күрәсең, әлеге нөсхә – бу якларга килгән бохаралылар иҗаты җимешедер.

Рабига апаның «Авыл көе» исә – татар халкының без барыбыз да белгән, яраткан «Мәк чәчәге» көе. Ә бәлкем ул татар дөньясына ерак Себердән таралгандыр? «Юк!» – дип кистереп әйтүчеләр дә табылыр, мин уйлап карар идем әле.

Рабига апа үзенең тормышы турында да сөйләп алды. «Минем күргәнем йөкле чанадан да авыр», – ди ул.

## *Тусказан авылы*

Тусказанда җырчы-әкиятче-дастанчыларны табарга һәм танышырга 7 нче классны тәмамлаган **Курманова Фәрзинә** белән 8 нче классны бетергән **Латыйпова Бану** ярдәм иттеләр. Алар безнең магнитофонга «Беренче мәхәббәт» (С. Садыйкова көе) җырын да истәлеккә дип яздырдылар. Күптән түгел мин аларны үзем эзләп таптым – 52 елдан соң!

Бу болай булды. 2021 елда Омскидагы «Издательский дом “Наука”»да Асия Назыйрованың «Деревня Тусказань – сибирская жемчужина» исемле китабы дөнья күрде. Китапны Казанга Омскидагы күптәнге танышым, Өлкә татар милли хәрәкәтендә иң актив кызларның берсе – Розалия Сайганова почта аша җибәрде. Рәхмәт аңа! Халыкка хезмәт итүче кешеләрнең юк-бар акчалары шундый эшләргә китеп бетә инде ул...

«Хөрмәтле Илгиз абыйга Себер киңлекләрендә сәяхәт иткән вакытларының хатирәсе итеп, миннән бүләк булсын», дип язылган иде китапка.



Тусказан авылында. Уңнан икенче Корманов Шәриф абый, унда хатыны Хафаза, сулдан икенче Корманов Хәлилрахман. 1969 ел

Мин Асия ханым белән телефон аша элемтәгә кердем. Ул миңа Фәрзинә һәм Бану ханымнарның телефоннарын табып бирде, рәхмәт төшкере!

Асия Җәмил кызы Тусказан авылында гомер буе балалар укыткан. Ул – Назыйров Әхмәтгали абыйның килене, Назыйров Нариманның хатыны.

**Корманов Шәриф абый** (1889 елгы) үзен чын бохаралы дип атады. Ул «Бүз егет» һәм «Таһир – Зөһрә»ләрне бер дә ашыкмыйча, бик тәмләп сөйләп бирде. «Бүз егет»нең җиде көе – назымы бар икән: «Йар-йар!», «Бүз егет җыры», «Бәетназым», «Куплет», «Бәет», «Икенче бәет», «Назым».

***«Бүз егет» тән назым***

*Хуш, рөхсәтсез, кәрваннар,*
*Сау-сәламәт җиткәнсез;*
*Әтине дә күргәйсез,*
*Әнине дә күргәйсез, диде,*
*Бездән сәлам диярсез, диде.*
*Күрсәң, сәлам әйтегез,*
*Аман булың, дусларым,*
*Аман булсак, кайтырбыз,*
*Исән булсак, кайтырбыз,*
*Күрсәк, сәлам әйтербез.*
*Аман булың, дусларым,*
*Исән булың, дусларым! – дип,*
*Хушлашып китте инде...*

Көй нигезендә борынгы лад формаларының берсе – секста киңлегендәге тетрахорд ята.

Шәриф абый – бик күңелле карт. Аңа берничек тә 80 яшьне биреп булмый. Ул Бөек Ватан сугышы ветераны. Кышын аның кичләр буе сөйләгән әкиятләрен тыңларга урамның бөтен бала-чагасы җыела торган булган.

***Кил, икәү утырыйк***




*Кил, икәү утырып җыр җырлаек,*
*Килешерләй микән көебез?*
*Ник килешмәсен, ай, көебез,*
*Сахраларда үскән буебыз.*

*Утырсаң, кунак, ай, урныңа,*
*Бал бирәмен ике кулыңа;*
*Яшь үлән булып үсәр идем*
*Бер басып ла киткән юлыңа.*

дип, безнең хөрмәткә дә җырлап алды ул.

Чәмбәр

Шәриф Корман улы әле «колотушка», ягъни тукмак белән бәреп уйный торган ***чәмбәр*** дип аталган уен коралы булуын

хәтерли. Формасы белән ул алдарак искә алынган төңгергә охшаган икән. Аңа бозау тиресе тарттырганнар. Ян-ягында божралары да бар. Шунысы кызык, муллалар чәмбәрдә уйнауны да тыйганнар, бары тик балаларны сөннәткә утырткан вакытта гына уйнарга рөхсәт бирелгән. Күрәсең, ислам диненә кадәрге чорларда Себер татарларының үз җирле йолалары белән бәйле бәреп уйнау коралларын юкка чыгару яки тулысынча тыю мөмкин булмаган. Шунысы игътибарга лаек: бу уен коралы турында башка җирдә белмиләр диярлек.

### Цимбал

Шәриф абый, икенче бер уен коралы – **цимбал** турында да сөйләде. Билгеле, ул хәзер сакланмаган. Цимбал өстәл озынлыгында булып, аңа 50 дән артык кыл тартканнар. Кызыл агачтан эшләнгән кечкенә таяк белән бәреп уйнаганнар. Әле күптән түгел Чүплекүл авылыннан Хәйбулла атлы кеше цимбалда скрипкага кушылып уйнаган.

Бәлкем цимбалны бу якларга үзен чын бохаралы дип йөртүче Корманов Шәриф Корман улының ерак бабалары алып килгәннәрдер. Бу уен коралы Көнчыгыш Европа илләрендә Белоруссия, Украина, Молдова, Венгрия һәм башка җирләрдә таралган.

Тусказан авылының үз көе бар. Аны **Корманов Хәлилрахман абый** (1928 елгы) башкарды.

***Тусказан көе***






*Биек тауыга менегән чакыта*
*Тайымас итеке булысаый[и]кәне лә.*
*Дусылар белән утырыганда,*
*Таң атымасы киче булсыйкән.*

*Эзләдем мин, табалмадым*
*Күлмәгемнең ишләрен лә.*
*Мин гомеремнең буйыларына*
*Онытал[ы]масамы нишләрмен?*

Ә «Ал була микән» җыры безгә мәгълүм «Сания апай» җырын хәтерләтә кебек.

Безгә Хәлилрахман абый башкарган «Картлар көе» аеруча ошады. Көе Себердә шактый популяр «Мостафа мулла»нықына ошап китә.

*Очкырлы агач мин юндым*
*Ян тәрәзәләргә терәүгә.*
*Төшемдә күреп гашыйк булдым*
*Гөлмөбәрәк йөсле берәүгә.*

Ул «Сарман» җырын да бик еш җырлый икән. «Кара урман» көенә «Шәмшәриф» дип тә җырлап җибәрде:

*Шәмшәриф дигән шәһәрнең*
*Кич ахшамсыз капка ябылмас.*
*Алма нурланадыр кызаргач,*
*Егет тәүфикъланa, кыз алгач.*

Бараба далаларында популяр «Күк юрга» җырын да башкарды Хәлилрахман абый:

*Атлый-туктый күк юрга,*
*Сау-сәламәт булыгыз күп елга!*

**Назыров Әхмәтгали Таһир улы** 1916 елда Форпост авылында туган. Сугышта катнашкан, яраланган, Дан ордены кавалеры, «За отвагу» медале алган. Сугыштан соң чирәм җирләрне үзләштерүдә катнашкан. Без килгәндә тракторчы булып эшли иде. Әхмәтгали абый безгә «Олы Күл көе», «Карлыгач» һәм «Кил, икәү утырыйк» җырларын башкарды.

**Фәхретдинов Бәшир (Басыйр) бабай** (1895 елгы) Бөек Ватан сугышында катнашкан, Берлинга кадәр барып җиткән, кулы яраланган. Ул безгә әкият-дастаннар яздырды. Үзен бохаралы дип саный, татарча чиста сөйләшә. Дастаннарны назымнары белән әйтә, ә бу безнең өчен бик тә әһәмиятле.

1899 елгы **Шихова Гарифә апа «**Хәсрәт» көен бик йомшак тавыш белән әйтеп бирде:

***Хәсрәт***

*Хәсерәт хәсерәткә охшамый,*
*Хәсерәт ур(ы)ны бушамый;*
*Кайда барсам да хәсерәт –*
*Минем хәсрәткә охшамый.*

*Алма бирдем, ашадың ла,*
*Кабыгын кемгә ташладың?*
*Әвәлен үзең башладың,*
*Ахырын кемгә ташладың?*

*Алмагачым алаша ла (тәбәнәк),*
*Мин тураем, син аша;*
*Янган-янсын, көйгән-көйсен,*
*Кил, утыраек янаша.*

«Агыйдел кичтем» җыры да шундый ук рухта булып чыкты.

*Агыйдел кичтем, әй, саендин,*
*Ишкеләрен ярдым каендин.*
*Сырхау ла ятып саргаймадым,*
*Мин саргайдым, бәгърем, кайгыдин.*

«Хәсрәт» көен мин әледән-әле искә төшереп алам, юктан гына бар булган көй түгел бит ул. Себердә җил карагайнарат башыннан йөрсә, безнең тирәдә агач башыннан йөри. Ә кайгы-хәсрәтне әйтәсе дә юк...

## Муромцево районы

### ***Юртбиргамак авылы***

Чираттагы авыл – Муромцево районында урнашкан Юртбиргамак авылы. Биредә Пенза, Рязань ягыннан күченгән татарлар яши.

Юртбиргамакта «Мөсәлимә көе» дип йөртелгән бик матур бер җыр бар икән. Җырлар турында сүз чыгуга, иң элек шуны искә төшерәләр. Җырны **Ташилова Мөсәлимә апа** (1922 елгы) үзе чыгарган. Кыз чагыннан ук җырлый. Җырның исемен ул «Кыйгач-кыйгач. Үз көем», дип яздырды.

***Кыйгач-кыйгач***

*Өй түбәләрем нә кыйгач-кыйгач,*
*Кыйгачлары саен ла сандугач;*
*Сандугачларымны, ай, бик сөям,*
*Җан сөйгәннәремне юксынам.*

Мөсәлимә апа бик традицион көй белән «Сак-Сок» бәетен дә көйләп күрсәтте. Юртбиргамакта бу – икенче «Сак-Сок». Беренчесен безгә **Искәндәрова Хупҗамал апа** (1923 елгы) җырлады. Көйләре бер үк диярлек.

Ә менә Хупҗамал апаның «Кычкырма ла кәккүк» җыры бик үзенчәлекле – мөстәкыйль көй.

***Кычкырма ла кәккүк***

*Кычкырма ла кәккүк, әй, каршымдай,*
*Кычкырсана агачның башындай;*
*Кычкырсана агачның башындай;*
*Син кычкырмасаң дай, әй, каршымда,*
*Хәсрәтләрем күп бит лә башымдай,*
*Хәсрәтләрем күп бит лә башымдай.*

*Агыйдел лә алкын, суы салкын,*
*Чайкаладыр ярлары тулыганыгай.*
*Утырып ла елаем, кычкырып йырлыйм,*
*Йөрәккәйләрем генә янгангай.*

*Кычкырма ла кәккүк.*
*Хупҗамал Искәндәрова башкара*

1969 елның 27 июне. Эшебезне Юртбиргамак авылында дәвам итәбез. 77 яшьлек **Хәмитов Хәйрулла абый** «Иске җыр»ны, 1932 елгы **Мардамшина Мәрьям апа** «Шәмшәриф көе» белән «Арча көе»н җырлап бирде.

Минем күңелемә үзенең философик эчтәлеге белән **Ташимов Хөсни абыйның** (1902 елгы) «Ай-хай дөнья» дигән җыры хуш килде:

***Ай-хай дөнья***

*Ай-хай да дөнья бит, ай-вай үтәсең,*
*Картайтып ла әрәмнәр итәсең;*
*Картайтып кына, их-вай, куймыйсың,*
*Кара йергәй аннарын кертәсең.*

Бу җырны язганда миңа 29 гына яшь булган икән. Хәзер олыгайгач, ул башкачарак кабул ителә.

Хөсни абыйның горурланып әйткән сүзләре әле дә колакта:

*О чем тужить, безгә ни булган?*
*Безнең дуслар белән ил тулган!*

**Ташимова Зөлхәбирә апа** (1902 елгы) Хөсни абыйдан бер дә калышмый. Ул «Җибәрим җырлап» дип сузып, шундый матур, салмак, вальска охшаган бер җыр яздырмасынмы!

*Җибәрим җырлап лай,*
*Китсен чыңнап,*
*Яңгырасын лай*
*Урманның буйлары;*
*Тиберәнсене кырлар,*
*Киң болыннар,*
*Онытылсыны хәсрәте уйыларый.*

Менә бит ул җыр халыкка ничек хезмәт итә! Иң авыр вакытта да кеше күңеленә ярдәмгә килә, юата, хәсрәтле уйларны күңел фильтры аша үткәреп җибәрә, тынычландыра, яшәү көче өсти, төшенкелек упкынынннан тартып чыгара!

### *Чуртанлы авылы*

Муромцево районының Чуртанлы авылы – борынгы авылларның берсе, сөйләүләренә караганда, аңа 400 елдан артык икән. Авыл халкы аның борынгылыгын яхшы белә, кайберәүләр 500 ел дип тә сөйлиләр. Биредә XVII–XVIII йөзләрдә ясаклы татарлар яшәгән. 1850 елларда авылда җамигъ мәчет булганлыгы мәгълүм, әмма кайчан төзелүе билгесез.

Чуртанлы – тупланып урнашкан кечкенә генә авыл. Халкы тыйнаклыгы белән аерылып тора. Шул ук вакытта биредә бик горур кешеләр яши. Сөйләшкәндә дә башны югарырак чөеп сөйлиләр. Авыл халкы үзара бик ярдәмчел. Гомумән,

бу – Себердәге татар авылларына хас күренеш. Күрәсең, кырыс табигать шартлары да моңа йогынты ясыйдыр.

Фәтхуллина Мөршидә апада фатирга төштек. Үтә дә җитез апа. Өйләре зур, чиста, яхшы телевизоры да бар. Муллык белән яшиләр. Туйганчы балык белән сыйландык. Авылның исеме дә Чуртанлы бит. Урамда пешкән уханың тәме... телеңне йота торган.

Беренче информантыбыз **Агабеков Таһир абый (**67 яшь) «Ай янында якты йолдыз», «Сәхраларга чыксам», «Карурман» дигән җырларны башкарды. Тагын бер җырын «Иске көй» дип җырлап бирде:

***Сәхраларга чыксам***

*Сәхраларга чыкысам, хәйраны булам*
*Төрле моңлыу кошларның таушынай.*
*Үткән дә генә гумерем охшатамын*
*Шалтырап аккан суларның агышынай.*

*Абу лә, Алла , башым аурый,*
*Әллә дә ләй йелләргәй, давылгай;*
*Әллә лә йелләргә лә, әй, давылга,*
*Әллә дә лә хәлләрем авыргай?*

Икенче информантыбыз **Адикаева Мөкатдисә апа** (1912 елгы) «Борынгый көй. Әтием көе» дип бер җыр башкарды. «Ай янында якты йолдыз» җырын исә ул И. Шакиров җырлаганчарак, аның пластинкалары аша өйрәнеп җырлады.

Калган җырчыларыбыз, нигездә, заманча, радио яки пластинкалардан ишетеп өйрәнгән җырларын башкардылар. **Фәтхуллина Мөршидә апа** (1927 елгы) «Күн авылы көе»н, «Ай югары, ай югары»ны җырлады. Безнең халыкның бер үзенчәлекле җыр иҗаты бар. Бу – дүртьюллыклар. Аларны хәзерге вакытта рус халкының частушкалары белән ча-

гыштыру да очрый. Татар дүртьюллыклары, частушкалардан аермалы буларак, кешенең психологик халәтен чагылдыра, уй-кичерешләрен ачып бирә. Шуңа күрә аларны частушка белән чагыштыру урынлы түгел. Көй ягыннан да бер үзенчәлеге бар бу җырларның, аларны һәр авыл үз авылы көенә дә башкара ала, алар озын көйгә дә, кыска көйгә дә ята. Мөршидә апа мондый җырларны да башкарды:

*Мәдрәсәләргә кергәндә*
*Салып кер галушыңны.*
*Сахраларга чыгып җырла,*
*Ишетерлек тавышыңны.*

Кайбер җырлаучылар бер генә җыр башкарсалар да, аларның исемнәрен дә искә алам.

**Мардатина Мәрьям** (1932 елгы) – сыер савучы, ул көн саен кич белән җылы сөт кертте, тәмле эремчекләрдән дә авыз иттек. «Арча» көен бик ярата, хромкада шул көйне уйнап, аны да җырлаттым.

Себер татарлары музыканы бик ярата, музыкантларны да хөрмәт итә. Туй-мәҗлесләрдә дә аларның урыны түрдә. Бу тирәдә бохаралылар күп яши. Аларның традицияләрендә туйларда музыкага зур игътибар бирелә.

Һәр өйдә Илһам Шакиров пластинкалары бар. Халык Казаннан килгән яңа җырларны бик ярата, киткәндә берничә кеше Казаннан посылка белән татар пластинкалары җибәрүебезне сорады. Бу чын миллилек бит! Бу мәсьәләдә мин һәрвакыт үз сүземдә торырга тырыштым.

**Биктимирова Мөкатдисә** (45 яшь) катерда эшли. Ул «Шәмшәриф»не җырлады.

### *Инсәз авылы*

1969 елның 1 июле. Инсәз авылы Муромцево районында Тара елгасы буенда урнашкан. Авыл XVII башларында барлыкка килгән дип сөйлиләр. Биредә дә ясаклы татарлар

яшәгән. Халыкның төп шөгыле – терлекчелек, аучылык булган. Икмәк игү эшенә соңрак керешкәннәр.

Инсәз бик матур авыл. Безгә монда бераз тоткарланырга да туры килде. Бирегә килүе җиңел, ә китүе бик авыр булды. Өч көн су трамвае килмәде. Ә ансыз юл юк, беркая китеп булмый. Ярый әле халык безгә ач йөрергә ирек бирмәде.

3 июльдә без экспедицияне тәгәлләп, өйгә юл тоттык. Фатих Усть-Тарада калды, мин Казанга кайтып киттем.

Инсәздә кечкенә генә авыл булса да, җиде җырчыдан шактый җырлар яздырдык.

**Насыйрова Миңлехәят ападан** (1918 елгы) «Кистем каен», «Шомыртым» җырларын язып алдык.

**Хөснетдинова Мөхлисә апа** (1906 елгы) башкарган «Борынгы көй»нең сүзләре дә, көе дә бик матур:

***Борынгы көй***

*Сандугачлар булып лай сайрар идем,*
*Ишек алларымда саз булсай.*
*Уйнар гына идем нәй, көләр идем,*
*Минем күңелкәйләрем шат булсай.*

**Гыйззәтуллин Шәйдулла абый** (74 яшь) «Мөнәҗәт», «Агыйделкәйләргә»; **Хәсәнова Хәбибҗамал апа** (80 яшь) «Сарман»; **Датаев Сәмигулла абый** (70 яшь) Авыл көе»; **Апушева Бәдриҗамал апа** (1916 елгы) «Ай югары»; **Шәмсетдинова Шәмселхәят апа** (1916 елгы) «Карурманнарга кергән чакта», «Ай янында якты йолдыз» җырларын җырладылар.

Шәмсетдинова Шәмселхәят апаның бер җыры «Ишегалдым яшел үлән» дип атала:

*Ишегалдым яшел үлән,*
*Йөгереп чыгам оекчан;*
*Тулган айларга карыймын,*
*Сине уйлап боексам.*

## Төңгер

Себер татарларында тормыш-көнкүрештә хәзер дә курай, кубыз, гармун һәм скрипка уйнау, төңгер кагу яшәсә, әкиятләрдә һәм өлкән буын кешеләре хәтерендә күптөрле уен кораллары булу турында мәгълүматлар очрый.

Новосибирск өлкәсендә узган экспедиция вакытында Бараба татарларында төңгер дигән кагып яки бәреп уйный торган музыка уен коралы табылды. Аның диаметры 28,5 сантиметр, биеклеге 7,5 сантиметр. Төңгердә, сирәк булса да, әле да кагалар. Туй мәҗлесләрендә биегәндә, скрипка яки гармунга кушылып төңгер да яңгырый. Эшләнеше белән төңгер алтай халыкларында киң таралган шаман коралларын хәтерләтә.

Туваларда бу уен коралы – «дүңгүр», ә алтай халыкларында – «түңүр» дип йөртелә. Төңгерне иләккә охшаган кысага мәче тиресен киереп ясаганнар. Кысаның ян-ягында дүрт урында икешәр җиз тәңкә беркетелгән. Тире алты җирдән аска тартылып беркетелгән. Уйнаганда җиңел булсын өчен, бармаклар белән тотарга махсус түгәрәк тишек тә бар. Картларның әйтүенә караганда, бу кагып уйнау коралы йола белән бәйле булып, туйларда гына уйналган.

Новосибирск өлкәсе Куйбышев районы Яргөл авылын узган фольклор экспедициясе вакытында Флора Әхмәтова һәм Рашат Гайнановка В. Алиев төңгер бүләк иткән. Алар аны Институтның халык музыкасы кабинетына тапшырдылар. Төңгернең копиясе Татарстанның Дәүләт музеена да куелды.

## Ятыган

Бараба татарларының тагын бер музыка уен коралы – ятыган яки ядыган булуы турында да хәбәрләр бар. Ятыганның Бараба татарларында яшәү ихтималын ике дәлил куәтли алыр иде: беренчедән, бу уен коралы күрше халыкларда киң таралган була, икенчедән, шушы уен коралына кушылып

сөйләнергә мөмкин «Кузы Көрпәч белән Баян-сылу» дастаны бар. Бүген дә мәшһүр дастанның көйләп әйтелә торган кайбер өзекләре сакланып калган һәм алар халык арасында мөстәкыйль җыр формасына күчә башлаганнар. Җырчылар исә үзләре дастанның эчтәлеген якынча гына беләләр. Чичәннәр Себер татарлары арасында булган. Чичән сүзе элек сүз остасы дигәнне дә аңлаткан, җыручы-импровизатор мәгънәсенә дә ия булган. Димәк, ул – һәр ике профессияне үзендә бергә җыйган кеше, борынгы халык шагыйре. Чичән җыручы буларак ничек иҗат итә соң? Иң элек ул шигырьне язып та, сөйләп тә чыгармый, аның кулында думбра була, ул шуның кылларында күтәренке, ярым көйле авазлар белән безгә тотрыксыз тезмә чыгарып сөйли... Ул борынгы җыр-дастаннарның күбесен күңелдән әйтә, аларның шигъри алымнарын, сюжет һәм мотивларының һәр очракта ничек сайланылышын, төзелеш, композициядәге ладларын алдан белә. Бу тавышлар рәтендә пентатоника лады теориясендә кабул ителгән биш төр дә бар. 2–3 нче кыллар арасында – квинта һәм 3–4 кыллар арасында кварта интерваллары булу башкарыла торган эпик әсәрләрдә бу актив интервалларның зур урын тотуын күрсәтә. Күрше-тирәдәге халыкларда бу музыка уен коралларының булуы да ятыганның Себер, төгәлрәк әйткәндә, Бараба татарларында булуына шик калдырмый.

«Ак Күбек» дастанының В.В. Радлов тарафыннан Тәрәнә авылында Бараба татарларыннан язып алынган вариантында да бу уен коралы телгә алына: *Ак Көбек төрле яхшы һөнәрле кеше иде; яралы булганга, ядыганын*[1] *бер агачка элеп салды, чиртергә көче юк иде*.

Ятыган тезгә куеп яткырып уйный торган тагарак рәвешендә. Ә инде чыңнары бары тик дастаннарда һәм әкияттә генә калган «алтмыш кыллы ай тумбра» – (бәлки ул

[1] Ядыган – чиртеп уйный торган кыллы музыка коралы.

чынлыкта алты гына кыллы булгандыр, әкиятләрдә күпертү – еш очрый торган күренеш) ярымай рәвешендә.

### Думбра

Татар халык дастаннарында һәм әкиятләрендә искә алынган икенче уен коралы – думбра. Кыл-думбра, айтумра, айтумрак һәм «алтмыш кыллы ай тумбра» да бик еш телгә алына.

Ятыган һәм думбра формалары, уйналу ысуллары белән бер-берсеннән аерылалар.

Думбраның (тумбра) тормыш-көнкүрештән төшеп калуына күп тә үтмәгәндер. Мәсәлән, туй йоласы «Күч җыры»нда ул болай искә алына:

*Думбраны ла чиртә лә, чиртә*
*Булдым бакшы[1], булдым бакшы.*
*Ай, күп халыкның арасында*
*Булдым яхшы, булдым яхшы...*

Себер татарлары думбрасында да чиртеп уйныйлар. Аның формасы һәм кыллар саны мәсьәләсен, киләчәк эзләнүләрне күздә тотып, ачык килеш калдырабыз.

Себер думбрасының төньяк күршеләр – мансиларның тугыз кыл тарткан почмаклы (ә Себер татарларында ярымай рәвешле) арфасына да, көньяк күршеләре – казахлардагы мәшһүр ике кыллы думбрага да охшавы мөмкин. Чөнки берничә халыкта төрле рәвештәге уен кораллары бер үк исем белән аталып йөртелү очраклары бар. Мәсәлән, кубыз – казахларның ике кыллы уен коралы, татарларның авызга кабып өреп уйный торган варганы. Кубос – чувашларның гармуны. Курайның аталышы Казан татарларында, башкортларда һәм Себер татарларында бертөрле.

[1] Бахшы – чичән.

# ДҮРТЕНЧЕ ЭКСПЕДИЦИЯ

## ТОМСК ӨЛКӘСЕ

*(1969 елның сентябре)*

### Томск районы

### *Абытай айыл*

1969 елның 14 сентябре. Авылда бәрәңге алып яталар, ә мин экспедициягә җыенам. Иртән Олы Бәрәзәдән энием Зәкия (1919 елгы) озатып калды. Казанда бертуган апам Люция һәм җизнәм Закирда бик яхшы кунак булдым. Бергәләшеп мине вокзалга озаттылар. Томск каласына 16 сентябрьдә төнге 11 дә килеп төштем. Кунакханәдә раскладушкада йокларга туры килде. Ул заманнарда кунакханәләрдә урын булмый, раскладушка варианты да начар түгел иде.

17 сентябрь. Иртән өлкә башкарма комитетына кердем, максатларны аңлаттым. Бернинди кәгазь-мазар алып тормадым. Мин инде өч кыр экспедициясендә шомарып, «эт каешына» әйләнгән идем. Сәгать 11 дәге Томск-Кулек автобусы белән Абытай – Чёрная речка авылына килеп җиттем. Авылны халык та ике исеме белән дә атап йөртә. Таныша башладым. Управляющий булып – Мухаметшин Ибрай абый, бухгалтер булып Казаков Мурат эшли икән. Мурат бик тә укымышлы, күп белә торган кеше. Шулай да алар, эзләп-эзләп тә, миңа торырга фатир таба алмадылар. Үзем табып, бер яхшы гына апада тукталдым. Безнең яктан, Волжскидан күчеп килгәннәр икән. Әтиләре төрмәдә үлеп калган. Беренче көнне үк яза башладым, тик...әлегә оригиналь көйләр юк. Бераз кәеф тә китте.

18 сентябрь. Иртән **Сәйфелмөлеков Хәйрулла абыйдан** (1905 елгы) «Городок көе», «Бандит көе», «Әйт әле шул, сандугач», «Урам көе», «Сарман көе»н язып алдым.

Бу якларда «Городок көе»нең бик популяр икәнлеген мин алдан ук белеп килдем. Беренчедән, Омскида Абитов Биктимер абый җырласа, икенчедән, Мөхәммәт Мәһдиев үзенең «Казан утлары» журналында чыккан (1968, № 10) мәкаләсендә бу җырның сүзләрен биргән иде:

*Китәм инде, китәм инде,*
*Китәм инде, каласың;*
*Том каласы ерак түгел,*
*Озатырга барасың.*

*Сау бул инде, Том каласы*
*Лагерь таулары белән;*
*Сез булмагач, мин нишләрмен,*
*Дөнья маллары белән.*


Ә менә Хәйрулла абыйның тексты:

*Гарадукның тавы биек,*
*Без менәлмәбез әле;*
*Бәлекеме рәхәт көнеләре булыр,*
*Без күрәлмәбезме әле.*

*Сандугачның балаларын*
*Тотсам үтермәс идем.*
*Сез дусларым җаннарында*
*Үлсәм дә үкенмәс идем.*

***Городок көе***






Бу җыр «Том көе» исеме белән А. Ключаревның «Татар халык көйләре» китабында[1] басылган. Анда аның 1940 елда Омск өлкәсендә И. Гыйззәтуллиннан язып алынганлыгы турында әйтелә. Ә тексты – чын советча:

*Городокның тавы биек,*
*Алма тәгәрәтергә.*
*Күңелле соң колхозларда*
*Эшләве бергә-бергә.*

*Городокның тавы биек,*
*Ерак түгел Обь елга.*
*Таза тормыш, яхшы тормыш*
*Бары колхозда гына.*

*Городокның тавы биек,*
*Алма тәгәрәтәбез.*
*Көчле тракторлар белән*
*Кырларны гөрләтәбез.*

Биктимер абый җырларның күбесен әтисеннән өйрәнгән, дидек. Күрәсең, Мәлик бабай (1887–1968) ямщик булып йөргәндә Томск якларында ишеткән булса кирәк.

[1] Татарские народные песни / сост. и собиратель А.С. Ключарев. Казань: Таткнигоиздат, 1955. № 10.

«Городок» җыры Томск татарларында хәзер дә бик популяр. Ул үзенчәлекле йола җырына да әйләнгән. 2015 елда Томск өлкәсендә узган экспедиция вакытында бу җырны Илсөяр Закирова да язып ала. Ул аның турында түбәндәгеләрне яза: «Информантлар: “Бу “Городок” җырын туйларда җырлыйлар. Туйга килгән халык авыл буенча шушы көйне җырлап килә. Кыз ягы җырлый. Егет ягы каршы җырлый. Кодаларны мактап җырлыйлар” дип аңлаттылар». И. Закирова язган буенча, «Городок» җырының тагын бер бик нәзакәтле вазифасы бар – ул килгән кунакларга таралырга вакыт икәнен искәртә.

**Фәттахова Бибихөсни апа** (1901 елгы) бер «Көй», **Әминова Миңлегаян апа** (1900 елгы) «Сарман буйлары», «Яшьлек», «Шахтёр», «Исламбул авылы көе»н яздырды. Соңгысы безнең якларда Әтнә районы Олы Бәрәзә авылының туй-мәҗлес җыры булган «Сылабаш» көенә бик тартым. Сүз уңаеннан, Исламбул – Томск өлкәсендә тулысы белән Казан ягыннан килгән халык яшәгән бердәнбер авыл. Авылга XX гасыр башында Столыпин реформасы буенча Казан губернасыннан күчеп килгән татарлар нигез салган. Ул Томскидан 200 километрлап төньякта урнашкан.

1898 елгы **Әбелбохаров Якуб абый** белән без бик тиз уртак тел таптык. Ашау – эшнең башы, дип, иң элек ул мине бик тәмләп сыйлады, авыл хәлләрен сөйләде. Күпне күргән, күпне ишеткән бу бабай. Һәрнәрсәгә үз фикере бар. Философ. Якуб абый – туган авылында һәм тирә-якта шактый танылган җырчы һәм скрипкачы. Ул яшьли якты дөньяны күрүдән мәхрүм булган. Тормышы җитеш. Күңелем сизә: Якуб абыйның җыр «капчыгы» буш түгел! Һәм ул шулай булып чыкты да.

Якуб абый җырларын Себер якларында яратып җырлана торган борынгы «Шәмшәриф» көеннән башлады. Аннан соң бер «Кыска җыр» әйтеп алды. «Зиләйлүк»не дә ярата икән. Ниһаять минем күңелемә бик якын, мин тиз отып алган, һәм

Казанга кайткач, радио-телевидение аша җырлап күрсәткән «Ай-һай, дустым» җырына чират җитте:

*Ай-һай, дустым, кашың кара,*
*Кайдин алдың каш кара?*
*Сиңа гомер тели-тели,*
*Үзем гомереме кыскара.*

Бу сүзләрне ул миңа карабрак җырлады. Дөресрәге, чын-чын җырчылар үзен тыңлаучыны бик тә хөрмәт итәләр.

*Аргамактан тайлар туса,*
*Ал аягы ак булыр.*
*Чит илләрдин малсыз кайтсаң,*
*Бер туганың ят булыр!*

Шулай ук бу утыруда «Борынгы җыр», «Баламишкин» һәм «Шәкертләр җыры»н да язып алдык. «Шәкертләр җыры»н мөнәҗәт дияргә дә була. Бу җырны Якуб абый абыйсы Гыймалетдиннән откан. Җырны исә 1907–1908 елларда ул Томск мәдрәсәсендә укыганда, шәкертләр үз мөгаллимнәрен мактап чыгарганнар икән.

***Шәкертләр җыры***

*Хәзрәтемә бараем да,*
*Бирсә, сабак алаем;*
*Сабак алып кайткандин соң,*
*Зикер тәсвих әйтәем.*

*Хәзрәтемнең собхәтендә*
*Сәчмәй ускән гөлләр бар;*
*Хәзрәтемнең күңелендә*
*Әүлия нурлары бар.*

*Хәзрәтемнең мәрәсәсендә*
*Гарше-көрси баскычы;*
*Хәзрәтемнең уң кулында –*
*Сигез оҗмах аскычы.*

*Хәзрәтемнең чалмасы*
*Яңа яуганлар кар кебек.*
*Хәзрәтемнең нурлы йөзе*
*Яңа туган ай кебек.*

*Хәзрәтемнең чапанында*
*Юлак-юлак юллар бар;*
*Хәзрәтемнең йөзкәендә*
*Тыулган айның нуры бар.*

*Хәзрәтемнең түбәтәен*
*Тубылдин китергән.*
*Хәзрәтемнең нурлы йөзен*
*Рәсемнәргә төшергән.*

*Хәзрәтемнең кулындагы*
*Камыш иде таягы;*
*Хәзрәтемнең мәдрәсә юлында*
*Бушамады аягы.*

Якуб бабай бу якларда элегрәк скрипка һәм балалайкада уйнауларын хәтерли. Томскида Фёдор Коковин һәм аның малае Александр гармуннар ясаганнар. Бу осталар Вяткадан килгән булганнар.

Якуб абзый шулай ук ***бандура*** дип аталган, ксилофон кебек металл пластинкаларга бәреп уйный торган уен коралының актив кулланышта булуын хәтерли.

Гомумән, күзләре күрмәгән кешегә музыкант булу ул әле үзенә күрә бер һөнәр дә бит. Барыбер ач булмыйсың!

Якуб абый скрипкада «Сабан туе көе», «Камарская» бию көе, борынгы бию көе, «Абыстайларның бию көе», «Во саду ли», «Ай-һай, дустым» (скрипка һәм җыр) көйләрен уйнады.

Бию көйләре туй-мәҗлесләрдә бик популяр булган, күрәсең.

Якуб абый башкарган көйләр арасында «Абыстайларның бию көе» күңелгә аеруча хуш килде. Ул аны «Кыз көе» дип тә атый.

Абыстай ул мулла хатыны гына түгел. Себердә еш кына хатын-кызларга хөрмәтләп абыстай дип эндәшәләр. Дөрес, бу күренеш Казан татарларында да очрый. Бу көй туйларда, мәҗлесләрдә, кич утырганда хатын-кызларны гына биетү өчен махсус уйнала. Аны тыңлаганда кич утырган абыстайларның бөгелә-сыгыла, нәфис хәрәкәтләр ясап биюләре күз алдына килә дә баса! Бу көйне Якуб абый бик тәмләп, яшь вакытларын искә төшерә-төшерә уйнады. Бер дә аптырап яшәмәгән ул, күрмәүчеләрне дә күрүчеләр бар икән бит бу якты дөньяларда!

*Абыстайларның бию көе. Якуб Әбелбохаров скрипкада башкара*

*Во саду ли. Якуб Әбелбохаров скрипкада башкара*

*Борынгы бию көе. Якуб Әбелбохаров скрипкада башкара*

*Ай-хай, дустым. Якуб Әбелбохаров скрипкага кушылып җырлый*

Бүген 2023 елның 11 августы. Телевизордан «Семнадцать мгновений весны» фильмын 50 елдан соң яңадан күрсәтә башлыйлар. Ә минем үземнең күңелемнән төшерелгән «49 мгновений Сибири» дигән фильмым бар. 50 ел элек мин дә Көнбатыш Себернең биш өлкәсендә 49 татар авылында булып, йөзләгән җыр-көйләрне язып алып, югалудан саклап калдым. Бүген аларны җырламыйлар да, көйләмиләр дә. Бу җыр-моңнар мине гомерем буе озата барды.

**Нуретдинов Җамал абый** белән очрашып сөйләштек. Урманчы икән. Монда аны Николай Михайлович дип йөртәләр.Туган авылы, аның табигате, халкы турында күпме

мәгълүматы бар аның. Заманында Абытайда А.Н. Радищев та кунып киткән! А.Н. Радищев Томскида 1791 елның август башында сөргенгә юл тотканда туктала. «Пугачёвтан да яман бунтовщикны» шәһәр коменданты Тома (Томас Томасович, Фома Фомич) де Вильнёв сыендыра. А.Н. Радищев биредә ике атна яши, халык тормышы белән таныша. Крестьяннарның авыр хәле турында язмалары да бар.

Моннан ерак бер авылда Юмаев фамилияле татар язучысы да яшәгән булган. Ул Хәсән Туфан булмады микән? дигән фаразлар да юк түгел.

Җамал абыйның Венский гармуны бар дигәннәр иде, Себер көйләрен дә белә икән. Тик мин аларга килгәндә, Җамал абый еракка китеп барган булып чыкты шул... Кемгә фән, кемгә дөнья мәшәкате...

Монда Идел буе немецлары да яши икән. Аларның да үз язучылары булган.

### ***Кызылкаш авылы***

19 сентябрь. Томск өлкәсендәге Кызылкаш (Тахтамышево) авылы каладан ерак түгел. Халык авылның Тахтамышево дигән исемен Алтын Урда ханы Туктамыш исеме белән бәйли. Бу тарихи дөреслектән ерак булуга карамастан, халыкның үз тарихын белергә омтылышы булуын күрсәтә.

Монда фатирны тагын үзем таптым. Яхшы гына. Гомумән, бу якта татар өйләре бай. Һәр йортта диярлек телевизор, диван-карават, 3–4 койка-карават, кер юу машинасы бар. Авыл урамнарыннан узып, карап, танышып чыктым. Йортлар зур, матур. Кичен **Сәитов Әнвәр абыйларда** булдым. Хатыны Мәдинә апа бик кунакчыл. 9 классны бетергән Зәйтүнә исемле бик матур кызлары да бар икән. Озаклап сөйләшеп, чәйләр эчеп утырдык.

20 сентябрь. Иртән кар ява. Гаҗәп матур күренеш. Ябалак кар. Шәп йокладым, тик сәгать аермасы гына бераз күзне кызарта.

Бик оста жырчы дип **Аблин Хаҗиәхмәт абыйга** (1904 елгы, 65 яшьтә) алып бардылар, тик аларның мамайлары вафат булган, вакытсыз булды керүем, шулай да өйләдән соң очраштык.

Хаҗиәхмәт абый – кечерәк кенә буйлы, бик җиңел атлап йөри торган ак чырайлы карт. Мулла вазифаларын башкара. Сталин төрмәләрен татыган кеше. 1936 елда ат караучы (конюх) булып эшләгәндә утырткannar. Хаҗиәхмәт абыйның беренче җыры ук минем күңелемә кереп урнашты. Том татарларының туй җыры – «Кыз елату җыры» дип атала ул. 1967 елда М. Мәһдиев җырның сүзләрен Хаҗиәхмәт абыйдан беренче булып язып алган иде инде: «Кияүгә киткән кызны йортыннан озатасы көнне аларга егетләр-кызлар җыелалар. Гармун, скрипка уйныйлар. Кызлар бии. Китәсе кыз җавап бирә:

*Агач башы күк тиен,*
*Атып алуы кыен;*
*Ятка бару берни түгел,*
*Ятка яравы кыен.*

Шушы җырдан соң барлык кызлар да сәкегә утырып елыйлар[1]. Җырның исә мин язып алган тексты болай:

*Ай, китәсең, китәсең лә,*
*Атка авыр итәсең,*
*Атка җиңел, сиңа авыр,*
*Яты кулына китәсең.*

*Безнең урам киртләч-киртләч,*
*Киртләч бетәр кар киткәч.*
*Ир бала кайта хезмәт иткәч,*
*Кыз бала кайтмый бер киткәч.*

---

[1] *Мәһдиев М.* Себер татарлары җыры // Казан утлары. 1968. № 10. Б. 130.

*Ак шарф та бәйләдең,*
*Күк шарф та бәйләдең.*
*Әткәң-әнкәң кулларында*
*Актык җәйләр җәйләдең.*

*Самавырны тиз кайната*
*Яшь каенның күмере.*
*Ата-анада кыз баланың*
*Унсигез ел гомере.*

*Кыз озату җыры.*
*Хаҗиәхмәт Аблин башкара*

Хаҗиәхмәт абый әйтүенчә, Кызылкаш авылының чама белән 300 еллык тарихы бар. Аның әти-әниләре Бохара ягыннан килгән. Үзенең «Борынгы көй» җырында:

*Ашыйсым ла килсә ашый алмыйм,*
*Бохарлардан килгән әлбәне, –*

дип тә әйтеп куя.

Хаҗиәхмәт абый «Баламишкин» җырын да җырлады.

*Өй түбәсе кыйгакчан,*
*Яшь егетләр мыекчан;*
*Яшь егетләрне күргәндә,*
*Кызлар чыга оекчан.*

*Ак агармак, күк агармак,*
*Җиккән сыңгар тәртәгә.*
*Яшь кызларга, егетләргә*
*Алла бирсен мәртәбә.*

Тагын бер борынгы җыр турында Якуб абый: «Без әле дөньяда юк заманадагы көй бу», – диде.

**Борынгы җыр**




*Казандин дәй килгән ай укам ди,*
*Тумыскида безнеңе җук андый,*
*Тумыскида безнеңе җук андый.*
*Баядиндәй бирле карап торам,*
*Килешмие калганы җирегез җуг әле,*
*Килешми калганы җирегезе җуг әле.*

*Судае буенда гына ай багана,*
*Башкайларын тулкын лай кагама,*
*Башкайларын тулкын лай кагамай?*
*Тамакларым да йе бик карылай,*
*Үтеп китте бездин ләй замана,*
*Үтеп китте биздин ләй замана.*

*Челтерәп лә аккан ай суларның,*
*Аскайлары дәрья лә булмасын,*
*Аскайлары дәрья лә булмасын.*
*Сөям генә дип лә әй әйтәсең,*
*Сөюләрең хәйлә лә булмасын,*
*Сөюләрең хәйлә лә булмасын.*

*Туйлар була иде элекке вакытны. Күрше Кызылкаш һәм Омайылдан күп кунаклар килә иде. Картлар җырлап җибәрәләр. Вәт шул җырлар колакка сеңеп калганнар. Абыстайлар бөгелмичә-сыгылмыйча биеп йөриләр иде. Элек кызлар кунакка килгәндә, «кыз өе» ясыйлар иде.*

*Яүштәнең Чәкә мулла бар иде. Үзе мулла, башында чалма, скрипкәне уйнап менә йөри иде, очып йөри торган кош шикелле.*

Томскиның атаклы «Бандит көе» турында да бераз языйк әле. Җырның сүзләре болай:

***Бандит көе***



*Баныдиты көе, баныдит көе,*
*Бандиты көйләрен яратам;*
*Бандиты көйләренә йырлап,*
*Бары хәсерәтем таратам.*

*Утырысам уйылый башлыйм ла,*
*Уйласам йырлый башлыйм;*
*Күп уйыланып йырламасам,*
*Дивана була башлыйм.*

*Уйыга калам, уйыга батам,*
*Кулымда кош уйынатам;*
*Күп уйыланып, бере йырыласам,*
*Күңелләрне юатам.*

Җырның көе мәшһүр «Идел» һәм «Су буйлап»ны хәтерләтә, «Алсу» җыры көенең интонацияләренә дә бик якын кебек. Хаҗиәхмәт абыйның әйтүенә караганда, күптәннән җырлана. Чама белән 1925–1926 елларда чыккан. Һәрхәлдә, «Идел» көеннән күпкә иртәрәк. Яшьләр җыры булган, картлар җырламаган. Җырның сүзләрен беренче булып теркәгән М. Мәһдиев болай дип яза: «Турысын гына әйткәндә, бу көйнең исемен ишеткәч, бераз каушап калдым. Ничек инде ул – бандит көе? Бәхеткә каршы, җырның сүзләрендә куркынычлы андый берни дә очрамады. Ә менә көенә килсәң, гаҗәп. Бу көй аһәңгә шулкадәр бай, шулкадәр тирән моң – монда иксез-чиксез тайганың шаулавына Себернең киң сулы елгаларының салмак агымы кушыла. Бу җырны тыңлаганда, ирексез, богауларын чыңлатып тайга юлларыннан сөргенгә куылган бабайларның аһ-зарын, йөрәк сыкравын ишетәсең. Ләкин халык җыры буларак ул тирән оптимизм белән сугарылган һәм, әгәр шулай әйтергә яраса, бу җырны мин тантаналы-драматик җыр дип атар идем»[1].

[1] *Мәһдиев М.* Себер татарлары җыры // Казан утлары. 1968. № 10. Б. 130.

М. Мәһдиевнең әлеге сүзләренә нәрсә дә булса өстәргә мөмкин микән?!..

Бу көнне кар явып, урамны баткакка әйләндерде. Почтага кереп, Казан белән сөйләшеп алдым. Почтальон үзенең танышлары аша, бик җайлы гына итеп, Казан белән тоташтырды.

Хуҗалар мунча яктылар. Кара мунча, бик кызу, тик түбәсеннән йолдызлар күренеп тора...

Икенче көнне **Әбҗәлилов Җамали абыйдан** (1921 елгы) «Уел», «Уракчы кыз»ны язып алдым. «Уел»ны бик күп җырчылардан ишеткәнем бар, Җамали абыйның «Уел»ы кабатланмас! Бик көчле тәэсир итә!

*Заманалар җиңел, тормыш рәхәт,* – дип җырлый бит ул!

«Уракчы кыз»ны да искиткеч итеп башкара Җамали абый. Мин инде бу җырны Омск өлкәсендә Зур Тибендедә һәм Илчебагада язып алган идем. Бу якларда да ул киң таралган. Аны Омск өлкәсе Ишем-Тамак районы Зур Тибенде авылында Әбүсәгыйтова Шаһидә (1921 елгы) җырлады. Җырның бер вариантын шул ук районның Илчебага авылында Хәмидуллина Зөләйха (1901 елгы) башкарды.

Халык арасында хәзер дә яши торган классик җырларның берсе ул «Уракчы кыз». Татар фольклористикасының аксакалы Н. Исәнбәт шигыренә җырлана. Күп еллар үтсә дә, җырның сүзләре үзгәрми диярлек, бары көй вариантлары гына ишәя. Бу хәл исә көй белән шигъри юлларның гүзәл бердәмлеге хакында сөйли. Н. Исәнбәт татар халык иҗатын җыюга бөтен гомерен багышлаган галим-филолог, шагыйрь-драматург, язучы. Шуңа күрә дә аның бөтен халык җырлардай классик шигырь язуы бик табигый хәл.

«Уракчы кыз» шигыре беренче мәртәбә 1922 елда «Кызыл Шәрык» журналында басыла. Моңа кадәр җырның көе булганмы-юкмы, анысы әлегә мәгълүм түгел. Мәсәлән, Ю. Виноградов җырның 20 нче еллар ахырында тууы

турында язган[1]. Җ. Фәйзи үзенең «Халык җәүһәрләре» китабында: «Халык аны көйгә салып, шул вакытлардан (1922 елларда. – *И.К.*) ук җырлый башлаган. Булган көй белән файдаланганмы ул, әллә шушы сүзләргә көй чыгарганмы, анысын ачыклап булмады. Моны Нәкый Исәнбәт үзе дә анык белми. Бәлки, халык көе буларак җыр башта төрле «күчмә сүзләр» белән җырлангандыр»[2], – дип яза.

Җырның 1928 елда Казанда язып алынган тәүге варианты бар. Г. Сөләйманова аны А. Ключаревка тапшырган[3] .

Кызылкаш авылында җырлар язып алуны дәвам итәбез.

**Абсалямова Мәрфуга** (59 яшьтә) – татар хакының «Уел», **Сафиуллина Рәхилә** «Герман сугышы» көен, **Казакова Гайшә** (1909 елгы) апалар «Һаваларда йолдыз» җырларын башкардылар. Болар барысы да – мәгълүм җырлар. Яңарак, безгә таныш булмаган көйләр көтәм.

**Әбҗәлилов Вафа абый** (82 яшьтә) җырчы булмаса да, «Картлар җыры» дип, бер җыр көйләп күрсәтте.

*Кычкырып җырлап җибәрәм.*
*«Тәфтиләү» көйләренә.*
*Башым кайгылардин чыкмый,*
*Яшь кенә көйләремә.*

*Килеп кердем өйләргә,*
*Бүрегем элдем чөйләргә.*
*Яшь вакытта уйна да көл,*
*Калсын сагынып сөйләргә!*

---

[1] *Виноградов Ю. В.* Татарские народные песни / под общ. ред. А. Абдуллина. М.: Музыка, 1964. С. 196 (в соавт. с М. Музафаровым и З. Хайруллиной).

[2] *Фәйзи Җ.* Халык җәүһәрләре. Күңелем кыллары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987.

[3] Татар халык көйләре. Казан, 1955. Б. 41.

*Һаваларда – Чулпан,*
*Суларда – чуртан.*

Авыл клубы мөдире Завьялова Мәүзизәнең сөйләм теле шулкадәр бай, ул мәкаль-әйтемнәр белән генә сөйли. Шуларның кайберләрен генә язам: *Уңган хатын ул китерер, изге хатын кыз китерер; Җикмәсәң дә ат яхшы, сөймәсәң дә кыз яхшы; Сау булсаң – ирең сөяр, бай булсаң – туганың сөяр* һ. б.

Ричапов Мөхәммәтгали абый скрипкада уйный икән, тик аны табып булмады. Ә гармунчылары Мурсалимов Шәйдулла Томскида яши икән.

### ***Умавыл/Омайыл авылы***

21 сентябрь. Иртән иртүк күрше Умавылга килдем. Гөлчирә апага фатирга төштем. Өйләре зур, яхшы. Бу авылда **Пономарёва Гаделбану Абделкадыйр кызы** (1897 елгы) һәм аның ире **Габделҗаббарның** җырлаганнарын яздырдым. Гаделбану апа «Сәйбаттал абый җыры» дип бер җыр яздырды. Сәйбаттал абый әле дә исән, тик җырламый, хәзер аңа 85 яшь икән инде. Матур җыр, ахыры гына бераз кызарып киткән.

*Китәсене дә генә, китә юллар белән,*
*Юлым китте минем лә сул белән;*
*Акылсыз лай бала түгел идем,*
*Акылларым бетте лә уй белән.*

*Җилфер дә генә җилфер йөрмәс идем,*
*Җил тавышкайларын ла сизмәсәм;*
*Өзелеп ләй өзелеп җырламас идем,*
*Советларыбызны мин лә сөймәсәм.*

**Пономарёв Габделҗаббар абый** (1895 яки 1896 елгы) берничә җыр башкарды. Беренчесе – үзе яраткан «Пыяла ишек»:

*Пыяла ишек – җиз тупса, –*
*Ачыла-ябыла җил сукса.*

*Сезе бар чакта сезгәй карыйм,*
*Кемгә карыйм сез юкта?*

*Уй җирләргә су җыела,*
*Шундай былбыл коенай.*
*Безнең гомер шулай уза –*
*Чәчәк булып коела.*

*Пыяла ишек.*
*Габделҗаббар Пономарёв башкара*

Ә менә «Аппагым» – Красноярск өлкәсе Ачинск шәһәрендә революциягә кадәр рус армиясенә атлар сатып йөргәндә ишеткән җыр икән. Аны врач Әхмәтзәки исемле кеше җырлаган.

***Аппагым***

*Безнең дә генәй урман –*
*Калын урман, аппагым,*
*Уртасындай үскән ләй,*
*Алтын алмам, бер тирәк.*

*Сезнең дә генәй кебек*
*Асыл дуслар, аппагым,*
*Аналардин туадыр,*
*Алтын алмам, бик сирәк.*

*Аппагым.*
*Габделҗаббар Пономарёв башкара*

Габделбану апа соңыннан гына исенә төшереп, «Килсен болыт» дигән җыр әйтте. З. Яруллинның атаклы Тукай маршы көенә халык җырлый торган җырларның берсе ул.

***Килсен болыт***

*Килесен болыт, яусын ягымур,*
*Китесен урыманы буенай.*
*Сезенеңе береләне безенеңе дусылыкы*
*Китесене гомере буена.*

*Алай эшләпе тә булмады,*
*Болай эшләпе булмады;*
*Безенеңе советлары килмичә,*
*Рәхәт көннәре булмады.*

*Килсен болыт.*
*Габделбану Пономарёва башкара*

Умавылга беренче булып Муксановлар килгән икән. Пономарёв Габделҗаббар Хәсән улы әйтүенчә, аларның нәселеннән кемдер Казанда пономарь булган. Фамилияләре шуннан килеп чыккан.

Габделҗаббар абый шәҗәрәсе белән дә таныштырды:

*Мансур – 90 яшьтә*
*Маматулла – 78 яшьтә*
*Ибраһим*
*Киләй кеше*

Гаделбану апа да үзенең бабаларын белә:

*Шәйхелислам*
*Мөхәммәтша*
*Абани*
*Сафар*
*Сәтти*

Курчаклар

Авылда курчакларга табыну эзләре дә саклана. Омайылда бер карчык, үләр алдыннан, курчакларын кәрзингә салып,

еракка алып барып ашатып кайткан. Шуннан сәламәтләнгән. Таза гына бер мамай булган ул. Бу хәлләргә 64 еллар узган инде. Әтәләй бабайның хатыны ул. Ә бабай үзе 1916 елны үлгән.

Габделҗаббар абый белән Гаделбану апа халык риваятьләрен дә беләләр.

*Күчем хан белән Ярмак*

*Күчем ханның кызы булган. Бу кызның матурлыгын ишетеп, Ярмак аны үзенә сораган. Күчем хан үзенең кызын бер дә бирергә теләмәгән. Кыз: «Әгәр мин Ярмакка чыксам, ул сезгә сугыш ачмас, сезне бетермәс», – дип, чыгарга риза була. Вәгъдә кылышкач, Ярмак болар ял итеп ятканда һөҗүм итә.*

Омайылда **Сөләйманова Хәбибҗамал апа** (76 яшьтә) бик күп җырлар яздырды:

*Казан ерак, Казан ерак,*
*Казаннан Мәскәү ерак.*
*Кайтыр идем – илем ерак,*
*Кайтмасам, яна йөрәк.*

*Уфадан килүчеләр,*
*Мамык шәл бәйләүчеләр.*
*Яшь урынына кан тамса да,*
*Юк безне жәлләүчеләр.*

*Парахутта без барабыз,*
*Төшеп, сулар алабыз.*
*Кая безгә рәхәт көннәр,*
*Ут эчендә янабыз.*

*Йөгереп төштем су буена,*
*Юдым ак беләккәйләремне.*
*Хәсрәт уты чорнап алган*
*Яшь кенә йөрәккәйләремне.*

**Пономарёва Мәрьям апа** (1908 елгы) да аннан калышмады. Аның башкаруында җырлар гына түгел, бәетләр дә, мөнәҗәтләр дә язып алдык:

*Эликтрлар якты яна*
*Тайга вокзалларында.*
*Бер җибәрми тотар идем*
*Сезне күз алларымда.*

*Быел үләр елларым,*
*Кабрем тирән казыгыз,*
*Баш очыма ташлар куеп,*
*«Бәхетсез» дип языгыз.*

*Быел алган мамык шәлем,*
*Мамык булмаган икән.*
*Теләгән теләккәйләрем*
*Кабул булмаган икән.*

*Каш карасы алдыраем,*
*Кара булыр кашларым.*
*Тагын ниләр күрер икән*
*Бу бәхетсез башларым.*

*Ходаем нигә бирде икән*
*Күз өстемдә кашымны.*
*Агымсуга ташлыйм микән*
*Бу бәхетсез башымны.*

*Каш кара булмаенча,*
*Күз кара булмас инде.*
*Үлеп гүрләргә кермичә*
*Хәсрәтем бетмәс шул.*

*Томскиның урамына*
*Таш сала белмәгәннәр.*
*Сандугачлардан сорадым,*
*Алар да күрмәгәннәр.*

## *Яүштә авылы*

22 сентябрь. Томск каласына якын гына урнашкан тагын бер авыл Яүштә дип атала. Анда шушы исем белән аталган халык – яүштәлеләр, яки яүштә татарлары яши, этник төркем атамасы авыл исеме булып киткән. Бу авыл Томскига кадәр үк нигезләнгән дип сөйлиләр. XVII гасыр башында Тоян Ермашетев, Евага, Басандай кебек кенәзләр яүштәлеләрнең башында торган. Яүштә кенәзе Тоянның Мәскәү патшасына баруы турында мәгълүмат риваятьләрдә сакланган.

Умайылда озак кына машина көттем. Йөк машинасының кабинасында калага килдем. Томск ерактан матур булып күренеп тора. Понтон күпер аша калага йөриләр, ул җәйгә генә эшләнә икән. Ашханәдә ашап, пристаньга төштем. Һәр ярты сәгать Нижнийга катер йөри. Хәзер су киткән. Яүштәгә җәяү бардым. Әйберләрем шактый авыр. Сафура апаларга квартирга кердем. Өе матур, тик зур мич идәнне сыгып төшергән. Кыяр-помидорлары бик уңган. Авылда ике кибет бар. Һәр кешедә телевизор. Тәрәзәдән Томск һәм Почтовый посёлогы күренеп тора. Кич җыр яздырып йөрмәдем, вакытым радио төзәтеп үтте (армиядә мин радиомеханик булдым бит!). Өй җылы, тышка чыгасы килми.

23 сентябрь. Авыл буйлап киттем. Сафура апа бәйнәбәйнә аңлатып, җырчыларның кайда яшәгәнлекләрен өйрәтеп җибәрде.

**Измайлов Гайсә бабай** (1895 елгы, 74 яшьтә) минем өчен зур хәзинә булды. Ул туй җырларын да белә, заманында үзе җырлап та йөргән. Беренче җыры – «Кыз озату җыры». Аны яшь кәләшне кияү өенә озатканда җырлаганнар.

***Кыз озату җыры***






*Киләсең лә, китәсең лә*
*Җиккән атың тирләтеп лә.*
*Газиз бәбекәңне үстердең,*
*Күкрәгеңдә тирбәтеп.*

*Без илләрдин чыккан чакта*
*Җилсез көндә җил-давыл ла.*
*Бергә яшәве (яшәүләр) күңелле,*
*Аерым яшәве авыр.*

*Агыйделнең буйларында*
*Ерактан килгән күбек лә.*
*Газиз бәбкәләре йөри*
*Заклаттагы мал кебек.*

*Кыр казлары биек оча,*
*Каерылмый канаты ла.*
*Сезнең кебек булса булыр*
*Падишаның санаты.*

*Кыр казлары биек оча*
*Урта җирендин өзелеп.*
*Сезнең өчен бәбкәң йөри*
*Эч-бавыры өзелеп.*

*Кыз озату җыры.*
*Гайсә Измайлов башкара*

«Кодагыйларны сыйлау җыры»н Гайсә бабай нәкъ тә туйдагыча уйнап-көлеп, бик тә фасонын китереп җырлады.

***Кодагыйларны сыйлау җыры***
***(Чук-чук сайрый сабан тургае)***

*Өстеңәй кигән күлмәгеңне лә*
*Өстәлләргә салып кистеңме?*
*Чук-чук сайрый сабан тургае,*
*Җалан (гел, һаман) болай килми оңгае.*

*Буең ла зифа, йөзең нурлы ла,*
*Әплисуннар ашап үстеңме?*
*Чук-чук сайрый сабанда тургай,*
*Гомерләрне бирсен күп елгай.*

*Аягыңдагый итегең лә шул,*
*Мәкәрҗәдән килгән олтаны.*
*Чук-чук сайрый сабанда тургай*
*Җалан болай килми оңгае.*

*Сез дускайларым исән булгач ук,*
*Ник җалыныйм икән ятларга?*
*Чук-чук сайрый сабанда тургай,*
*Гомерләрне бирсен күп елгай.*

*Чук-чук сайрый сабан тургае.*
*Гайсә Измайлов башкара*

Икенче көнне иртән кибеткә кереп, 20 сум 40 тиенгә ботинка алып чыктым. Тегесе тетелеп беткән иде. Олтаны Мәкәрҗәнеке булмаса да, ярап тора безгә! Шул дәрт белән хуҗаларга утыннарын кисеп-ярып та ыргыттым. Сафура апай тозлаган кыяр белән сыйлады үземне.

23 сентябрь. Яүштә авылында эшемне дәвам итәм. **Мәүлекиева Разия апа** (1920 елгы) миңа ике җыр яздырды.

«Агыйдел кичтең мәллә» җырын ул яшьтән бирле көйли. Әлләни үзенчәлекле җыр булмаса да, башкаручы аның аша үзенең үтмәс кайгы-хәсрәтен җиткерә – ул якты дөньяларны күрә алмый яши.

Ә аның «Агыйдел билемдин» җырын күңелемә бикләдем дә гел көйләп йөрим.

***Агыйдел билемдин***

*Агыйдел билемдин,*
*Чыгармын сай җирендин.*
*Хак Тәгалә аермасын*
*Туып үскән илемдин!*

*Агыйдел кичкәндә,*
*Ишкем сынды ишкәндә.*
*Бер җырлыймын, бер җылыймын*
*Дуслар искә төшкәндә.*

**Әминова Гайшә апа** (1900 елгы) җырлаган «Картлар җыры» күптәнге туй-мәҗлес көе икән.

***Картлар җыры***

*Челтәрле күпер астында*
*Каз канатын төзәтә.*
*Алтын тәхет, биресене бәхет,*
*Бәхет күркәм күрсәтә.*

*Эстинада ике көзге,*
*Матур күрсәтә йөзне.*
*Сез онытсагыз да безне,*
*Без онытмабыз сезне.*

**Мозаффаров Ибраһим абый** (1901 елгы) «Мәҗлес җыры» һәм «Әтием җыры» дип яздырган көйләрен туган авылы Берёзкинода әтисе Гайдуштан отып калган икән. Традицияләрнең дәвам итүе бу. Бик күпләр шулай әти-әниләренең җырларын җырлый-җырлый саклап яшиләр.


**_Мәҗлес җыры_**




*Ай-хай ла дигән ай тавышкай,*
*Сары лай төлке кача лай камышкай.*
*Үлмәгәч бәндә лә үлми икән.*
*Эчкәйләрей тулы лай сагышкай.*
*Ат җибәрдем тирән ләй елгагай,*
*Сер бирмийек фани ла дөньягай.*

Һәм менә зур табыш – «Хан кызы». Аны **Низаметдинов Гомәр бабай** (1895 елгы) әйтте. Мин бу җырны бик эзләгән идем, күп җырчылардан сораштырдым да. Ниһаять! Бөтен төрки дөньяда билгеле җыр бездә дә бар икән!

***Кан кызы***




*Кан кызы, ач ишегең, бән керәем,*
*Сәнең йөзең нурлы диләр, бән күрәем.*
*Бәнем йөзем күреп сиңа нидер файда,*
*Сатучыда күрмәдеңме кызыл алма?*

*Кан кызы, ач ишегең, бән керәем,*
*Синең буең зифа диләр, бән күрәем.*
*Бәнем буем күреп сиңа нидер файда?*
*Су буенда күрмәдеңме буй-буй камыш?*

Тамырлары Мөслим ягыннан булган **Хәлиуллин Зәйнулла Вәлиулла улы** (1904 елгы) үзебезнең як җырларын – «Кара урман», «Агыйдел», «Сак-Сок»ны яздырды. **Зәбирова Шәфига апа** элеккеге җыр дип җырласа, Мөнирә апа ике бәет әйтте.

**Мәүлекиев Габдулла бабай** (1890 елгы) «Рус-япон сугышы бәете»н белә икән. Аны көе белән әйтеп бирде:

***Рус-япон сугышы бәете***

*Тугыз йөз дә дүртенчедә сугышларга башладык,*
*Сугышка дип хәбәр килгәч, вольный кием ташладык.*

*Бу бәетне язамын, искә алсын туганнар,*
*Хәзерендәй безләрне сугышларга куалар.*

*Бу бәетне язабыз ничә солдат җыелып, –*
*Көне-төне җылаганга, бетте яшем коелып.*

*Укучы, дим, үтенәмен, гаеп кылма карарга,*
*Чибәррәк тә язар идем, табып булмый язарга.*

*Ачы суык җилләр исә, өскәй карлар сылаша,*
*Машинага утырганда, туганнарым җылаша.*

*Караңгы төн, ачы буран, ачып булмый күзләрне,*
*Колакларым ишетмидер «Сау бул!» дигән сүзләрне.*

*Бузгат сорнай уйнаганда күңлем тулып еладым,*
*Аерылып киткән чакта бик моңаеп җырладым.*

*Камышлыный чыккан чакта аяк асты баткылак,*
*Йөзе кара японецлар калды безгә аткалап.*

*Сары диңгезнең өстендә дулкын булды давылга,*
*Яйсез булган чыгарга, барып төштек авылга.*

*Ранинуслар[1] килә иде, Ходаем юлны бирер дип,*
*Кем уйлаган бу эшләрне безнең башка килер дип.*

Яүштәлеләрнең сөйләме әдәби телгә якын булса да, кайбер үзенчәлекле сүзләре бар. Мәсәлән: *абра* – арба, *байбак* – оек, *таңда* – иртәгә, *шабала* – кашык, *кипәк* – күлмәк, *чапчак* – кисмәк, *ырбан* – көрпә.

**Манапова Сәрвәр апа** (1905 елгы) Даян кенәз турында риваять сөйләде:

*Кенәз Даян*

*Кенәз Даян городокта торган. Икенче кенәз Басандайка (аның торган урыны бар, каладан 7 км чамасы) булган. Алар икесе сугышканнар. Таудан тауга, ике тау арасы 10 км,*

[1] Ранинуслар – *броненосец* сүзе бозып әйтелгән.

*балта ыргытканнар. Нинди көчле булганнар! Даян җиңелгәннән соң, бирелмәс өчен, үзләрен үзләре тереләтә күмгәннәр. (Ике кенәз дә мөселман булганмы, бу турыда Сәрвәр мамай белми.) Городок янында Кнестаян речка бар. Моңа 400 елдан артык. Әле Томски, аңа 350 ел гына, булмаган. Яүштә кешеләре йөк берлән Иркутскига йөргәннәр. Безнең доходны алыр дип, тимерьюл салдырмаганнар. Элек монда гел байлар булган. Чәй, манфактур белән эш иткәннәр. «Теплый» авылы («Теплоречка») бар, сәүдәгәрләргә шул авылдан үтү бик авыр булган. Юлбасарлар, караклар булган анда.*

*Чәкә мулла*

*Чәкә мулла дигән бер мулла булган. Чын исеме Җәләлетдин Кучкильдинов. Ул туйда скрипка уйнап, биеп кенә йөргән. 62 еллар элек яшәгән. Аның малайлары да скрипкада уйнаган. Өч малае, ике кызы булган. Хатыны яшьләй үлгән, башка өйләнмәгән, хатынсыз торган. Әле ул авыруларны да дәвалаган, лекарь да булган, шприслары да булган, кешеләргә укол да ясаган. Төрле авыруларны дәвалау ысулларын белгән. Бер апаны корчаңгыдан коткарган.*

*Яшьләргә никах укыган.*

*Аның өстеннән Хәмзә мулла жалу белән йөргән, ул бай булган.*

Сәрвәр мамайның әтисе Мөхәммәтҗан «кредитное товарищество»да эшләгән. 300 сум акча алган. Аңа алты ат алып булган.

*Исән бул, Том каласы,*
*Лагерь тауларың белән.*
*Сез булмагач, мин нишләрмен*
*Дөнья маллары белән?*

*Былтыр тартты уң кашым,*
*Быел тарта сул кашым.*
*Ни күрсәм дә күрәм инде,*
*Күрергә калган башым.*

26 сентябрь. Томск өлкәсенең Яуштә авылыннан Кемерово өлкәсенең Юрга районына юл тоттым.

Яуштәдән көндез чыгып киттем. Нижнийдагы катерга биш минутка соңга калганмын. Икенчесен бик озак көттем. Суда бару рәхәт. Барып җиткәч, такси белән автовокзалга киттем. Автобус та, машина да юк. Планымны үзгәртеп, тимерьюл вокзалына юнәлдем, 17.30 да Томск-Бийск поездына утырдым. Юргага төнлә генә килеп төштем. Шунысы яхшы: гостиницада урын булды, кундым.

27 сентябрь. Юрга чибәр генә, чиста шәһәр. Көн салкынча. Үземнең максат һәм бурычларымны аңлатып, Юрга шәһәр комитетына барып килдем.

КЕМЕРОВО ӨЛКӘСЕ


*(1969 елның 26–27 сентябре)*

## Юрга районы

### *Кышлау авылы*

Бер шофёр Кышлау юлына китереп куйды. Кышлауның сөт ташучы машинасында арбада килдем. Яхшы гына бер апада фатир таптым.

Кышлауга килеп төшүгә, **Шулаяков Гафур бабай** белән очрашу турында сөйләшеп куйган идек. Гафур бабай Себердә мин язып алган җырчыларның иң-иң өлкәне – аңа 87 яшь. Ул мине бик яхшы каршы алды, энесе **Шулаяков Сөнгатулла абый да** (1900 елгы) янында иде. Бер-берсенең сүзен



Кышлау авылыннан
Шулаяков Гафур абый

хуплап, бер-берсенә көч биреп торалар, җырларны да шул рәвешле яздырдылар.

Иң элек Гафур абыйның «Кыз озату җыры»н яздырдык.

***Кыз озату җыры***

*Китәсең, туганым, ай, китәсең,*
*Атларга да авыр итәсең.*
*Атларга да авыр, ятка җиңел,*
*Әткәң-әнкәң ташлапы китәсең.*

*Өстеңә лә кигән күлмәгеңне*
*Керләнсә дә салып җуарсың.*
*Әткәң берлән әнкәң исеңә төшсә,*
*Аулак җиргә чыгып җыларсың.*

*Кыз озату җыры.*
*Гафур Шулаяков башкара*

Мин бу җырны беренче мәртәбә 1968 елның көзендә Новосибирск өлкәсе Чаны районы Белекте авылында Йосыпова Шәмсенур ападан «Тамчы тама» исеме белән язып алган идем. Шәмсенур апа миңа бу җырны Кемерово өлкәсендәге Кышлау һәм Эскәтем авылларында җырлауларын да әйткән иде. Һәм менә быелгы көзге экспедиция шушы җырны ачыклау өчен махсус оештырылды дип әйтергә дә мөмкин.

Гафур һәм Сөнгатулла абыйлар миңа бу җырны күрше Эскәтем авылыннан Тәминдаров Сәгыйрь абыйның яхшы белүен әйттеләр. Тик ул хәзер... Казанда яши! Алар миңа Сәгыйрь абыйның адресын бирделәр. Һәм без аның белән күрештек.

Гафур абыйның икенче җыры – «Ишек бавы җыры».

**_Ишек бавы җыры_**

Җиңгиләр:

*Саранланыр чак түгел,*
*Бир, кияү, комсызланма;*
*Акча бирми keретмәбез,*
*Тукта, сабырсызланма.*

*Бирсәң бир син күп безгә,*
*Без риза түгел азга.*
*Яудыр алтын-көмеш безгә,*
*Бакыр төрмә кәгазьгә.*

*Синең җанашың булса,*
*Ул бит безнең апабыз.*
*Акча бирми керетмәбез,*
*Бу бит – җәннәт капкасы!*

Егетләр:

*Урамнардан үтәргә,*
*Коймаң биек сүтәргә.*
*Җырны озак җырлатмагыз,*
*Төннәр кыска көтәргә.*

*Пыяла шкаф эчләрендә*
*Пешкән алма тәгәри.*
*Оҗмахтагы хур егете*
*Булмас кияү кадәре.*

Бу җырның икенче исеме – «Кияүне кыз куенына кертү җыры».

Гафур абый «Тау башында таш тегермән» җырын да яздырды. Ул аны якынча гына белә икән. Җырның авторы – Тәминдаров Сәгыйть абый, аңардан сорарга кирәклеген искәртте.

Ә менә «Хатынымны аердым» җыры минем өчен зур яңалык булмады. Җырның бер вариантын үзенә үзгә көе белән

мин Татарстанның Әтнә районы Олы Бәрәзә авылында әнием Сабитова Зәкиябанудан (1919 елгы) отып алган идем. Беренче куплет шул ук:

*Якшәмбе көн сәгать унда*
*Хатынымны аердым;*
*Хатынымны аердым да*
*Ялгыз торырга булдым.*

Олы Бәрәзә көенең үтә оригинальлеге гаҗәпкә калдыра. Безнең көйме ул, әллә башка халыкларныкымы? Һәрхәлдә, кайбер музыкантларга һәм музыка белгечләренә мөрәҗәгать итү дә әлегә нәтиҗәсез калды.

Гафур бабай җыры хатын аеруның мәгънәсезлеген аңлаткан түбәндәге юллар белән тәмамлана:

*Ялгыз тору читен икән,*
*Алып кайттым хатынны.*
*Әнә шуның белән инде*
*Саттым яман атымны.*

Гафур һәм Сөнгатулла абыйлар миңа тагын бер бик кызык бәет яздырдылар. «Әбделмән купец бәете» ул. Бертуган Шулаяковларның әйтүенә караганда, Әбделмән атлы купец Сембер губернасыннан шушы якларга сөргенгә җибәрелгән имеш. Үзе белән көен дә алып килгән.

***Әбделмән купич бәете***

*Әбделмән купичның илле бер ялчысы баралар главныйга урманга.*
*Бу ла бәлалардан Ходай коткарса иде, мең куй суяр идем корбанга.*

*Әбделмән купичның икедер хатыны, кигән киемнәре лә шау ука.*
*Судьялар илтәләр хөкем залларына, һичбер адәм чыкмайдыр порукка.*

*Ай да бу сарайлар, вай да бу сарайлар, эчләренә тулырлар варайлар*[1]*,*
*Ислам динен хурлап утыралар Сембер өязендәге боярлар.*

*Ишегем алдына таш түшәлгән иде, судьялар йөри-йөри баз булды.*
*Унике генә пот кәгазъ акчам иде, башымны йоларга ла аз булды.*

*Гыйгыл да гына гыйгыл, ниләр гыйгылдый Әбделмән купичның ук казлары.*
*Сембер өязендә елашып йөриләр Әбделмән купичның ук кызлары.*

*Алтын суга торган алтын өстәлемне, сал, әнкәй кабәм, ук грәзгә.*
*Конюшняда үскән кара айгырымны бир, әнкәй кабәм, ук кенәзгә.*


*Унике лә ташлы тегермәнем, акчам кая киткәнен белмәдем.*

Кышлау авылында **Таһир Селивановтан** (1905 елгы) әсәрнең түбәндәге юлларын да язып алдык:

*Әптелман бай куписның*
*Ишегалды сарайлар,*
*Сарайларгай эленгән тарайлар.*
*Әптелман бай куписның*
*Аяклары димен лә.*
*Баструк тирәзәсендин карайлар*
*Дим елгаларының буйларында димен лә.*
*Унике иде минем тирмәнем,*
*Кешеләргә дә генәй ай бирмәдем, димен лә,*
*Үзем дә изгелеген күрмәдем.*




[1] Варай – шаһит.




Сөнгатулла абыйның репертуары шактый киң: «Хуш, авылым» (С. Сәйдәшев җыры), «Саз» (Г. Тукай сүзләре), «Айбулгин Хәлил җыры», «Көй», «Кызны озату җыры», «Хатынымны аердым», «Ак тирмәләр», «Зәйнәбем» , «Кама буйлары» һ. б.

***Гыйззелбанат***

*Томскиның пароходы,*
*Күрмәдем күмелгәнен.*
*Күтәрелми күңелләрем,*
*Кыскадыр гомерләрем.*
*Гыйззелбанат, яулыгың,*
*Уйнамыйсың да көлмисең,*
*Әллә юкмы саулыгың?*

«Кама буйлары» җыры, Сөнгатулла абыйның әйтүенә караганда, Казан ягыннан килгән. Бәлки бу хактыр да. Җырның эчтәлегенә килсәк, сүз Кама елгасы турында бара һәм беренче яртысында аның «Уракчы кыз» көенә тартымлыгы моңа нигез була алыр иде. Шулай булуга карамастан, көйдә логик эзлеклелек бар. Ул мөстәкыйльлеккә дәгъва итә ала дип уйларга кирәк. Шунысы бик тә кызык: соңгы бер-ике елда (2020–2023) «Мәйдан» TV каналында Кама Тамагы яшьләренең шушы көйнең бераз кызурак варианты белән түгәрәк уен уйнаганнарын күрсәтәләр. Күңелем бик сизә – монда ниндидер бәйләнеш бар!

***Кама буйларында***

*Кама буе сиңа таныш түгел,*
*Җалгыз гына чыгып буйлама.*
*Онытмадым, туган, һич онытмыйм сине,*
*Онытылырмын диеп лә уйлама.*

*Кама буйларында бик күп җөрдем,*
*Туймам инде шаулый Камадан.*
*Чын мәхәббәт дигән Камадан да тирән,*
*Очрашырбыз әле җангадан.*

*Кама буе сиңа таныш түгел,*
*Җалгыз гына чыгып буйлама.*
*Ара җырак, туган, хатлар сирәк килсә,*
*Оныткандыр диеп лә уйлама.*

*Кама буйларында бик күп җөрдем,*
*Җәйнең матур алсу таңында.*
*Җәйнең таңнарында, Кама җарларында*
*Очрашырбыз әле тагын да.*

Казанга кайткач, мин бу җырны Сәгыйрь абыйга һәм аның хатынына Фрунзе урамындагы шәхси йортларына магнитофонны алып барып тыңлаттым. Күзләреннән яшьләр килде! Бүгенге көндә дә телевидение аша җырлы сәламнәр җибәрәләр. 1970 елларда «Хатлар укыганда» тапшыруын Әминә апа Сафиуллина алып бара иде. Ягез, Илгиз Кадыйров Себер татарларына хезмәт итмәде дип кем әйтер икән!

Кышлауда өченче җырчым **Мансурова Һәдия апа** булды (1904 елгы). Шулаяков Гафур абый җырлаган «Кыз озату җыры»н ул миңа «Дамбов көе» дип яздырды (Дамбов – елга исеме икән).

***Дамбов көе***

*Сайрамачы, былбыл, ник сайрыйсың,*
*Өзелә үзәк синең тавышка.*
*Чыдасы да бәндә чыдый икән,*
*Күкрәгендә тулый сагышка.*

*Иртә торып, шулай, сөлге чиктем,*
*Сөйгәнемә дигән сөлге иде.*
*Әрни йөрәгем, әрни, урын тапмый,*
*Шулай әрнер микән мәңгегә.*

Һәдия апаның да үзенең «Кыз озату җыры» бар. Тик моның көе башка инде.

***Кыз озату җыры***




*Һаваларда очкан ай аккошның*
*Аякыларый сарый ла балавыз шул.*
*Сагынулар түгел, саргаербыз,*
*Кулыгызда үскән балагыз шул,*
*Кулыгызда үскән балагыз.*

Һәдия апа бераз карлыкканрак тавыш белән бик тә яратып, иплэп кенә «И былбылым»ны («Егет белән кыз җыры») җырлаганда, үзем дә кушылып утырдым. Туй уены җыры икән бу. Туйларны күркәмләндереп җибәрү өчен, өлкәннәр

егет-кыз булып, яшь чак – җүләр чакларын кабатлап, бераз кызмача кода-кодагыйларның, туган-тумачаларның түрдә, бәхет тәхетендә утырган кияү-кәләшкә ымлап җырлана торган җыры икән. Һадия апа әйткәнчә, бу җырны мәҗлесләрдә һәм кич утырганда яшьләр үзләре дә җырлаган. «Яшь вакытларда була инде ул андый күңел ачулар», – дип тә өстәп куйды Һадия апа моңсуланып.

### *И былбылым*

*(Егет белән кыз җыры)*




Егет:

*И былбылым, куна торган*
*Талларыңны сындырам шул,*
*Былбыл итеп барчагызны*
*Күкрәгемә кундырам.*

Кыз:

*Карлыгандин каклар коеп,*
*Алма белән йөзләрмен шул.*
*Сезне төшләремдә күргәч,*
*Таңнар аткач эзләрмен.*

Егет:

*Эзләдең син, эзләдең син,*
*Эзләдең син саф күңел.*
*Эзләдең, таптың, югалттың,*
*Инде табылачак түгел.*

Кыз:

*Алмагачтин алма төшеп,*
*Тәгәри бөтен булып.*
*Һичкем сүзе арабызга*
*Кермәсен төтен булып.*

Егет:

*Гөл бакчаларына кердем –*
*Бадиян түтәлләре.*
*Синнән башка һич берәү дә*
*Кирәкми бүтәннәре.*

Кыз:

*Сандугач сайрый да әйтә:*
*Телләрем талды, диеп.*
*Алма да әйтә,өзелеп төшкән*
*Агачым калды, диеп.*

Егет:

*Сызыла-сызыла, сызыла күңелем,*
*Сызыла бертуктамыйча;*
*Сызыла айлар, сызыла еллар,*
*Сызыла төн йокламыйча.*

*Сызылып-сызылып син мәхәббәт*
*Ялкының гөлләр яса;*
*Мәңге хәсрәт һәм караңгы*
*Төннәрне көннәр яса.*

Кыз:

*Там-там яшем, дәрья булсын,*
*Дөньяны су капласын.*
*Күкрәгемдә бер өмет бар,*
*Тик шул гына батмасын.*

**Фәйзуллин Абдулгани абыйдан** (1900 елгы) «Рамазан бабай җыры»н язып алдым. Көй ашыкмыйча, үзенә бертөрле ягымлы итеп башкарыла. Бу җыр элекке вакытта туй-мәҗлесләрдә яңгыраган.

*Чәчтем бодай, бирде Ходай*
*Бер бодайдан мең бодай.*
*Сезне бездин, безне сездин*
*Аермасын бер Ходай!*

Кышлауда **Коникова Рәхимә апа** (1905 елгы) «Туган як көе», «Дусларым» җырларын яздырды. Җырчының әтисе Башкортстанның Туймазы районы татары икән. Ул бу җырны «туган ягымныкы» дип җырлый торган булган.

*Уйлыйм сезене, дусларым, уянам да,*
*Таң әтәче канат какканда, и какканда.*
*Уйлыйм сезне таңнар атканда, атканда.*

**Әптерәшитова Миңнуш апа** (1912 елгы) да үзенең әтисе җырлаганны яздырды. Әтисе Габделҗәмил 1909 елны Самарадан күчеп килгән.

***Бадиян баскыч***

*Казаннардин Мәскәү күренер микән*
*Бадиян басыкыч куеп карасаң?*
*Сезнең тавышыгыз ишетелер микән,*
*Сандугачлар булып сайрасам?*
*Ал кирәкми безгә, гөл булса,*
*Ят кирәкми безгә бит, сез булса.*

«Яшел чирәм»не мин магнитофон тасмасына Кемерово өлкәсе Юрга районы Кышлау авылында **Мансурова Хәдия** (1900 елгы) мамайдан язып алдым.

*Ишегалдым яшел чирәм,*
*Йөгереп чыгам оекчан.*
*Тулган айларга карыймын,*
*Бик сагынып боексам.*

Җырның исемен Хәтимә мамай «Бабам җыры» дип яздырды. «Әтиемнең әтисенең йыры бу, балам», дип тә өстәде. Искиткеч матур, күңелгә тиз сеңеп кала торган җыр бу. Хәтимә мамай аны сузып, ашыкмыйча, һәр сүзен җиренә җиткереп, үзенең бераз карлыккан тембры белән көйли. Көй белән шигъри сүз бер-берсенә аерылмаслык булып береккән.

«Бабам бик оста җырчы булган, туй-мәҗлесләргә ераклардан килеп алып киткәннәр», дип сөйли Хәтимә мамай. Аның үзен дә еш кына кунак-төшемгә чакырганнар. Сәгыйрь абый Тәминдаровның туена күрше Эскәтемгә барып та җырлаган ул. Җитмәсә, Хәдия мамай кыз озату җырларын да белә икән. Яшьрәк вакытта кияүгә китәсе кызның чәчен икегә аерганда, аны җырларга чакырганнар. Чәчне кызның җиңгәсе яисә апасы икегә аерып үрә. Җыелган бар халыкны елатырлык итеп җырлый белергә дә кирәк бит әле! Моны бөтен кеше булдыра да алмый. Шуңа күрә, бу бик тә җаваплы йоланы үтәгәндә, иң талантлы җырчыларны гына чакырганнар.

Тагын бер кызыклы күзәтүем бар. Бу җырны тизрәк көйли башласаң, өлкән буынга мәктәп елларыннан таныш «Ком бураны» җыры килә дә чыга.

*Ишегалдым яшел чирәм*... Бу җыр минем хәтеремдә балачактан уелып калган.

*Ишегалдым яшел чирәм,*
*Мәтерүшкә түгел ул.*
*Күпме сөйсәң дә бер булыр,*
*Яр фирештә түгел ул.*

Монысын минем әнием кайвакыт җырлап куйгалый иде. Тавышы матур иде әнинең. Әтине мин хәтерләмим. 1940 елда ул хәрби хезмәткә киткәндә, мин тугыз айлык булып калганмын. Шул китүеннән әти кайтмады, 1941 елда хәбәрсез югалды. Әти – гади колхозчы баласы, үз тырышлыгы белән авыл укытучысы дәрәҗәсенә күтәрелгән кеше.

22 яшендә өч бала һәм кайнана белән тол калган әни 40 ел балалар укытты. Сугыш вакытында – директор, сугыш беткәч, завуч булды.

Кышлауда шушы авыл кешеләре Шиганбаева Миңнезифа, Сираҗетдинова Нәгыймә, Кинҗагулов Дәүли, мәктәп директоры Кинҗагулов Шәүкәт, гармунчы Сираҗетдинов Һидият, Шулаяков Мәгъзүм, Камәр мамай белән аралаштым.

**Губаев Миншаһи Әхмәтсафа улына** 88 яшь (1881 елгы). Ул Шулаяков Гафур абыйдан да 1 яшькә олы булып чыга! Бу үзенә күрә рекорд – минем Себердә язган җырчылар арасында Миншаһи бабай иң олысы икән бит!

Шунысын да теркәп куйыйк әле: Гафур абый минем янга соңыннан килеп, «Бәет» яздырып китте. Бер хатынның ире чәшке (су җәнлеге) ауларга киткән дә кайтмаган. Боз астына китеп һәлак булган. Шушы фаҗига уңаеннан бәет чыгарганнар. Бу – ерак Себердә, төгәлрәге татар халкының фәнни әдәбиятта калмаклар дип йөртелгән этник төркемендә дә бәет чыгару традициясенең дәвам итүен күрсәтә торган факт.

27 сентябрь. Күп яздым. Кичен апаларга бәрәңге алыштым. Көндез алар печәнгә бардылар. Өчпочмак пешереп сыйладылар. Арыла. Көндез бераз черем итеп алдым.

29 сентябрь. Бүген бик шәп итеп мунча яктылар. Себергә дүртенче экспедиция ахырына якынлаша.

30 сентябрь. Минем өчен махсус пилмән пешерделәр. Селиванов Таһир абый, өйгә килеп, Абитов Биктимер абый җырын яздырып китте («Бер мәхәббәт»). Авторитет зур абзагызның, җырчылар мине үзләре эзләп килә!

1 октябрь. Иртән Заһид Юргага илтеп куйды. Көндезге сәгать икедә Томскига автобус китә.

Кышлау эпопеясы Казанда дәвам итте. Кайту белән Сәгыйрь абыйны эзләп таптым. Һәм эшкә – Тел, әдәбият һәм тарих институтының музыка кабинетына чакырдым.

Кышлауда күптән булмаган икән, мин үз күргән-белгәннәремне бәйнә-бәйнә сөйләп бирдем. **Тәминдаров Сәгыйрь** (1889–1975) – Ленин орденлы укытучы. Тумышы белән Кемерово өлкәсе Юрга районы Эскәтем авылыннан. Әтисе чыгышы белән Чистай ягыннан. Себергә килеп өйләнгән. Әнисе – Алтай ягыннан. Ул курчакка табына торган булган.

Сәгыйрь абый – чын мәгънәсендә тылсымлы җырчы, искиткеч моңлы, катлаулы бик тә сизгер мелизм бормасырмаларын гаҗәеп төгәл көйләүче түбән бас тавышлы тембр иясе. Иң беренче ул «Җир бәете»н көйләп бирде. Бу якларда җир өчен бик каты көрәш барган.

***Җир бәете***

*Өч борадәр – туганнар.*
*Бик куәтле булганнар.*
*Тимер Мылтык, Эшкә Иркә,*
*Балык Би исемле булганнар.*

*Күп җирләрне алганнар,*
*Бик күп җиргә салганнар.*
*Монда килеп туктаганнар,*
*Хан булырга уйлаганнар.*

*Унсигез семьяны алып,*
*Урыс ханына барган.*
*Ханлыкны да, халыкны да*
*Балык кулына алган.*

*Авырган олы туганы*
*Бу эшкә ачуланган...*
*Туган бәддога кылган –*
*Уңма-үрчемә, дигән;*
*Аты да аламан, йөзе дә илтәк[1],*
*Алсын дип дога кыйлган.*

[1] Аты да аламан, йөзе дә илтәк – казах телендә аламан сүзенең юлбасар дигән мәгънәсе бар (Йөзгә куркыныч юлбасар).

*Шуннан калган җиребезне*
*Алдырдылар аталар.*
*Алтын кебек җиребезгә*
*Тулды ак чабаталар.*

Сәгыйрь абый башкарган «Таһир – Зөһрә» җырының көе бик үзенчәлекле – «Крутится, вертится шар голубой» җыры көенең татарча варианты. Кем белә аны, бәлки киреседер дә?

Сәгыйрь абый һәм аның дуслары әле революциягә кадәр үк туган авыллары Эскәтемдә «Таһир – Зөһрә» пьесасын уйнаганнар. Таһир ролендәге Сәгыйрь абый нәкъ менә шушы җырны җырлаган, Зөһрә ролен аның хатыны Гөлсем апа башкарган. Тамашаны карарга авыл муллалары да килгән. Спектакль уңышлы чыккан, башка татар авылларында да күрсәткәннәр. Тамаша кем әсәре булгандыр, ул турыда Сәгыйрь абый мәгълүмат калдырмады, һәрхәлдә, төп сюжет линиясе итеп Әхмәт Уразаев-Кормашиның «Таһир илә Зөһрә кыйссасы» яки Ф. Бурнашның «Таһир – Зөһрә» трагедиясе алынгандыр. Беренчесе 1876 һәм 1911 елларда Казанда басылса, икенчесе 1916–1917 елларда язылган.

Җыр тексты, аз гына үзгәрешләр белән, Кормаши әсәрендәге текстка тәңгәл килә. Тик анда бишенче куплет кына юк.

Хан кызы:

*Таһире затыңы пәримә,*
*Фирештәме, хурийма?*
*Бу яралган җисемегес*
*Яшел җәүһәр нурыйма?*

Таһир:

*Мин – Зөһрәнең ярыйман,*
*Кара зөлфи*[1] *дариман;*
*Синең гүзәл хөснеңә*[2]
*Хәйран булып карыйман.*

---

[1] Зөлфи – зөлф, биткә төшкән чәч бөтеркәсе.
[2] Хөсне – хөсен, матурлык, гүзәллек.

Хан кызы:

*Саф мәхәббәт бар микән,*
*Синең сөяр яр микән,*
*Синең өчен зар микән,*
*Сине сөяр яр микән?*
*Бер хуп назар*[1] *кыйлсана,*
*Зөһрә миндәй бар микән?*

Таһир:

*Сәрви назым минем юк,*
*Хөснеңә һич сүзем юк.*
*Гакылым Зөһрә алгандыр,*
*Сине күрер күзем юк.*

Хан кызы:

*Мәгъсүманә*[2] *һәр җирем,*
*Нәзек, зифа бу билем.*
*Ирнем шифа хәстәңә,*
*Дәрткә дәрман һәр җирем.*

Таһир:

*Матур булсаң мең һазар,*
*Берен кыйлмам ихтыяр;*
*Зөһрәм белән вәгъдәм бар,*
*Һич сөймәс мән бүтән яр!*

*Таһир–Зөһрә.*
*Сәгыйрь Тәминдаров башкара*

Әйе, Себер татарларын өйрәнүчеләр өчен монда мәгълүмат бар.

---

[1] Хуп назар – матур караш, җылы караш.
[2] Мәгъсүманә – гөнаһсыз, керсез, кимчелексез.

Инде бүгенге көннәрдә дә радиодан яңгырый торган «Тау башында таш тегермән» җыры турында берничә сүз. Мин аны Кышлауда Гафур һәм Сөнгатулла абыйлардан язып алган идем. Ә Сәгыйрь абый башкаруында ул бөтенләй патриотик рухта яңгырый кебек. Кайберәүләр моны «Себер гимны» дип тә әйтә.

*Һәй!*
*Тау башында таш тегермән,*
*Яшь бодай тарта микән?*
*Егет үзе картаймаса,*
*Дөнья картайта икән.*

Кышлауда аны: *Кызлар картайта икән,* дип тә җырлыйлар.

*Һәй!*
*Алмагачның ботагына*
*Тайлар бәйләсәң иде.*
*Рәхәтләнеп, бергәләшеп,*
*Җәйләр җәйләсәң иде.*

Җырны Таһир Якупов өйрәнде һәм радиога яздырды. Шулай ук Закир Шаһбан да, текстын бераз үзгәртеп, радиодан башкарды.

***Зәйнәбем***

*Син – минем якты кояшым,*
*Күз нурым, җәннәт хурым.*
*Ай җаный, Зәйнәбем,*
*Үтә рәхәт җәйләрем лә,*
*Үтә рәхәт җәйләрем.*

*Син – мәхәббәтле күңлемнең*
*Сайрый торган былбылы.*
*Ай җаный, Майтабым,*
*Хуш, исән бул, кайтамын, шул,*
*Хуш исән бул, кайтамын.*

*Кашларың да, күзләрең дә,*
*Күзләрең – керфекләрең.*
*Ай җаный, Зәйнәбем...*
*Әллә мәрмәр, әллә мәрҗән,*
*Керфегең бөртекләрең.*

*Ай җаный, Майтабым...*
*Бөрлегән күк кызыл иренең*
*Бал микән, гәүһәр микән?*
*А, җаный, Зәйнәбем...*

*Йолдыз кебек ялтыраган*
*Тешләрең җәүһәр микән?*
*Ай җаный, Майтабым,*
*Хуш, исән бул, кайтамын, шул,*
*Хуш, исән бул, кайтамын.*

Минем үземә Сәгыйрь абыйның «Димен лә» җыры да бик ошады. Мин аны бик тиз нотага салдым һәм җырчының үзенә җырлап күрсәттем. Ошатты. «Юкка гына җырлар җыймыйсың икән!» – дип куйды.

*Ялан да гына җирдә, бигрәк ямьле, димен лә,*
*Ак тирмәләр корып җәйләргә,*
*Ак тирмәләр корып җәйләргә;*
*Кайда гына йөрсәң, дус-иш кирәк димен лә,*
*Йөгереп чыгып атыңны бәйләргә!*
*Йөгереп чыгып атыңны бәйләргә!*

Җырның соңгы куплеты – алтынчысы бигрәк фәлсәфи яңгырый:

*Ялан да гына җирдә ялгыз тирәк димен лә,*
*Яфракларын ярса да күрке бар,*
*Яфракларын ярса да күрке бар.*
*Каһәрләрен салган явыз тормыш, димен лә,*

*Рәхимнәрен салса да ирке бар!*
*Рәхимнәрен салса да ирке бар!*

*Димен лә.*
*Сәгыйрь Тәминдаров башкара*

Бүген 2023 елның 14 августы. Бер айдан Кышлауда булганыма 54 ел тула. Җырчыларның тембры әле дә колагымда. Чөнки көйләрне нотага төшергәндә – ә бу процесс коточкыч авыр һәм четерекле гамәл – аңлашылмаган урыннарны күп мәртәбәләр тыңлыйсың. Себер татарларының диалекталь сөйләме һәм җырлау үзенчәлекләре бик катлаулы. Язып алганда аңлашыла кебек, ә тыңлый башласаң – фонетик системаның Себердәге «саз»ларына чумасың. Өч төркем бит алар: тубыл-иртыш, бараба, том диалектлары. Мондагы орфоэпия нормаларында йөзү өчен үзеңә тел белгече булу кирәк. 70 нче елларда Себер татарларының фонетик системасы һәм графикасы бик буталчык иде бит. Бер үк җырчы һәр куплетны төрлечә әйтеп җырлый. Бер яктан, күбесе мәктәп-мәдрәсәләрдә, татар мәктәбендә укыган, әдәби телне яхшы белә, икенче яктан, туган ягының сөйләм үзенчәлекләрен дә саклый. Шул рәвешле, кайвакыт бер җыр эчендә төрлелек килеп чыга. Нәрсә ишеттем, мин шуны кәгазьгә төгәл төшерергә тырыштым.

## БИШЕНЧЕ ЭКСПЕДИЦИЯ

ТӨМӘН ӨЛКӘСЕ
*(1970 елның 14–16 мае)*

### Ялутор районы

Төмәнгә килеп төштем. Төмәннең кырыйларын су баскан. «Заря» гостиницасында кундым. Партия өлкә комитетында татар кешесе эшли, шуның янына бар, дигәннәр иде. Киттем. Ул – Кәбир Хаҗи улы Фәхретдинов булып чыкты. Экспедициягә килү максатымны әйттем. Ул миңа Себер татарларының бетә баруы, без эшләгән эшнең кирәксезлеге турында 15 минутлап нотык сөйләде. Тарихка шулай керде бу абзый.

Мин артык сүз көрәштермәдем, ни дисәң дә ул – КПСС ның Төмән өлкә комитетында пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире урынбасары. Шулай да үземнең эшчәнлегем һәм Омск, Томск, Новосибирск, Кемерово өлкәләрендә яшәүче татарларның бик бай музыкаль-поэтик хәзинәгә ия булуы турында әйтеп үттем.

Ялуторовскига поезд белән килдем. Бу шәһәр урынында борынгы заманда Яулы Тора дигән татар каласы урнашкан була. XIX гасыр ахырына аның тирәсендә егермеләп татар авылы була. Хәзер дә татарлар яши торган авыллар шактый.

«Сибирь» кунакханәсендә кундым. Кечкенә генә ресторан-кафелары бар икән. Мин Казаннан дигәч, арзанга гына шундый тәмле итеп ашаттылар. Шәһәр комитетына беренче секретарь Михаил Романович Игнатов янына кердем. Бик хуплады. Икенче секретарь Александр Иванович Фоминыхны чакыртып, мине Асланага җибәрү хәстәрен күрергә кушты. Аслана авылының ике исеме бар, аны Аслана

дип тә, Кашавыл дип тә атыйлар. Шулай да татарча исеме – Кашавыл. Иртәгә иртән «Сөт-консервы комбинаты»на барырга, Асланадан килгән сөт машинасы көтеп торачак, диделәр. Өлкә комитетында татар кешесе татар бетәчәк дип утырганда, урындагы руслар миңа ике куллап ярдәм итәргә тырыштылар. Аларга рәхмәтем зур.

***Кашавыл***

Шулай эшләдем дә. Кашавылга килеп төшсәм, тездән су, пычрак. Кар яуган, эрегән. Шофёр дус миңа резин итек кидерде, авылдан киткәндә калдырырсың, диде. Аяк җылынды! Киров исемендәге колхоз белән таныштым. Яхин Мөхәммәтҗан – колхоз председателе, Мөхәммәдиев Әнвәр – авыл советы председателе, Янтимиров Искәндәр – мәктәп директоры.

Кашавыл – Тубыл елгасы буена урнашкан бик матур татар авылы. Казан ягыннан килеп төпләнгән татарлар да күп.

Мине бик яхшы кешеләргә фатирга урнаштырдылар. Шәмсия апа, кызы Фәүзия апа Шәмсетдиновалар (укытучы) мине өч көн буена бик нык кунак иттеләр. Икесе дә авылдагы талантлы кешеләрне әйтеп яздырдылар. 4–5 яшьлек кечкенә уллары бар, Илгиз исемле, минем адаш та булып чыкты.

**Шәмсетдинова Фәүзия апа** (1928 елгы, 42 яшьтә) бик моңлы җырлый.

***Карлыгач***

*Карлыгачкай кара, муены ала,*
*Очып киткәч кенә югала.*
*Кыз бала тик инде, газиз бала,*
*Үсеп җиткәч кенә югала.*

*Карлыгачкай кара, муены ала,*
*Ник моңая икән бу бала?*
*Моңаймас иде, ай, бу бала –*
*Эчкәйләре тулы ут яна.*

Көйне 1941 елга кадәр үк авылга читтән килеп куелган ниндидер спектакльдән отып алган.

Безнең өчен «Балалар уены» зур табыш булды. Аны да Фәүзия апа әйтте. Алар бу җырны 1935 елда беренче класста укыганда уйнап җырлаганнар.

*Бабай урам себерә, себерә, себерә,*
*Тузаннарын туздыра, туздыра, туздыра;*
*Көштер-ку, көштер-ку,*
*Көштер, көштер, көштер-ку!*

*Әби белән түтиләр*
*Тавыкларга җим бирә;*
*Чип-чип-чип! Чип-чип-чип!*
*Чип-чип-чип-чип-чип-чип-чип!*

*Тавыклар хәбәр бирә,*
*Әтәч тә килеп җитә;*
*Кыт-кыт-кыт! Кыт-кыт-кыт!*
*Кыт-кыт-кыт-кыт-кыт-кыт-кыт!*

Балалар фольклорының бик сирәк үрнәкләреннән берсе бу. Көй, нигездә, терция (бәләкәй һәм зур) һәм октава интервалларына корылган. Терциядә «тирбәлү», ахырда тоник терциянең (тоническая терция) яңгыравы көйгә аерым бер үзенчәлек өсти.

Уен болай башкарыла. Балалар бер рәткә басалар. «Бабай» аларның башлыклары була. Барысы да бердәм урам «себерәләр». Бу җырлауны «сарнау» диләр икән, ягъни бию көен көйләү, җырлау.

*Әттә тинә тинәя,*
*Мин сарнаем, син уйна, –*

дип тә өстәде Фәүзия апа.

Минем бәхеткә, Фәүзия апаларга Ялутор районы Тумаер авылыннан **Рәхимова Фәридә Хикмәтулла кызы** (1918 елгы)

кунакка килгән иде. Икәүләп «Сигезенче март» түгәрәк уены җырын ярыша-ярыша җырладылар.

*Сигезенче март көне –*
*Хатын-кызлар бәйрәмен*
*Тәбрик итәбез!*

*Аң-белемгә чакырыгыз,*
*Наданлыкны ташлагыз –*
*Ленин сүзләре!*

*Талның үзәге өзелгән,*
*Кошлар талга тезелгән,*
*Чут-чут сайрыйлар.*

*Аң-белемгә чакырабыз,*
*Наданлыкны ташлагыз –*
*Ленин сүзләре!*

«Ярым вакытны (кайбер вакытта) минем шундый җырлыйсым килә!» – ди Фәридә апа.

«Пошна авылы көе»н **Рәхимова Фәридә**, **Кәримова Мөхәссәнә** (1928 елгы), **Шәмсетдинова Фәүзия** апалар бер тавышка – унисонга трио башкардылар.

*Ай югары, ай югары,*
*Ай югары салкынга.*
*Агач булсам, янар идем,*
*Эчемдәге ялкынга.*

Фәридә апа җыр арасына такмак та кертеп җибәрде:

***Әпипә***

*Иске шырпы кабы,*
*Яңы шырпы кабы;*
*Сандалымның төбе төште,*
*Биер идем тагы.*

*Уха, уха,*
*Уха – балык шулпасы.*
*Көн дә бәйрәм, көн дә туй,*
*Көн дә шулай булсачы.*

Биредә «Умач көе» дигән җыр да очрады. Ул «Минзәлә» көенең себерләшкән бер варианты буларак кызыклы:

*Яшьлегем – кадерле чагым,*
*Миннән дә үтте инде;*
*Кире кайтып, гөлләр булып,*
*Чәчкә атмассың инде.*

*Бергә чакта бергәлекнең*
*Кад(е)рен белмәдем бугай.*
*Бергә чакта уйламадык*
*Аерылырбыз дип болай.*

«Авызыннан җыры чыкса, күзенән яше чыга», ди җырның бер хасияте турында Фәридә апа.

Рәхимова Фәридә апа «Испанчылар җыры»н 1936–1937 елларда ШКМда (Школа красной молодежи) укыганда Кулик авылында яшәүче Латыйпова Гайшәдән өйрәнгән. Куликта Казан ягыннан килгән кешеләр күп. 1936 елны җәй көне анда зур сайлау булган, шунда җырлаганнар.

*Еллар авыр килде испанчыларга,*
*Ком бураннары аша ничек чыгарга?*

Кушымта:

*Ташкын таулар аша,*
*Ашкын сулар аша,*
*Еллар аша ерак илләргә;*
*Чит илләрне гизеп,*
*Дошманнарны изеп (кисеп),*
*Без кайтырбыз туган илләргә.*

*Еллар авыр килмәс испанчыларга,*
*Күкрәк киереп баралар алга.*

Кушымта.

*Үтәме бу еллар, үтәме, үтә,*
*Агамы бу сулар, агамы, ага!*

Без бу язмаларны эшләгәндә, Кәримова Мөхәссәнә Мулланур кызы (1928 елгы) да тыңлап утырды. Үзе югары белемле математика укытучысы икән. «Сәйел авылында Сәйел суы, Сәйел күле турында җырлар бар. Ул җырларны Зөлкарнәева Таһирә (Кәбирә) белә», – диде.

Кашавылның йолалары, гореф-гадәтләре белән **Гарипова Самиха апа** (1912 елгы) таныштырды:

*Асланада яңгыр яумаса, корбан чалалар, «теләк теләп»: 40 тавык суялар, 40 казан асалар. Тубыл буенда әле дә чокырлар бар. Былтыр да (1969 елны. – И.К.) Кактамаклар тавык җыеп йөргәннәр. Кайсы табак он бирә, тавык, икмәк биргәннәр.*

*«Теләк теләү»дә үгезләр суеп, шуның итен урманда пешереп ашап-эчеп, дога укып ятканнар.*

*Туй вакытында кызны күчергәннәр. Арбага утыртып җырлап күчергәннәр. Үмәтәк – мүәдәк – кыз күчерә торган специальный арба.*

*Алар егыла башласалар, «Өй, әттәнә!» дип әйтәләр, «Ай, Алла!» диясе урынга. Әттәнә – курчак. Әттәнәнең битенә яба торган челтәрләре булган.*

*Самавырны куйдым, әй, кайнарга,*
*Казаннардин килгән байларга.*
*Сез туганнарымны бик сагынып,*
*Йөгереп чыгам тулган айларга.*

**Галиуллин Әхәт Мәүлекәй улы** (1894 елгы, 76 яшьтә) берничә җыр башкарды, аның репертуарында тагын бер «Туй-мәҗлес җыры» да килеп чыкты:

*Эчәем микән, эчмим микән,*
*Эчсәм исереп китмәм микән?*
*Ай, бу нужаларымнан котылып,*
*Кайчан рәхәт күрермен икән?*

*Агыйделнең аръягында*
*Яңа да гына салган бер амбар.*
*Гыйшыклык тоткан бер без түгел,*
*Гыйшык тоткан Йосыф пәйгамбәр.*

**Туй-мәҗлес җыры**

*Күпердә башта, ай, күк чәчәк,*
*Ашатасың килсә, ат йебәр.*
*Мине тәләү[1] тисәң, мине сөйсәң,*
*Яшел пичәт паскан кат йебәр.*

*Карагай пашта вай карысам[2],*
*Мәргән тә генә пулсаң, атып ал.*
*Мине тәләү тисәң, мине сөйсәң,*
*Йес илле биш сумкау сатып ал.*

*Агыйтелкәйләрнең аръягынтау*
*Яңа та гына салган гүрничә;*
*Ай, шул гүрничәләрнең эчендәү*
*Кумыс[3] гагып уйнай бер бичәй.*

**Себер җыры**

*Каз әйтә, үрдәк әйтә: Кил очаек,*
*Казанның киң кырына без төшәек;*
*Казанның киң кырлары тардыр безгә,*
*Бер Ходайның язганнары бардыр безгә.*

*Укыгызлар безнең язган сүзебезне,*
*Күргән кебек булырсыз һәр үзебезне;*

---

[1] Тәләү – теләгәнем.
[2] Карысам – кары осач, көртлек, «тетерка».
[3] Кумыс – кубыз.

*Бер күрергә мохтаҗ булдык йөзегезне,*
*Афурәхим, колак салып тыңла инде.*

Кашавылда **Хөснетдинова Сәгыйрә** үзе көйләр чыгара икән. **Кучукова Оркыя мамай** да шактый җырлар белә. **Хөснетдинова Мөслимәт мамайдан** борынгы уен җыры турында сораган идем, оныткан!

Мин: «Әби, сиңа ничә яшь?» – дим. Ул: «Әй, балам, без туганда ел бар идемени?» – ди.

**Юртаев Шәяхмәт Җәләлетдин улы** (1892 елгы, 78 яшьтә) – хирыс балыкчы. Бер генә җыр әйтеп бирсә дә, балыкны күп ашатты. Шәяхмәт абый Исәй авылының Хәмидулла атлы кешесеннән отып алган «Шылдыр-шылды» җырын яздырды.

*Шылдыр-шылды ни елтырдай,*
*Тургавайлар[1] төшкән өй мәллә?*
*Кулларында кузла, әй, бияләй[2],*
*Бик портовой[3] йөргән ир мәллә?*

*Ак елкылар белән, ай, күк елкы,*
*Тибрәнепкәй йөри тау буенда.*
*Ир-егетләр белән хайван башы*
*Ниләр күрми үзенең гомерендә.*
*Язын булганнарын шуннан беләм –*
*Өзелеп-өзелеп ага кар суы.*

**Кашавылда Ногманов Искәндәр** (1939 елгы, 39 яшьтә) белән таныштым. Җырчы, скрипкачы, үзешчән композитор. Гаҗәеп талантлы шәхес. Мәктәптә музыка һәм җыр дәресләре алып бара. Минем коллега! Мин дә бит 1966 елны КДПИның музыкаль педагогика факультетын бетердем.

Искәндәрнең абыйсы **Ногманов Садри** «Ташландык бала» дигән трагик җыр яздырды. Мин аның текстын монда

[1] Тургавай – торговый сүзеннән, сатучы.
[2] Кузла бияләй – кәҗә бәтиенең тиресеннән тегелгән бияләй.
[3] Портовой – фартовый сүзеннән, көяз.

бирмәскә булдым. Тетрәндергеч вакыйга тасвирлана. 1921 ачлык елларында Төмән өлкәсе Кырынкүл авылында Сабирова Галиядән (1926 елгы) отып алган аны Садри абый.

«Көтәм сине» һәм «Сагыну» җырларын Искәндәр абый үзе язган.

***Көтәм сине***

*Син кайтасы юлларыңда су сибәм гөлләремә,*
*Мәңге сүнмәс ут калдырдың минем күңелләремдә.*
*Кил син, гүзәлем, дөрләп яна йөрәгем,*
*Сагындырдың, алсу йөзем, кайт, зәңгәр күзем!*

***Сагыну***

*Саубуллашкан көннән башлап, бәгърем,*
*Өзелеп-өзелеп тибә йөрәгем;*
*Моңлы кара күзем, нурлы йөзем,*
*Җырым булсын сиңа бүләгем.*

Искәндәр абый, Казанга кайткач, Азат Әхмәдуллинга сәлам әйтергә кушты. Тубылда пединститутта аларны Азат абый укыткан булган икән. Азат Гыйльмулла улы Әхмәдуллин – Тел, әдәбият һәм тарих институтының гыйльми секретаре – минем нәчәлник! Азат абыйның бер шигырен дә әйтте әле Искәндәр:

*Уфаларга баргач, көй чыгардым,*
*Йөрәкләрем дөрләп янганга;*
*Туган авылым белән сөйгән ярым*
*Уфалардан ерак калганга.*

Сәламне Азат Гыйльмулловичка тапшырдым. Бик күңеле булды. Гомумән, мин Азат абый белән бик тә дустанә мөгамәләдә булдым. Җайлы кеше иде. Ул вакытта филология фәннәре кандидаты. Татар драматургиясе һәм театры тарихы буенча, Г. Камал, Г. Исхаки, Ф. Әмирхан, М. Фәйзи, К. Тинчурин һ. б. иҗатлары турында фәнни хезмәтләре бар. Ул – әдәбиятчы, тәнкыйтьче, ТАССРның атказанган фән

эшлеклесе, Казан дәүләт университеты профессоры, ТР Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы булды. Гомумән татар әдәбияты тарихында үзенең лаеклы урынын тапкан зур галим ул.

Азат абый үтә музыкаль, сәләтле кеше иде. Баянда шактый җиңел уйнады. Азат Әхмәдуллин, Равил Фәхретдинов (археолог) һәм мин – трио – Институтның әдәби-музыкаль кичәләрендә сәхнәгә чыгып, баяннарда сызгырта идек. Мине бик хөрмәт итә иде. Хәтта улына пианино сатып алганда, үзе белән алды. Бик яхшы инструмент сайладык.

Кашавылда язып алган кайбер сүзләр:

*Аш* – иген.
*Онаш* – токмач.
*Тукац* – камыр ашы, кабартма.
*Эрәтә* – калым.
*Питяулык* – тастымал, сөлге.
*Мүәтәк, мүгәтәк* – өсте ябулы арба.
*Цәгелтәк* – камыр ризыгы.
*Сыйгалык* – мәҗлес.
*Тәсторган* – ашьяулык.
*Түбәлек* – өсте ябулы абзар.
*Корманнык* – корбан.
*Төс* – кыр, басу.
*Пакцар* – сыерчык.
*Корткайак* – карчык.
*Ябак* – яссы, киң.
*Негә йөсек* – туй балдагы, туй йөзеге.
*Саравац* – тастар, хатын-кыз баш киеме.
*Тургавай* – сәүдәгәр, торговый сүзеннән.
*Асырау* – бала табу.
*Сарын* – көй.
*Сарнау* – бию көен көйләү.

## ***Рауды авылы***

Ялутор районы Рауды авылына юл тоттым. Русча Ревда дип аталган бу авылның атамасы татарча төрлечә яңгырый, аны йомшак итеп – Рәүде, шулай ук Рауды, Рауты, Рауда дип тә атыйлар. Күпчелек Рауды ди. Ул шул исемдәге елга атамасыннан алынган. Рауды Тубыл елгасыннан ерак түгел. Халкы балыкчылык, аучылык, мал асрау, урман эше белән мәшгуль. Тормышлары матур.

Беренче итеп **Халитов Әхмәтҗан Калбай улын** (1912 елгы, 58 яшьтә) яздырдым. Иң элек ул скрипкада «Әпипә», «Бибиләй» һәм «Авыл көе»н уйнады.

*Скрипкәм талый, талый,*
*Талый булса да ярый.*
*Безне кызлар яратмаса,*
*Буйдак булса да ярый, –*

ягъни кияүгә барып кайткан кыз булса да ярый, дип өстәп куйды.



Беренче көтү куу. Рауды авылы. 1970 ел

Әхмәтҗан абый туй җырларын да белә икән. Гомумән, Себернең төрле өлкәләрендә узган бу экспедицияләр туй йолалары поэзиясен бик баетты, аларны тулы бербөтен буларак күзалларга мөмкинлек бирде.

***Кыз җыры***

*Шөлдер дә генә, шылдыр, ни шаулыйдыр, –*
*Су буйкайларының камышы.*
*Сөймәгән лә ярга көчләп бирә, –*
*Юктыр әти-инәмнең акылы!*

Туй-мәҗлесләрдә Әхмәтҗан абыйның урыны түрдә булган. Яшь вакытта скрипкада уйнап йөргән. Ул башкарган икенче җыр «Сатылган кыз җыры» дип атала.

***Сатылган кыз җыры***

*Агайракай*[1] *башын утлай-утлай,*
*Куй баладин симез бар микән?*
*Күкрәккәе дәртле, күзе яшьле, –*
*Кыз баладай моңлы бар микән?*

*Әтекәем базарга барса иде,*
*Мыскал-мыскал ефәк алса иде.*
*Сөймәгән ярга биргәненче,*
*Таш бәйләп кое суга салса иде.*


Раудыда Әхмәтҗан абыйдан җырларын кат-кат магнитофонга яздырып утырганда, өйдә бик тәмле ит исе чыкты. Хуҗабикәләр Казаннан килгән кунакка кияү пилмәне пешерәләр икән. Аны бик тә вак итеп ясыйлар. Пешүгә зур гына табак белән өстәл уртасына чыгарып утырталар.

Әхмәтҗан абый да үзенең кияү булып йөргән вакытларын искә төшерде. Кияү булып кергәч, кыз ягыннан йеңкәлекләр, ягъни җиңгәләр, «кияү аш» дип алып кереп ашатканнар.

[1] Агайрак – актамыр, сарут, пырей.

Шундый ук пилмәнне Әхмәтҗан кияүнең туган-тумачалары кыз ягына да алып барганнар.

Әнием дә Татарстанның Әтнә районында бик вак итеп кияү пилмәне ясауларын, аны туйдан соң кодаларны озатыр алдыннан гына соңгы сый итеп табынга чыгаруларын сөйләгән иде.



Корманов Галим.
Рауды авылы. 1970 ел

Икенче информантым **Корманов Галим Мөхәммәтгали улының** (1895 елгы, 75 яшьтә) репертуары гаҗәеп бай, күптөрле. Ул җырлар, йола җырлары белүе өстенә, курайда искиткеч оста уйный. Курайны үзе ясый. Курайның буе 82 см, диаметры 8 мм, 4 уемы бар: аралары 55–9–9–10 см.

Галим абый башкарган «Солдат җыры» эчтәлеге белән традицион солдат җырларыннан аерылып тора. Бер яктан ул диалогка корылган, беренче куплет озатып калган, икенче һәм өченче куплетлар киткән кеше исеменнән башкарыла, икенче яктан, гаҗәеп матур бизәкләр белән кешенең хискичерешләрен ача:

***Солдат җыры***







*Түбәтәйләреңне калдырып кит,*
*Читләренә ука мин тотармын.*
*Китәсең калдырып ялгызымны,*
*Хәсрәтләнеп, ялкын-ут йотармын.*

*Озата бара дускай, үзе җылый,*
*Бирдем кулымнандин яулыгымны.*
*Хат язып тор, дускай, хат язып тор,*
*Исәнлегең белән саулыгыңны.*

*Сахраларга чыксам, ялгыз үзем,*
*Һаваларда йолдыз, ай юлдашым;*
*Һаваларда йолдыз, ай юлдашым,*
*Мең дошманга каршы ялгыз башым.*

Рауды – туй җырларына бай авыл. Төмән – Тубыл – Лайтамак тирәләрендә «Кияү типсәү» җырлары аеруча популяр. Курманов Галим абый да бу җырны белә икән. Җырның беренче вариантын без аңардан язып алдык. Галим абый аны «Кияү иңдерү» җыры дип яздырды.

**_Кияү иңдерү_**






*Һауата кыңгыл-кыңгыл*
*Каз имәсмә, каз имәсмә.*
*Ай, егетне хур-зар кылган*
*Кыз имәсмә, уай җаным – ай!*

*Йел өрсә камыш башы*
*Шәүшәрташыр[1], шәүшәрташыр.*
*Кыс-улан кәткә йетсә[2],*
*Кылгылташыр, уай җаным – ай!*

*Суга салсаң, батмас*
*Янган күмер, янган күмер.*
*Ат менеп кусаң, йетмәс*
*Үткән гүмер, уай җаным – ай!*

Галим абыйдан совет идеологиясен яктырткан җырлар да, заманча җырлар да язып алдык.

***Укыек, туганнар!***

*Укыек, туганнар! Укыр замана.*
*Янсын дәхилләр! Укыек, иптәшләр!*
*Йөрмәек уйнап, урамны буйлап,*
*Киләчәкне уйлап, укыек, иптәшләр!*

*Без яшь булсак та, укыек яшь чакта;*
*Калмаек артта, укыек, иптәшләр!*
*Укымаганнар – фәкыйрь торганнар,*
*Артка калганнар, укыек, иптәшләр!*

---

[1] Шәүшәрташыр – кыштырдашыр.
[2] Кәткә йетү – балигъ булу, буйга җитү.

«Яшь пионерлар» дигән җыр, совет власте урнашып, балаларны пионер сафларына керткән вакытны, шул заман рухын тоярга мөмкинлек бирә.

*Бүрекләреңне кисәң дә*
*Килешмәй дип салырсың;*
*Ясыл, иптәш, камсамулга,*
*Аң-белемнәр алырсың.*

*Әй, яшь пионерлар,*
*Әй, яшь ленинчылар.*

*Коммунистлар җыелышты*
*Төмәнлек өязенә;*
*Револьверлар кыстырылган*
*Билендә пуясына,*
*Пуясы, пуясы, билендә пуясына.*

*Әй, яшь пионерлар,*
*Әй, яшь ленинчылар.*

*Бес үсебес Төмәннеке,*
*Төмәнтә тумасак та.*
*Советка хезмәт итәбез*
*Камунис булмасак та.*
*Камунис, каминис, камунис булмасак та.*

*Әй, яшь пионерлар,*
*Әй, яшь ленинчылар.*

**Бакиев Гани Әптелҗаббар улы** (1912 елгы) «Ибәтулла бәете»н нән бер өзек, мәгълүм «Абау, гөлкәем»не көйләп күрсәтте. Күршесе өйрәткән.

Рауды халкының кайбер «хикмәтле» сүзләре дә истә калган:

*Бер күргән – белеш,*
*Ике күргән – таныш.*

*Кайнананың яхшысы –*
*Тәмугының чаткысы.*

*Ашны тәмле иткән – тоз,*
*Ятны үз иткән – кыз.*

*Җыр – күкрәк хәзинәсе.*

*Тошыкма,*
*Тошыкканнан соң, пошыкма!*
(Уйлап эшләргә кирәк. Юлыкма, юлыксаң, үкенмә!)

### ***Кактамак авылы***

Ялутор районының чираттагы авылы – Кактамакка 20 майда килдем (1970 ел). Аның икенче атамасы Кызыл Яр, русчасы Красный Яр. Тубыл елгасы буенда урнашкан. 1909 елда авылга Столыпин реформасы буенча Идел буеннан татар гаиләләре күчкән.

Беренче җырларны яздырган кеше **Миңлебаев Абелгаяз абый** (1921 елгы, 49 яшьтә) Кактамакка Күл авылыннан (Озерная) кунакка килгән иде. Бик теләп, «Әлмән күле» дигән җырны яздырды.

***Әлмән күле***

*Әлмәне күлләренең балыгының ла,*
*Калын микән лә кабыгы?*
*Әлмән илләрендин ич хәбәр юк,*
*Саулары микәне нә халыгый.*

*Агыйделкәйләргә төшә яздым,*
*Тотмадың беләгемдин.*
*Тамыр җәйгән лә гөлләр кебек*
*Китмәдең йөрәгемдин.*

Курган өлкәсендә Әлмән һәм Сафакүл авыллары бар. Бәлки җыр шул Әлмән турындадыр?

Әбелгаяз абый белән **Гадиева Миңлехәят апа** (1927 елгы, 43 яшьтә) икесе бергә «Кем сәхрәсендә» җырын яздырдылар.

*Кем сәхрәсендә кояш нур сибә,*
*Нәкъ шушы сәхрәдә яшь ямщик үлә.*

Мин килгәндә Кактамакта, язын су басу сәбәпле, хәлләр бик шәптән түгел иде. Чәчү дә соңлаган. Мондый су басу ун елга бер генә була икән. Төмәнне дә су баскан иде бит. Себер якларында, бигрәк тә зур елга яки күл буенда урнашкан авылларда бу хәл булып тора.

Кактамакта **Мөхетдинова Хәербану апа** (75 яшь) үзе башкарган җырны «Казакъ җыры» дип атады. Ул җыр казах халкыннан кергән.

***Казакъ җыры***

*Карадин камзул кидем, коелмаган[1],*
*Итәге машинадан җыелмаган.*
*Кыз баладин моңлы бар микән,*
*Үз илендә туфырагы боермаган?*

*Сез илнең агачы тигез биек,*
*Анда уйнам дигән бала киек.*
*Сез туганнарымны уйлап китсәм,*
*Йан түшәктә йоклый алмыйм, эчем көеп.*

*Карага мин караем мал микән дип,*
*Чытра күлдә үскән тал микән дип;*
*Ишекне бер ачам да бер ябамын,*
*Минеке йан сөйгәнем бар микән, дип.*

*Ак күлмәк тузмый диләр, киң булганга,*
*Ике асыл уйнай дигән, тиң булганга.*
*Эч серемне сиңа әйтми, кемгә әйтим,*
*Күземә күренгәнем син булгангай.*

*Күлләрдән кыллар касарылмый[2],*
*Мин киткәч, йортыгызның яме китәр*
*Таргалган[3] Сверлауной базарыдай.*

[1] Коелмаган – киселмәгән.
[2] Кыллар касарылмый – боз катмыйча (информант аңлатуы буенча).
[3] Таргалган – таралган.

**Хисамов Шәриф Афзал улы** (1911 елгы) – Буа районы Ташкичү авылыннан килгән кеше. Ул берничә борынгы җыр яздырды.

***Себер көе***

*Карлыгач кара, муены ала,*
*Карлыган җыйсам, мин калдырмам,*
*Атсыз бармакларым талдырмам.*
*Калса да калсын безнең хәтер,*
*Сез дусларның хәтерен калдырмам.*

*Карлыгач кара, муены ала,*
*Тамак асларындин кан тама.*
*Атадан бала яшьтән кала,*
*Күкрәк көче белән мал таба.*

*Утырдым көймәнең түренә,*
*Тоз күлләрен кайтып кичәргә;*
*155 сумга бер ат алдым,*
*Алгасасам*[1] *кайтып китәргә.*

*Карагай башта кара осанны*[2]*,*
*Атыр идем, итен имәсләр*[3]
*Сезнең дә лә өчен үләр идем,*
*Сезнең өчен үлгән димәсләр.*

***Борынгы көй***

*Агыйдел буе сары камыш,*
*Сызылыпкай килә бер тавыш.*
*Сырхауда ятып саргаймадым,*
*Саргайтадыр кайгы, уй-сагыш.*

[1] Алгасасам – сагынсам.
[2] Осан – көртлек.
[3] Имәсләр – ашамаслар яки өнәмәсләр.

***Борынгы җыр***

*Җилфере-җилфере йөрегәнемтә*
*Җиләләр ача, җиләләр ача, вай-хай, куенымны.*
*Ай-хай торган җир,*
*Сагындыра икәне лә йе туган ил.*

*Ялыгызы йөдәп йөрегәнемтә,*
*Җырлар ача, җырлар ача, вай-хай, күңелемне.*
*Ай-хай алмалы,*
*Бу дөньялар бесләртин калмалы.*

*Әбәү, Алла, «уф» кебек,*
*Бер хәсрәтем, бер хәсрәтем, ай-вай, юк кебек.*
*Ай-хай, абыем ла,*
*Кайдин кадерләреңне табыем ла?*

*Бер хәсрәтем булмаса да,*
*Яна йөрәгем, яна йөрәгем, вай-хай, ут кебек.*
*Ай-хай, абыем ла,*
*Кайдин кадерләреңне табыем ла?*

**Нурмөхәммәтов Әйтмөхәммәт Кәлимулла улы** (1915 елгы) берничә җыр куплетларын яздырды. Ул яздырган «Солдат җыры»нда патша гаскәрендә 25 ел хезмәт иткән солдат язмышы турында сүз бара.

*Сикреп төштем бакчага,*
*Бастым бакыр акчага.*
*25 ел тиккә хезмәт иттем,*
*Александр патшага.*

Әйтмөхәммәт абый, «Егет индерү җыры» дип, туй җырыннан да бер өзек җырлады:

*Җил өрсә, иелә камыш башы,*
*Шәүшәрташыр[1], шәүшәрташыр.*

[1] Шәүшәрташыр – кыштырдашыр.

*Ат тотып кусаң, җитмәс,*
*Үткән гумер, уай җаным-ай!*

Кактамак авылында Әйтмөхәммәт абыйларда бик тәмле бәлеш белән сыйладылар. Шушы якларда бик популяр булган кияү бәлеше белән. Аны дөге, йөзем һәм алма кушып пешерәләр икән. Бәлеш ашарга күрше-күләннәр дә керде. Бергәләп, гәпләшеп ашаган бәлеш бик тәмле булды.

**Бикчәнтәев Әхтәр** (Мөхтәр?) **Фатыйх улы** (1938 елгы). Трактор бригадасы бригадиры. «Шахта көе» белән «Уку еллары» җырларын башкарды.

### ***Калмак яки Калмаклар авылы***

1970 елның 22 маенда Ялутор районы Калмак (Калмаклар) авылына килдем. Русча Авазбакеева дип йөртелә.

**Мәүлет бабай Мөстәкыймов** (1884 елгы, 86 яшьтә) халыкның бик популяр дүртьюллыкларын җырлады.

*Алтын балдагым да бар,*
*Көмеш балдагым да бар.*
*Ни сорасаң, шуны бирәм,*
*Кайчан алдаганым бар?*

*Алма ал була микән,*
*Әче бал була микән?*
*Кычкырып җырлап җибәрәм,*
*Әллә ял була микән?*

*Ал бирим, аласыңмы,*
*Гөл бирим, аласыңмы?*
*Минем белән барасыңмы,*
*Ятларга каласыңмы?*

*Әйтеп киттем иркәмә*
*Кайтырмын дип иртәгә.*
*Әллә әйтеп килим микән*
*Бибизәйтүнәкәмә?*

*Әлеп микән, би микән,*
*Бибиәнүсә микән?*
*Бибиәнүсә җаникәй,*
*Мине сагына микән?*

*Мин ничек онытырмын*
*Синең әйткән сүзләрең?*
*Тышка чыксам, эзләп йөрим*
*Аяк баскан эзләрең.*

*Рауза гөлем чәчәктә,*
*Быелгы еллар ничава,*
*Ни булыр киләчәктә?*

Калмак авылында Мәүлет бабайдан җырлар яздырган арада, өйдәгеләр бәлеш пешереп өлгергән. Безне өстәлдә парларын чыгарып кайнар бәлеш – астыган, ягъни кура җиләге бәлеше көтә иде. Әйтүләренә караганда, бу тирә-авылларда балан бәлешен еш пешерәләр икән. Балан күп, ел әйләнәсендә җитәрлек була. Шулай ук кыр чия – нарат җиләге һәм мүк җиләгеннән дә бәйрәмнәрдә бәлешләр пешерәләр, табыннар мулдан була икән.

### *Исәт авылы*

1970 елның 24 мае. Исәт яки Өйсәт авылы (аны, русчага ияреп, Яр дип тә йөртәләр) Исәт елгасы буена урнашкан. Чкалов исемендәге совхоз, җитәкчесе – Шукуров Хәмит.

Бу авылда шактый кызыклы материаллар язып алдым. Шуларның беренчесе – «Теләү корбанлык», ягъни яңгыр теләү йоласы. Яңгырны шулай чакырып алу бу якларда әле дә бар. Бу йола башка регионнардагы кебек үк яңгыр булмаса үткәрелә. Хәзер иң кызыклысы турында: күлдә балык булмаса да, «Теләү корбанлык» үткәреп, корбан чалганнар. «Валлаһи, билләһи, балык боты ашамадым», – дигәннәр.


Кайбер урында аны «теләк үткәсү» дип атыйлар. Тубылтура авылында (Төмән өлкәсе Тубыл районы) яр башына

алып чыгып ат суйганнар. Бөтен авыл халкы шунда ашап-эчеп утырган.

Исәт авылында кемнәр белән очрашу кирәк икәнне, кемнәрдән нәрсә язып алып булганны бәйнә-бәйнә аңлаттылар: Ялуторда Исәт авылының скрипкачысы **Закиров Әхмәтсафа** (1915 елгы) яши. Сеңелесе – **Закирова Миңлебану. Вәлиева Мөриҗамал апа** «Йар-йар»ны җырлый, **Кадыйров Сәфәрмөхәммәт (Саппар)** иске җырларны белә икән. Тик өйдә булмады. Гыйбадулла турында җыр белә диделәр. **Кадыйрова Фатыйха, Шәяхмәтова Курманбикә** апалар да җырлыйлар. **Заһидуллин Зәйнулла** (1930 елгы) да җырлар белә.

Туй җырларының чираттагысын **Шәңгәрәев Әхмәт Гәрәй улы** (1903 елгы, 67 яшьтә) башкарды. Бу уникаль «Күч җыры»:

***Күч җыры***




*Думраны ла чиртә лә чиртә*
*Булдым бакшы, булдым бакшы;*
*Ай, күп халыкның арасынта*
*Булдым яхшы, ай, җаным-ай!*

*Дәрьяга салсаң, батмас*
*Янган күмер, янган күмер.*
*Ай, ятышлап кусаң, җитмәс*
*Үткән гомер, ай, җаным-ай!*

Әхмәт абыйның икенче җыры:

*Каз канатлары кат-кат була,*
*Ир канаты яхшы ат була.*
*Егетнең тапкан малы бетсә,*
*Үз туганкайлары ят була.*

*Исәткәй ярбаш киртләч-киртләч,*
*Киртләчләре бетәр, боз киткәч.*
*Карлугач китер, кар-су киткәч,*
*Без килмәбез, туганнар, бер киткәч.*

**Яхина Җомабикә Хәбибулла кызы** (1903 елгы) «Тәзкирә» җыры белән башлаган иде, аннары туй йоласы җыры «Йар-йар»ны башкарды:

*Үз атаңның тупсасы*
*Алтын булыр – йар-йар!*
*Кайнатың тупсасы*
*Тимер булыр, йар-йар!*

**Җомабикә апа** борынгы бәет дип искәртеп, «Гыйбадулла бәете»н дә әйтте:

***Гыйбадулла бәете***






*Гыйбадулла иртән торып, тәһарәт ала,*
*Тулган айны ярты күребе хәйран кала.*
*Әнекәсе хәер бирәм, улым, диде,*
*Хәер бирер көннәр түгел, әнием, диде,*
*Ике балам ятим булып кала, диде.*

*Гыйбадулла урак урып ятар иде,*
*Урагы ятып калды курасынта;*
*Шуны әйтеп, Гыйбадулла күп еглады*
*Ыстанавай периставның курасынта.*

*Атарыңда сыер ята бозау белән,*
*Кызлар чәчен үстерәләр сыйпау белән.*
*Әнекәсе карт кияүгә бирәм, дисә,*
*Күз майларын сысдыралар елау белән.*

Бу бәетнең көен Җомабикә һәм Шәңгәрәев Әхмәт абый башкаруында да язып алдым. Сүзләрен тулысынча Кашавылда Бакиев Гани абыйдан язып алган идем. Бу якларда бик киң таралган һәм яратылып башкарыла торган бәет ул. Халыкта йөргән сүзләргә караганда, Ибәтулла – Гыйбадулла нindидер зур түрәне үтергән. Аны алып киткәч, әнисе бәет чыгарган. Гани абый бәеттә Шадрин районы (Курган) Өчкен һәм Тәрсүк авылларында булган вакыйга турында сүз баруын әйтә.

Инде **Янгулова Фәүзия Сәфәргали кызы** (1910 елгы, 60 яшьтә) турында. Кечкенәдән үк якты дөньяны күрмәгән,

ятимлектә үскән. Ул җырга бик оста булып чыкты. Фәүзия апаның туган авылы турында ике бик матур җыры бар. Кайбер җырларының ахырында шаяртып болай дип өстәп тә куйгалады:

*Кулымдагы балдагымның*
*Исемнәре Асия.*
*Бу җырларны башкаручы –*
*Янгулова Фәүзия.*

Бу бит чын шагыйрә дигән сүз. Бәлкем әле бу җырларның кайберләре анықыдыр да.

***Исәткәй илебез***

*Исәткәй – безнең илебез,*
*Кендегебез, туган илебез;*
*Айкаплап-чайкаплап*
*Өйрем торган Исәт илебез.*

***Исәт көе***

*Исәткәй лә ярбаш тугай-тугай,*
*Тугаенда сайрый мең тургай;*
*Иртәсен дә сайрый, кичен сайрый,*
*Саргаеп үлсен, ди бугай.*

*Исәткәй лә ярбаш бигрәк әйбәт,*
*Ак чатырлар корып җәйләргә;*
*Кайта гына барсаң, тиш-туш кирәк,*
*Төшеп, ат кынаең бәйләргә.*

Фәүзия ападан «Йар-йар!» җырларын, бер казах җыры, «Ике күзем» дигән бәет язып алдым. Такмаклар да яздырды.

*Теге-теге тегендә*
*Теге капка төбендә;*
*Теге белән сөйләшкәнем,*
*Әле дә тамак төбендә.*

***Йар-йар!***

*Үз атаңның тупсасы*
*Агач булыр, йар-йар!*
*Кайнатаңның тупсасы*
*Тимер булыр, йар-йар!*

*Сыктама, балам, сыктама,*
*Туең булыр, йар-йар!*
*Сыер пуктан сылаган*
*Өең булыр, йар-йар!*

Фәүзия ападан язып алган «Яңгыр, яу!» такмагын барыбыз да беләбез.

*Яңгыр, яу, яу, яу,*
*Илгә котлык килмәсен;*
*Ашлыкларга баш бирсен,*
*Сыерларга сөт бирсен.*
*Яңгыр, яу, яу,*
*Илгә котлык килмәсен;*
*Халык ачтан үлмәсен,*
*Ашлыкларга баш бирсен,*
*Сыерларга сөт бирсен!*
*Яңгыр, яу, яу, яу!*

Бары тик ике тавышлы гына бу гади көйләү, һичшиксез, иң борынгы үрнәкләрнең берсе булырга тиеш.


Әле 50 нче еллар башында да бөтен татар авылларында диярлек яңгыр боткалары пешереп, кичен су сибешеп уйный торганнар иде. Шул вакытта үзебез җырлап йөргән такмак безнең дә хәтердә сакланган.

### ***Сәел авылы***

Ялутор районы Сәел авылында **Булатова Гайниҗамал апайдан** (1895 елгы, 75 яшьтә) туй йолалары вакытында башкарыла торган берничә җыр язып алдык. Шул рәвешле,

атна-айлар буе бара торган туйларның һәр эпизоды ачыклана бара:

***Йар-йар!***





*Кысыл-кысыл кураслар*
*Комта булыр, йар-йар!*
*Кыс алмаган егетләр*
*Туйта булыр, йар-йар!*

*Кара сыер мөгесен*
*Каермагыз, йар-йар!*
*Әнкәсендин баласын*
*Аермагыз, йар-йар!*

*Чылтыр-чылтыр камышка*
*Сыргам төште, йар-йар!*
*Кыс алмаган егеткә*
*Күңлем төште, йар-йар!*

*Түрт почмаклы өемтә*
*Урным калты, йар-йар!*
*Түрт колаклый касанта*
*Өлешем калты, йар-йар!*

## ***Кодаларны сыйлау җыры***




*Өстеңәй кигән күлмәгеңне лә,*
*Өстәлләргә салып кистеңме?*
*Чук-чук сайрый сабан тургае,*
*Җалан болай килми оңгае.*

*Буең ла зифа, йөзең нурлы ла,*
*Әплисуннар ашап үстеңме?*
*Чук-чук сайрый сабанда тургай,*
*Гомерләрне бирсен күп елгай.*

*Аягыңдагый итегең лә шул,*
*Мәкәрҗәдән килгән олтаны.*
*Чук-чук сайрый сабанда тургай,*
*Җалан болай килми оңгае.*


*Сез дускайларым исә булгач ук,*
*Ник җалыныйм икән ятларга?*
*Чук-чук сайрый сабан тургае,*
*Гомерне бирсен күп елгай.*

## Кодагыйларны сыйлау җыры




*Ак беләккәеңне иңләп салып,*
*Агыйделкәйләрне кичтеңме?*
*Буйларың ла зифа, йөзең нурлы,*
*Сәмсәм сукайларын эчтеңме?*

## Шәриф кодам көе



*Сәелкәй лә ярбаш бигрәк ямьле,*
*Ак чатырлар корып җәйләргә.*
*Кайда гына барсаң, дус-иш шайла[1],*
*Төшеп, аткинаңны бәйләргә.*

Узган гасырның 70 нче еллары – халык чагыштырмача иркен яши башлаган вакыт. Ул әле алда коммунизм буласына да, тагын да рәхәт тормыш көтүгә дә ышана. Бу ышаныч җырларда да чагыла.

***Коммунистлар***

*Коммунистлар тарантаска*
*Икешәр утырганнар.*
*Красныйлар белыйларны*
*Байкалга тутырганнар.*

*Котылмады бер буржуй да,*
*Омскига китсә дә;*
*Омскидан качып чыгып,*
*Япуниягә үтсә дә.*

*«Коммунизм» дип язалар*
*Кызыл флагларына;*
*Коммунистларны бирмәбез*
*Авыл кулакларына.*

*Агыйделнең аръягында*
*Коммунистлар өй сала.*
*Коммунистлар арасында*
*Утырулар весалай (күңелле).*

---

[1] Шайлау – әзерләү.

***Уфа ялан***

*Уфа ялан – бик зур ялан*
*Чәчәк ата һәр заман.*
*Ленинград – Москва,*
*Су буйлары таш кына.*

*Кызыл әләм алларында,*
*Яшьләр алга ашкына.*
*Совет өчен тырышаек,*
*Рәхәт килер бер заман.*

*Ленинград – Чиләбе,*
*Пешә кура җиләге.*
*Эшче абзый эшкә бара,*
*Кулларында көрәге.*

**Гыйззәтуллин Хисмәт Сибгатулла улының (**1899 елгы, 71 яшьтә) әти-әнисе Казаннан килгән. Хисмәт абыйдан да бер уникаль җыр язып алдык. Ул печән чапкандагы өмә җырын хәтерли икән. Әлбәттә, җырның төп сүзләре онытылган инде.

*Исәткәй ярбаш бигерәк сәйел,*
*Ак чатырлар корып ук йәйләргә;*
*Кайда лай барсаң, иш-туш сайла,*
*Төшеп, аткынаңны бәйләргә.*

*Камилә җаным, әй, Камилә,*
*Былбыллары кунадыр талына;*
*Шул Камиләне димләгәле,*
*Ни сорарсыз, җиңәйләр, йалнай?*

Тагын бер җыры – бик борынгы җыр, бабаларының бабалары җырлаган булган.

Хисмәт абый аның берничә юлын гына искә төшерде:

*Ком булмайдыр Иделнең ташлары,*
*Ни күрмәйдер егетнең башлары.*

*Атлар баралмый яңгырлар яуганга,*
*Без җырлыйбыз йөрәкләр янганга.*

## Түбән Тәүде районы

### *Киндер яки Киндерле авылы*

1970 елның 6–10 июне. Авылны Киндер авыл дип тә, Киндерле (русча Киндер) дип тә атыйлар. Хәлиуллин Шәрифулла Салават улы – авыл советы председателе. 8 еллык мәктәпнең директоры – Шәмсетдинова Мөнирә, аның улы Фәһим, килене Фәния. Бик күркәм кешеләр.

Киндерле халкы белән аралашкач, бу авылда һәр кешенең үз җыры, үз көе бар ахры, дип уйлыйсың. «Нурижамал апа көе» бар. Бу авылда Мәүлекәй атлы кеше яшәгән. Шуның көен җырлыйлар. Бу җырны **Әхтәриев Рәхимҗан Нигъмәтҗан улы** (1904 елгы, 66 яшьтә) җырлап бирде.Үземнең җыр дип тагын бер җыр җырлады («Рәхимҗан көе»).

#### *Мәүлекәй көе*

*Үтәсең, гомерем, ай, үтәсең,*
*Әкрен искән җил кебек.*
*Ике лә битем тиң саргайды,*
*Сабагындин өзгән гөл кебек.*

*Үтәсең, гомерем, ай, үтәсең,*
*Картайтып әрәм итәсең;*
*Картайту белә, ай, куймыйсың,*
*Үлтереп үк гүргә кертәсең.*

Икенче көйне шушы авылның Басыйра атлы кешесе чыгарган.

***Басыйра көе***

*Сута сусар юл күрсәтә*
*Сутагы контысларга ла.*
*Мин сагынсам, айга карыйм,*
*Син кара йолдысларга.*

*Суның да бар кондызы ла,*
*Айның да бар йолдызы ла;*
*Шуңа карап гыйбрәт алам –*
*Кояш яши ялгызы.*

*Яңа исемнәр кушалар*
*Зөһрә йолдызларына ла;*
*Күтәреш хәсерәтемне,*
*Авыр ялгызларыма.*

Татар халык җырларында Агыйдел елгасы иң еш телгә алынган елга бугай. Киндерледә дә Агыйдел турында гаҗәеп матур җыр язып алдым.

***Агыйделкәй***


*Агыйделкәй ага-ага*
*Нигә тулмаган икән лә;*
*Кошларда – кул, бездә – канат,*
*Нигә булмаган икән?*

*Ат җибәрдем кырлауга (аланлык),*
*Кырлау башы кыртауга (кечкенә чүмәлә).*
*Сатып алган нәрсәм түгел,*
*Назланмыймын җырлауга.*

«Агыйделкәй» җырын мин бик күп урыннарда яңгыраттым инде. Көе ифрат көйле!

Татар халкы җырларны гына түгел, мөнәҗәт, бәетләрне дә көйләп башкара, хәтта китапны да махсус көй белән укый. Киндерледә дә «Кәлбиҗамал бәете»н көе белән яздырдык.

## *Кәлбиҗамал бәете*




*Җыл да ике гает була,*
*Берсе – Корбан гаете;*
*Без әйтәбез, сез тыңлагыз –*
*Кәлбиҗамал бәете.*

*Төмәннәргә барган чакта,*
*Барма димәде әнкәм;*
*Барма, кызым, дигән булсаң,*
*Бармас идем, әнкәем.*

*Мине урлап алып китте*
*Талымхан пар атлары;*
*Муйныма пычак салдылар*
*Талымхан караклары.*

*Алып чиләк, бардым суга,*
*Батырып алдым, тулмады;*
*Аягым чылбырлы чакта*
*Кызганучы булмады.*

*Моңлы җырларым җырладым,*
*Чылбыр белән ятканда.*
*Күзләремидин яшьләр чыкты,*
*Мылтык белән атканда.*

*Иртә буран, кич тә буран,*
*Талымханның урамы.*
*Башымны исыраф итте*
*Талымханның бурлары.*

*Кулымдагы яулыгымны*
*Элдем мин киртәләргә.*
*Кәлбиҗамалның бәете*
*Төшәр гәҗитәләргә.*

Киндерледә халык мәкаль-әйтемнәр кушып сөйләшә. Кайберләрен без дә теркәп куйдык:

*Ашама-эчмә, тышка чыкма көннәре.*

*Тотыкма, тотыкканнан соң, потыкма.*

Мәкальләрдән соң, табышмакларга да чират җитте:

*Олы киленнең башлыгы*
*Кече киленгә ярамый;*
*Кече киленнең башлыгы*
*Олы киленгә ярамый. (Мич юшкәсе)*

*– Кәкере-бөкере кая барасың?*
*– Яшел мудери*[1] *сакларга. (Урак уру)*

*Аналары сузылган,*
*Балалары тезелгән. (Матча)*

*Өйдә түгел, тышта түгел,*
*Чыпчык оясы. (Бусага)*

*Өй әйләнә йөгердем,*
*Ачкычымны төшердем,*
*Ай күрде, кояш алды. (Чык)*

[1] Мудери – башак.

*Чатыр-чытыр арасында*
*Алтын таяк ташладым. (Киндер сугу)*

*Илләр иләмендә, шәһәр чирәмендә*
*Унике мең каз уйный. (Гармун)*

*Кара урман, төн урман,*
*Ел булдак, мышкылдак,*
*Селгелдәк, шапколдак. (Чәч, мыек, күз, борын, ирен, авыз)*

*Абышкасы кычкыра,*
*Корткаягы кашкыра (көлә). (Көбедә май атлау)*

*Караңгы өйдә аерым кычкыра. (Йозак, крючок)*

*Атасы утын өйгәнче,*
*Баласы урманга җитә. (Төтен)*

1970 елның 8 июне. «Рауды авылы кызы җыры»н **Әсәдуллин Сәйфулла Әсәдулла улы** (1900 елгы, 70 яшьтә) башкарды.

*Ырауды бүрән*[1]*, ай, эчентә*
*Үсеп тә генә килә яшь таллар.*
*Еракка җиргә китеп барам, –*
*Яшәмәсен ауыл, яшь бал(а)лар*[2].

*Кулыма алган кул мылтыгым*
*Атылып китте бер кырга.*
*Сатып лай алган нәстәм түгел,*
*Назланып, куй, тормам йырлауга.*

*Ырауды бүрән тугай-тугай,*
*Бөгелеп куй килгән тугатай.*

[1] Бүрән – пүрән – кечкенә култык (елгада яки күлләрдә); пүрән пуй – елганың элекке аккан урыны.
[2] Кыз авылны каргап китә, каргыш сүзләре.

*Үсем лә сөйгән йанкисәгем*
*Йомарланган алтын укатай.*

Кайчандыр шушы авылның бер кызын башка авылдан үзе теләмәгән егеткә кияүгә биргәннәр. Басу капкасы янында ул, туган авылын һәм яшь балаларны каргап, шушы җырны җырлаган. Янәсе, алар да аның кебек ирексез һәм бәхетсез булачаклар.

Икенче строфаның соңгы юлларын элеккечә дөрес итеп шушы авылдан **Әхтәриев Рәхимҗан абый** (1904 елгы) җырлап күрсәтте. Димәк:

*Кулыма алган кул мылтыгым*
*Атылып куй китте бер гырга.*
*Үз генә сөйгән дустыкаем*
*Сатылып куй китте Бирбурга.*

Рәхимҗан абый әйтүенчә, бу җырны Нурҗамал исемле хатын җырлый торган булган.

«Өмә җыры» бик күптәннән өмәләрдә җырланган. Тик асыл сүзләре генә күптән онытылып беткән.

*Каеннан биек карагайның,*
*Чаныкайым, өселәй үркейем.*
*Аппак каен алыста*[1] *мелгейләй*[2]*.*
*Бишвакыт намас укый алмаем,*
*Чаныкаем, өселәй үркейем,*
*Ни әйтербес Алланың каршынтай.*

Әсәдуллин Сәйфулла абый «Көзге ачы җилләрдә» җырын да искә төшерде. Авылда тагын Әсәдуллин Басыйри (1905 елгы), Рәхмәтуллина Әминә, Сәфәргали, Сәйпүш абый карчыгы (табышмаклар белә), Нәсипҗамал, Айтумбитова

[1] Алыс – ерак.
[2] Мелгейләй – күренә, җемелди.

Фатыйма, Сайдуллина Зария, укытучы Мусина Маһинур һ. б. белән аралаштым.

Берничә мәкаль дә язып алдым:

*Күзең күреп, керфегең кыймылдаганда, бар да кирәк.*

*Катын алсаң, утын ал.*

*Сүз – көмеш, җыр – алтын.*

*Җырсыз көн батмас, итсез карын туймас.*

*Ил бетсә – идрәч баш.*

## ***Балтан авылы***

Түбән Тәүде районындагы Балтан авылында керәшен татарлары яши. Татарстанның Мамадыш районы Юкәче авылыннан күчеп килүчеләр 1914 елда нигез салган булган бу авылга. Гаҗәеп матур, дус, бердәм булып яши биредә халык. Җырлы авыл да икән әле Балтан.

Себердәге йөзләгән татар авыллары кебек бу авыл да 1974 елда тулысынча юкка чыккан. Нәкъ 60 ел яшәп калган.

Бейкина Наталья апаларда фатирда тордым. Бик тә кунакчыл хуҗабикә булып чыкты.

Балтан авылында иң борынгы җыр үрнәге – хезмәтөмә җыры сакланган. **Петрова Дуня апа** (1899 елгы), **Шелопаева Мария апа** (1900 елгы), **Бадиева Мария апа** (1908 елгы), **Максимова Пелагея апа** (1901 елгы) «Тула басулары» дигән җырны бергәләп башкардылар.

### ***Тула басулары***

*Тәрәзә лә төпләрем, әй, тутый кош,*
*Тутый кошларыгызны тотыгыз.*
*Торган тикле әле лә юк торасым,*
*Минем җыруларымны отыгыз.*

*Җәйләрнең лә берләредәй вакытында*
*Печән чабулары лай – авыр эш;*
*Кышларның да берләредәй вакытында*
*Тула басулары лай – дәвер эш.*

*Өерләләр микән дәй, әй, ашыгыз,*
*Буткалар да микән дәй ашыгыз.*
*Өерләләр булса лай әй ашыгыз,*
*Тулагызны үзегез басыгыз!*

Себергә күчкән керәшеннәр үзләре белән шушы иң борынгы җырны да алып килгәннәр. Хәзерге көндә ул үзенең төп функциясен югалткан һәм туй-мәҗлес җырына әйләнеп калган. Төрле эчтәлекле поэтик сүзләр шул көйгә җырланырга мөмкин. Ләкин шул ук вакытта аның хезмәт белән бәйләнгән шигъри юллары да яшәүдән туктамаган. Димәк, көй функцияләр алмашыну чорына кергән дип әйтергә була. Кайчандыр хатын-кызлар өмәгә җыелып, шушы җырны җырлый-җырлый тула басканар.

Шул ук җырлаучылар туй җыры үрнәге булган «Кодалар җыры»н да башкардылар.

**_Кодалар җыры_**

*Табакайларда, табакайларда борчак,*
*Түкмәй генә, чәчмәй дә тотыгыз.*
*Безнең бәбекәйләребез сезнең дә кулдай,*
*Какмай гына, сукымай да тотыгыз.*

*Сандугачлар, кайларга ла сезләр барасыз,*
*Бармыйсызмы безнеке илләргәй?*
*Барсагыз ла безнең әле, ай, да илләргәй,*
*Сәлам диегез безнең лә сөйгәнгә.*

*Кара сыерларның әй каймагын,*
*Каерып ашарга дай килдек без.*
*Әнекәләренең әй бәбкәсен*
*Аерып алырга дай килдек без.*

Шелопаева Мария һәм Петрова Дуня башкаруында тагын бер борынгы «Туй җыры»н язып алдым.

***Туй җыры***

*Кара урманнарны чыккан чакта,*
*Таянырга таяклар тапмадым.*
*Алдым да лай каләм, яздым сәлам,*
*Җибәрергә кешеләр тапмадым.*

*Тәрәзә лә ачып мин карасам,*
*Беләм печәннәрнең дә кипкәнен.*
*Сез дә әйтмәсәгез, үзем беләм,*
*Кайтыр вакытларның да җиткәнен.*

Бу – Себердә яшәүче керәшен татарларының туй җыры. Аны туйда, егет өендә, килен ягыннан килгән кодалар җырлый. Җырның көе – Татарстандагы керәшеннәр җырының бер варианты.

*Кара урманнарның артларында,*
*Төлке көтүләре (лә) көттем мин.*
*Сез (дә) кодаларым килә дигәч,*
*Капкалардан чыгып (та) көттем мин.*
*Ишек алдыкаем, әй, карал(ы)ты,*
*Каралтым ла күрә лә караңгы(й).*
*Төшә кодалары килеп кергәч,*
*Кан алган йөрәккәйләрем таралды(й).*

М. Нигъмәтҗанов бу җырны Татарстанның Алабуга районы Шүрнәк авылында А. Камаева һәм М. Просвиряковадан язып алган булган икән.

Себердәге керәшеннәр ата-бабаларының борынгы җыр хәзинәсен бик кадерләп саклыйлар. Бу мисал ике төбәктә дә көйләрнең интонацион-лад төзелешләре бер үк икәнлеген ачык күрсәтә.

Җыр беренче мәртәбә 1972 елның 12 октябрендә язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында (Бауман урамы)

Себер татарларының музыкаль-поэтик иҗатын җыюга багышланган кичәдә яңгырады. Аны яшь җырчы, Татарстан радиосының тавыш операторы булып эшләүче Флүрә Сөләйманова җырлады. Соңрак ул бу көйгә Г. Зәйнашевадан яңа сүзләр яздырып, «Урманнарда йөрдем» исеме белән радиога яздырды.

Кичәдә исә бу җырны Таһир Якупов башкарырга тиеш иде. Тик ул килмәде... Ә соңрак Таһир бу җырны «Уйлану» дип атап, радиога яздырды. Тексты – без өйрәткән, экспедициядән кайткан вариант.

Шул ук җырлаучыларым «Мәҗлес җыры»н да яздырдылар:

*Җырлагыз, дус(ы)ларым, җырлагыз,*
*Авызыгызны җомымагызы ла;*
*Бергә чакта җырлап калыйк,*
*Мәңге бергә булмабыз.*

Балтан керәшеннәре бу җырны кунак-төшемдә, туй-мәҗлесләрдә бик яратып башкаралар. Аның Себер татарларында, бигрәк тә Себер керәшеннәрендә популяр булуы игътибарга лаек. Чөнки җырның көе бик таралган, ул – күп кенә вариантлы көйләрнең берсе. Бу җырның:

*Безнең газиз башларыбыз*
*Әйләнеп кайтыр микән, –*


дигән юлларын мин кечкенәдән үк хәтерлим. Аны Татарстанның Әтнә районы Олы Бәрәзә авылында яшәгән әбием Кадыйрова Шәмсекамәр (1885–1955) җырлый иде. Күренә ки, җырда сүз солдат, сугыш турында бара. Әбинең улы, минем әтием Кадыйров Шәфикъ 1941 елда сугышта хәбәрсез югалды.

## ***Бохара авылы***

1970 елның 4–5 июне. Бохара авылының русча атамасы – Байкал.

Мин Сабитова Сәрби апаларда фатирда. Улы Әүхәдулла, энесе Ишук, улы Таһир, Таһирның кызы Асия (9 нчы классны бетергән) исемле. **Сәрби апа (**1895 елгы, 75 яшьтә) берничә җыр яздырды. Арада «Йар-йар» җырын бу мәгълүм җырның тагын бер вариациясе буларак язып алдым.

### ***Йар-йар***




*Сыктама, балам, сыктама,*
*Туең булыр, йар-йар!*
*Сыер буктан сылаган*
*Өең булыр, йар-йар!*

*Ат(а)инәңнең өендә –*
*Агач бикләү, йар-йар!*
*Ят кешенең өендә –*
*Тимер бикләү, йар-йар!*

*Ике ястык, бер түшәк –*
*Аз булмасын, йар-йар!*
*Чыгып карагыз, кияү*
*Таз булмасын, йар-йар!*

**Фәйзуллина Хәдичә ападан** (1909 елгы) «Китәмен илегездин» дигән җыр яздырдым.

***Китәмен илегездин***

*Ал алъяпкыч бәйләп кенә*
*Үстердем буйларымны;*
*Ник алдарак уйламадым*
*Хәзерге уйларымны.*

*Адеал микән, юрган микән*
*Минем ябынганнарым.*
*Син балама мәгълүм микән*
*Минем сагынганнарым?*

*Китәмен илегездин,*
*Котылам сүзегездин;*
*Яшел башлы үрдәк булсам,*
*Су да эчмәм күлегездин.*

**Сабитова Бибинур апа** (1894 елгы, 76 яшьтә) «Туй-мәҗлес җырлары җырлады:

*Таянмагыз өстәлләргә,*
*Фанерлары бөгелә.*
*Сезгә хатлар язган чакта*
*Күземнән яшь түгелә.*

*Үзем җырлыйм, үзем җылыйм,*
*Үзем җыям бөрлегән.*
*Хәсрәт кулләрендә йөзәм,*
*Үзем сабырга түзәм.*

*Без утырган машинаның*
*Көпчәкләре нумерлы.*
*Я килермен, я юк инде –*
*Белеп булмый гомерне.*

*Алмагачның алмасын*
*Җыеп бетерә алмассың.*
*Әйттең бер сүз – калды хәтерем,*
*Инде таба алмассың.*

*Сандугач булсаң, белербез,*
*Кайда сайраганыңны;*
*Озакламый ишетербез*
*Саг(ы)нып саргайганыңны.*

*Байлар кия итек-читек,*
*Мин киярмен күн итек.*
*Яңадин ярлар сөярмен*
*Исең китмәле итеп!*

*Алмагачның алмасын*
*Кәрзинкәмә тутырам.*
*Чәем дә, шикәрем дә бар, –*
*Спокойно утырам.*

## АЛТЫНЧЫ ЭКСПЕДИЦИЯ

### ТӨМӘН ӨЛКӘСЕ
*(1971 елның июле)*

### Тубыл районы

#### *Лайтамак авылы*

Лайтамак авылына без Тубыл каласының Сатылган авылында урнашкан аэропортыннан очып киттек. Бу 1971 елдагы 6 июль көненең кояшлы киче иде. Килеп төштек. Авыл халкының барысы да диярлек «самолёт каршыларга» чыга. Шундый күркәм гадәт яши бирэдә. Үзенә күрә көн саен үзара очрашып-күрешеп алу мөмкинлеге дә бу. Омск өлкәсендәге су трамвае каршылау гадәте кебек.

Лайтамак – Тубыл районында саз эчендә урнашкан авылларның берсе. Бу районда сазлыкта утрау-утрау булып урнашкан татар авыллары шактый. Бу авылларга җәен самолёт очса, кышын, су каткач, боз өстеннән машина юлы салына.

Безнең киләсен беркем белми. Без икәү килдек, хатыным Миңлегөл дә минем белән. Каршылаучылар арасында авыл советы председателе Дәминов Тәүфикъ та бар икән. Ул безнең янга килеп, кем булуыбызны сорашты. Ике дә уйлап тормыйча, безне укытучы Зәкия апа Хәлилова янына алып китте.

Ә Зәкия апа безне бик тә зур кунаклар итеп каршылады. Үзе 30 ел мәктәптә балалар укыткан, хәзер пенсиядә. Ике кызы, бер улы бар. 1970 елда ире суга батып үлгән, авыл советы председателе булган икән. Зәкия апа Төмәннән педучилище бетереп килгән беренче махсус белемле укытучы исәпләнә авылда.

Безгә махсус чыбылдык кордылар, чөнки черки-кигәвен-мошкарага түзәр хәл юк.

Иң беренче җырчыбыз **Халиков Шаммөхәммәт Абдулла улы** (1901 елгы, 70 яшьтә) булды. 4 класс белемле. Телгә бик тә оста, бертуктамый сиңа сәгатьләр буе нәрсәдер сөйләргә мөмкин. Элеккеге укытучы, хәзер мулла булып йөри. Себер тарихы белән кызыксына. Ул мәкальләр кушып сөйли, җор телле.

*Как балыкның каны юк,*
*Карт кешенең ояты юк.*

*Тапканда борам-борам,*
*Бетсә алай да торам.*

Шаммөхәммәт абый мәзәкләр дә сөйләп ала, риваятьләр-легендалар да белә.

*Авыл халкы наданмы, беркатлымы булган.*

*Берәүне мөфтигә мулла булыр өчен указ алырга җибәргәннәр. Мөфти аннан: «Сездә рамазан уразасын кай вакытта тоталар?» – дип сорагач, «Мөхәррәмдә», – дип җавап биргән, имеш.*

*Лайтамак Лаймы һәм Насхы елгалары кушылган җирдә утырган. Ике яктан да яу килгәне күренеп торсын, имеш. Алар Күчемнән һәм Ермактан качканнар, сөннәтләүдән курыкканнар.*

*Ерак түгел Корландар һәм Нымындар (кеше исемнәре, дар – йорт) авыллары булган.*

*Вацыр – Вачир – Ачир янында ике авыл Рынья татарлары булган. Ермак кешеләре килеп, аларны чукындырганнар. Урыс динендә калганнар. Хәзер Ачир татарлары булып кушылганнар.*

*Кузгуркүлдә берәүнең келәтендә табына торган курчаклар булган.*

***Кулакларга каршы***

*Ник бай абзый назланасың,*
*Әллә кесәң тулыгамы?*
*Артык малыңнан язарсың,*
*Тотса кызыллар якаң.*

*Син элек тә алдый идең,*
*Хәзер алдап булмыймы?*
*Ычкына алмассың инде,*
*Тотса кызыллар якаң?*

*Син элек тә ашый идең*
*Бәлеш, сумса, каз, үрдәк.*
*Бәрәңгегә зар булырсың,*
*Тотса кызыллар якаң?*

*Син элек тә чаба идең*
*Юрга атлар җиктереп.*
*Чабатаңны туздырырсың,*
*Тотса кызыллар якаң?*

*Син элек тә сала идең*
*Тоташтан йортлар ничә?*
*Мунчада да торалмассың,*
*Тотса кызыллар якаң.*

«И-ха-ха, весала» җыры Троицкидан Мирваҗа Бабаҗанның пластинкадагы көе икән бу.

***И-ха-ха, весала***

*Йырла, дисәгез, йырлаем,*
*Берне түгел – икене;*
*Йырламас идем икене,*
*Сез дусларым сөйкемле.*

*И-ха-ха, весала,*
*Җырлап утыру весала.*
*Карурманның артларыннан*
*Учлап алдым карлыган.*

*Тагы да күбрәк җырлар идем,*
*Тамагым бик карылган.*
*У-ха-ха, у-ха-ха,*
*Тамагым бик карылган.*

*Сикереп мендем бер тайга,*
*Барып кердем бер байга.*
*Байның кызын алдап үптем*
*Бер ярым такта чәйгә.*
*О-ах-ах-ах-ах-а,*
*Бер ярым такта чәйгә.*

1912 елларда чыккан тагын бер көйне «Бузгаев көе» дип атады.

***Бузгаев көе***

*Ялан гына җирдә ялгыз каен,*
*Яфраклары аның киң түгел.*
*Әй, егетләрдән егет һич ким түгел,*
*Эшләүләре генә тиң түгел.*

*Арыслaндай егет һич алдырмас,*
*Каршысында биек тау булса;*
*Әй, маллар өчен егет һич кайгырмас,*
*Газиз башы аның сау булса.*

*Алгыр була арыслан баласы,*
*Батыр була юлбарыс баласы.*
*Әй, азлап кына сөйләп, күпне аңлар,*
*Ир-арыслан ата баласы, –*
*Син бит хәзер Совет баласы.*

1971 елның 5 июле. **Исәнярова Зинникамал** (1927 елгы, 44 яшьтә) безгә «Хан кызы» җырын җырлады. Беренчесен мин 1969 елның сентябрендә Яүштәдә (Томск өлкәсе) Низаметдинов Гомәрдән яздырган идем.

*Кан кысы, ач ишегең, мин герәем,*
*Пуең сифа тип әйтәләр, мин гүрәем!*
*Агыйтелтә гүрмәйсеңмә буй-буй гамыш?*
*Агыйтелтә гүрмәйсеңмә буй-буй гамыш!*

*Кан кысы, ач ишегең, мин герәем,*
*Чәчең осын дип әйтәләр, мин гүрәем!*
*Сатучыта гүрмәйсеңмә кара ленты?*
*Сатучыта гүрмәйсеңмә кара ленты!*

*Кан кысы, ач ишегең, мин герәем,*
*Тешең ах, вак дип әйтәләр, мин гүрәем!*
*Сатучыта күрмәйсеңмә вак-вак йенҗе?*
*Сатучыта күрмәйсеңмә вак-вак йенҗе!*

*Хан кызы.*
*Зинникамал Исәнярова башкара*

Бик зур табыш бу безнең өчен! Бигрәк тә иренә ярдәмче булып ерак сәфәргә – сазлар патшалыгы Лайтамакка барырга курыкмаган хатыным Миңлегөл өчен. Себер аңа якынрак – ул бит Урал кызы, Свердловск өлкәсе Нижнесергинский районы Вәскиннән. Менә, Ходай рәхмәте белән, исеме татар фольклористикасы битләрендә сакланып калачак. Рәхмәт аңа барысы өчен дә, урыны җәннәтнең түрендә булсын! (2008 елның 11 гыйнварында бакыйлыкка күчте.)

Зинникамал апа да «Хан кызы»н җыр дип атый. Аның әйтүенчә, туй-мәҗлесләрдә, яшьләрнең аулак өендә ул кара-каршы башкарылган күңелле, шаян җыр икән. Аны кунакларның кәефен күтәрү өчен, китәсе кызның туган өйдән аерылу хәсрәтен җиңеләйтү өчен җырлаганнар.

Ф. Урманчеев бу җырны бәетләр жанрына кертә. Без, Яүштә һәм Лайтамак нөсхәләрен күз алдында тотып, «Хан кызы» – «Туй уены җыры», дигән фикердә.

Яшь егет белән кыз бер-берсенә тапкыр сүзләр әйтеп, кара-каршы җырлый торган лирик җырлар үзбәкләрдә, таҗикларда һ. б. халыкларда киң таралган.

Татар халкында да «Башмагым», «Җизнәкәй», «Былбылым» кебек кара-каршы җырлана торган җырлар күп.

«Хан кызы» Г. Тукайның җырлар дәфтәрендә дә бар. Г. Тукай аны җырлар арасына кертә, бәетләр белән бутамый. Әлбәттә, бу – кызыклы факт. Менә шуңа күрә дә «Хан кызы»ның яңа вариантларын язып алырга кирәк. Күп



М. Кадыйрова Исәнярова Зинникамалдан (1927 елгы) җыр яздыра. Лайтамак авылы. 1971 ел

вариантларның көй һәм сүзләрен чагыштырып карагач кына, җырның төп функциясе турында катгый фикер йөртергә мөмкин булачак. Мин әлегә аны «Туй уены җыры» дип карыйм.

Бу җырның язмышы белән мәшһүр тарихчы Миркасыйм ага Госманов та кызыксынган. Үзенең «Каурый каләм эзеннән (археограф язмалары)» китабының «Эзләр дастанга илтә» дигән бүлегендә «Хан кызы»н җентекләп тикшерә.

Зинникамал апа көчле һәм киң сулышлы тавышы белән башкалардан аерылып тора. Шуңа күрә аны туй-мәҗлесләргә еш чакыралар. Элегрәк аулак өйдәге яшьләр уеннары, үзешчән сәнгать концертлары да аннан башка үтмәгән.

***Мәҗлес көе***

*Сантугаң булсам, сизәрсең*
*Кайта сайраганымны ла;*
*Озакламый ишетерсең*
*Сагынып саргайганымны.*

*Имәнтәме, талтамы ти,*
*Минтәме күңлең, яттамы,*
*Әйт төресен, алтама!*

*Уфага барышларым;*
*Алтайсың син, ташлайсың син,*
*Бар синең танышларың.*

Гади генә җыр. Ә нинди ихласлык!

***Турчай***

*Кечкенә турчай баласы,*
*Сикереп лә менмәң, биле аурыр.*
*Кыз бала сезгә, һәй кунактыр,*
*Каты сүзләр әйтмәң, яны аурыр.*

Монысы инде турыдан-туры кыз озату белән бәйләнгән.

Менә монысы – чын мәҗлес җыры. Сузып, рәхәтләнеп, бөтен табынны яңгыратып җырлый торган җыры бу Зинникамал апаның:

*Агыйтел алларына ла,*
*Таянмыйм талларына;*
*Син пәгеремне алыштырмыйм*
*Пы төньйа малларына.*

*Агыйтел пуйлайсыңмы ла,*
*Манталин уйнайсыңмы.*
*Мин сине көн тә уйлаем,*
*Син мине уйлайсыңмы?*

*Уфа тиләр, Уфа тиләр,*
*Уфаны янган, тиләр.*
*Ике егет алты кыска*
*Бертигез калган, тиләр.*

Лайтамакта көндез бөтенләй йөреп булмый, мошкара, чебен-черки котырган! Эшкә кичләрен чыгабыз, төнгә кадәр язабыз. Иң зур табышларыбызның берсе – «Кияү типсәү» җырлары. **Таҗетдинова Җәмилә мамай** (1906 елгы, 65 яшьтә) җырлады.

*Күпрәтин үтәр-үтмәс*
*Күртем сәне, әй, күртем сәне;*
*Ай, күп калык арасынта*
*Сәүтем сәне, вай чаним-ай.*

*Һауата пер йолтыс парый,*
*Ярык (яхшы) йолтыс, әй, ярык йолтыс;*
*Шул йолтыс йергәй төшсә, –*
*Пулар көнтес, вай чаним-ай.*

*Һауата кыңгыл-кыңгыл*
*Кас имәсмә, кас имәсмә?*
*Ай, егетне хур-сар кылган*
*Кас имәсмә, вай чаним-ай.*

*Кияү типсәү.*
*Җәмилә Таҗетдинова башкара*

«Кияү типсәү» җырлары – туй йоласы җыры. Лайтамак авылында да, Төмән өлкәсенең башка авылларында да кияүне кыз куенына шушы җыр белән озатканнар.

Йола түбәндәге сценарий буенча барган:

Башка авылдан килгән кияү иң элек дусларында яки туган-тумачаларында тукталган. Нүгәрләр (кияү егетләре) кияүне, ике яктан култыклап алып, шушы җырны бар көчкә кычкырып җырлап (бөтен авылга ишетелсен!), кыз өенә алып киләләр. Әгәр дә кияү кыз күңеленә хуш килгән кеше булса, ул түшәк җәеп торган, ошамаса – чыгып качкан. Бу очракта аны беркем дә көчләп бирергә батырчылык итмәгән. Шунысы кызык: кайвакыт олы яшькә җиткән картлар да, шаяртып һәм гомер иткән карчыкларын сынарга теләп, үзләрен шулай «иңдереп» йөрткәннәр. Җырны «Кияү иңдерү» дип тә атаганнар.



М. Кадыйрова Таҗетдинова Җәмилә белән. Лайтамак авылы. 1971 ел

Җырны тыңлап торган **Кучумова Һава мамай** (1894 елгы, 77 яшьтә) «Кияү типсәү»гә өстәп, болай диде:

*Йел өрсә, камыш баши*
*Шәүшәрташыр[1], шәүшәрташыр,*
*Кыс-улың буйга йетсә,*
*Кылгылташыр, вай җаним, әй,*
*Кылгылташыр, вай тус йар, әй!*

*Төягә йук бәйләтем,*
*Вай җаним, әй, вай тус яр, әй!*
*Җанымдин рухсәт суратым,*
*Ил ятканчы, вай тус яр, әй!*

Җәмилә апа тумышы белән Төмән өлкәсе Каенавылдан. Җырга-юморга искиткеч бай һәм тапкыр мамай. Сүз арасында да җырлап ала. Һәр темага җыры бар.

*Җегет кеше үткен була,*
*Ат сугара буранда;*
*Йөрәгенә чыдый алмый,*
*Җырлап йөри урамда.*

Җәмилә мамай безне махсус кунакка чакырды. Өстәл тулы пешкән ризык иде. Авылның бөтен кызык хәлләрен безгә сөйли-сөйли «Ашаң-ашаң!» дип кыстый-кыстый сыйлады. Мең рәхмәтләр аңа!

Инде Җәмилә апаның «Үләң[2] таш» җырына килик. «Йар-йар!» җырларын Лайтамакта шулай атыйлар.

*Ата-инәңнең өентәй –*
*Агаң пикләү, йар-йар!*

---

[1] Шәүшәрташыр – кыштырдашыр.
[2] Үләң – җыр.

*Яшь кешенең өентәй –*
*Тимер пикләү, йар-йар.*

*Ике түшәк, пер ястык,*
*Ас пулмасын, йар-йар!*
*Әнкәң пелән эткәңней*
*Исеңә төшер, йар-йар!*

*Кысыл-кысыл курасслар*[1]
*Комта пулыр, йар-йар!*
*Кысыл питле йеңкәйләр*
*Туйта пулыр йар-йар!*

*Үләң таш.*
*Җәмилә Таҗетдинова башкара*

Шушында ук «Үләң таш»ның **Хисаметдинова Хөсни апай** (1915 елгы, 56 яшьтә) җырлаган вариантын бирәбез.

*Кысыл-кысыл курасслары*
*Комта пулыр, йар-йар!*
*Кысыл питле йеңкәйләр*
*Туйта пулыр, йар-йар!*

*Сигес түшәк, пиш ястык,*
*Ас пулмасын, йар-йар!*
*Цыгып караң кияүне –*
*Тас*[2] *пулмасын, йар-йар!*

---

[1] Курас – этәч.
[2] Тас – таз.

*Шултыр-шултыр камышка*
*Сыргам[1] төштем, йар-йар!*
*Кыс алмаган егеткә*
*Күңлем төште, йар-йар!*

*Кара сыер мөгесен*
*Каерманыс, йар-йар!*
*Әнкәсенин паласын*
*Аерманыс, йар-йар!*

*Үләң таш.*
*Хөсни Хисаметдинова башкара*

Ике «Үләң таш»ның да махсус көйләре бар. Алар арасында, әлбәттә, интонацион яктан охшашлык зур, әмма шулай да болар – мөстәкыйль вариантлар.

Җәмилә апаның «Баламишкин» җыры да бар. Аның көе безнең якларныкына охшаган, тик ул аны сузыбрак җырлый.

*Баламишкинның буента*
*Ак балыклар уента;*
*Ак балыктай матур ярлар*
*Ята егет куйнынта.*

*Аксак-туксак йигеп чыксак,*
*Бездә дә бар туры атлар.*
*Әвәлге йөрегәнләрен*
*Ник оныткан бу картлар?*

*Алларым кайта минем,*
*Гөлләрем кайта минем?*
*Уналты яшьтә сүгән*
*Яр гынам кайта минем?*

[1] Сырга – колак алкасы.

Җәмилә мамай куплетлар арасында «Ай, эттәнә!» дип әйтеп куя. Вагай районы Супра авылында да да шулай сөйләшәләр икән.

Җәмилә мамай бер куплет мөнәҗәт тә әйтеп куя:

*Үлдең исә җуарлар,*
*Тәнеңдә кәфен салырлар;*
*Илтеп гүргә куярлар,*
*Ни дип җавап бирергә?*

Инде Таҗетдинова Җәмилә мамайның иң көчле җырына килеп җиттек. Янгутымда Мәхмүт исемле мәргән – аучы булган. Ул юлтамага[1] киткәч, үзеннән күпкә яшь хатыны җыр чыгарган.

***Мәхмүт мәргән***

*Мәхмүт ләй мәргән әй сурасагыс –*
*Юлтамага киткән, вәй, өйтә юк.*
*Кушырыпы салган, най, куш өйләрем*
*Оцып барган кошның, әй, юлынта.*

*Насхы лай елгамта киртләч-киртләч,*
*Киртләчләре китәр, вай, бос киткәч.*
*Беснең ләй ауыл сәел (матур) ауыл,*
*И ямьләри петәр, вай, мин беткәч.*

*Мәхмүт мәргән.*
*Җәмилә Таҗетдинова башкара*

Җәмилә мамай соңыннан гына, инде без магнитофоннарны җыеп чәй эчәргә утыргач кына, сузып җырлап җибәрде:

[1] Юлтамага – ауга.

**Борнагы көй**

*Утыртым көймәнең, ай, түренәйе,*
*Каратымы лайы суларның төбенәй;*
*Су төпләрендә ләй ич кара юк,*
*Аллам ясган эшләргә чара юк.*

Бер генә куплет – әмма тулы бер тормыш фәлсәфәсе. Җырның беренче юлы бик күп җырларда очрый.

Җәмилә мамайның икенче «Борнагы көе» (ягъни «Борынгы көй»):

*Турчайный*[1] *йектем тус белән, әй,*
*Йелтертем көсгей бос белән.*
*Пәйшәмби акшам аш искицем,*
*Утыртым матуры кыс пелән.*

*Мәскәүтин килгән куйанный, әй,*
*Юлларын пуран басмасын.*
*Иртин ләй калган ятим хатын –*
*Хотайым Алламы язмасын.*

*Аппак лай аппак йомырткай,*
*Ашар лау итем пешереп.*
*Алмай та куймай матурымный*
*Ал белән кулгай төшерәм.*

Җәмилә мамай әйтүенчә, кияүне кыз куенына алып килгәндә, «Кияү типсәү»не җырлап килгәннәр, гармунда, скрипкада уйнаганнар, «пубин» сукканнар. «Пубинның эцендә червоннар булган», ди ул. Себер татарларында киң таралган бәреп уйный торган музыка уен коралы *тип* дип аталган. Җәмилә мамайның «пубины» – шул тип инде ул. Чөнки җырның да исеме «Кияү типсәү» бит. Төңгер кебек тип тә

[1] Турчай, турчайный – кечкенә ат.

туйларда сугылган. «Кияү типсәү» дигән туй йоласы җырының аталышы, күрәсең, шуның белән бәйле. Фәнни экспедицияләрдә типнең формасы һәм вазифасы турында төрле фикерләр тупланды. Мәсәлән, Омск өлкәсе Ишем Тамак районы Савыргач авылында типнең шул ук бубен икәнлеген хәтерлиләр, шул ук районның Илчебага авылыннан З. Хисмәтуллина типнең формасы белән аш казанына, ягъни литаврага ошаганлыгын, һәм балаларны сөннәткә утырткач, аларга бүләкне «тип сугып» җыюларын хәтерли.

Җәмилә мамай Миңлегөлне аеруча үз итте. Ул Бәхтиева Сәрвәр, Кучумова Һава мамайларны язганда да безнең янга килеп, кызык-кызык хәлләр сөйләп, кәефне күтәреп китә иде. Җыр белән туган, яшәгән, гомер иткән... Себер сазлыкларын яктырткан нур, талантлы шәхес ул.

**Бәхтиева Сәрвәр мамай** (1900 елгы, 71 яшьтә) тавышы бик йомшак, ишетелер-ишетелмәс. Әкрен генә, ипләп кенә сөйләшә. Күңеле тулы моң. Барысы да эчендә. Чын татар әбисе. Казанча әйтсәк, «Тән тазалык – тирән байлык», – дияргә ярата ул. Ачир авылы кызы. Кияү типсәп, Лайтамакка килен булып килгән. Аның беренче «Борнагы көй» җыры туган авылындагы Мөхәммәтгали абыйның иң яраткан, әтисеннән өйрәнгән җыры булган икән. Туган авылын сагынганда, Сәрвәр мамай һәрвакыт шул җырны эченнән җырлап йөргән. Ни сәбәпледер, бу җырның «җене» миңа да кагылды. Кайда да булса Себер татарлары турында сөйләргә туры килсә, мин шушы лирик җырны җырлап күрсәтәм.

Мөхәммәтгали абый 100 яшендә булган, Сәрвәр мамайга – 70. Бер 50 яшьләр тирәсендә җырны әтисеннән өйрәнгән дип уйласак, 1971 елда без язып алганда «Борнагы көй»гә 150 ел чамасы булган.

2023 ел бара. Димәк, җырның 200 еллык тарихы бар.

Сәрвәр мамай туган авылын сагынып сөйли. Күчем хан килгәнче, бу якларда курчакларга табынганнар, чормаларда,

келәтләрдә курчаклар тотканнар. Курчакларга табыну шактый көчле булып, исламга керүдән, бигрәк тә сөннәткә утыртудан да качып, сазлар арасына күчеп утырганнар.


Шуңа да карамастан, халык ислам динен кабул иткән. Ачир үзенең укымышлы, динле-иманлы кешеләре белән тирә-якта дан казанган. Ачирда мәчет эшләгән, муллалары да үз шушы авыл кешесе булган.

Авылда гармунда, скрипкада уйнаганнар.

Җырлаганда Сәрвәр мамай: «Тагын да бер сабах әйтимме?» – дип сорап куя. Тагын бер куплет җырлыйммы, янәсе.

Әтисе Ниясмөхәммәт бик тә белемле, акыллы кеше булган.

**_Борнагы көй_**




*Алтын биреп алыр итем,*
*Алтыным юк кесәмтә.*
*Шул матурны алыр пулсам,*
*Әреманым[1] юк үлсәм тә.*

---

[1] Әреман – үкенеч.

*Парахут килә пар белән,*
*Эце тулы мал белән.*
*Ялган төньяның рәхәте –*
*Сөеп алган яр белән.*

*Карай карлугацка ышарсың,*
*Карай камсулың кигәц;*
*Теләсә кешей ни тип әйтсен,*
*Үсеңнең күңелең сөйгәц.*

Без инде Себердә төрле дастаннарның аерым назымнарыннан торган өзекләрнең салмак кына озын көйләргә көйләнүен әйткән идек. Бу өзекләр халыкта мөстәкыйль җыр булып яшиләр һәм өлкәннәр аларны туй-мәҗлесләрдә бик теләп әйтәләр. Бәхтиева Сәрвәр мамайның да үз «Таһир-Зөһрә» һәм «Сәйфелмөлек» җырлары бар.

***Таһир – Зөһрә***

*Кысыл алма аягың,*
*Сары көмештәй сөягең;*
*Гәүһәре – якут беләгең,*
*Күрәр күңлем булармай?*

*Бик сар булган күргәли,*
*Риса булган үлгәли;*
*Таһир җаның килгәнтур,*
*Гөл йөзеңни күргәли.*

***Сәйфелмөлек***

*Кашың карай күсеңнең күклегенәй,*
*Пуең сифай пилеңнең нәслегенәй.*

Җырчыга **Хисаметдинова Хөсни мамай** (1915 елгы, 56 яшьтә) булышты. Хөсни мамай Кыскыркүл авылы кызы

икән. «Сәйфелмөлек»нең бу көен шул авылда җырлаганнар. Җыр бер генә куплетлы булып чыкты. Күпме сорасак та, калганнары исләренә төшмәде. Бу очракта бер бик мөһим нәрсәне әйтеп үтим әле. Заманында мин М. Нигъмәтҗановның Мәскәүдә чыккан китабына рецензия язып, «Казан утлары»нда бастырып чыгарган идем. Мәкалә Мәхмүт агага бик тә ошады. Тик мин анда кайбер җырларның бер генә куплетлы булуына игътибар итеп, үземчә зур белгеч булып, җырчыларга сәхнәдән җырларга бу гына җитми, дип тәнкыйтьләп маташканмын. Бу – яшьлек һәм тәҗрибәсезлек билгесе. Соңрак үзем дә бер генә строфадан торган җырларны да магнитофон тасмасына яза башладым. Музыкант өчен көе кадерле, бигрәк тә яңа, уникаль көй булса.

Лайтамакның тагын бер сандугачы бар бит әле. Аны Миңлегөл тапты. Ул – **Кучумова Һава мамай** (1894 елгы, 76 яшьтә). Аннан «Сарын», «Эскәтерем», «Мәдинәкәй» җырларын магнитофонга бер утыруда яздырып алдык.

***Эскәтерем***

*Эскәтерем киң генә,*
*Өстәл белән тиң генә.*
*Минем сөйгән җанкисәгем*
*Җир йөсентә бер генә.*

*Сандугачның балалары*
*Бар да кунган тирәккә.*
*Мәхәппәтең бигерәк катый,*
*Кан төшерте йөрәккә.*

*Ике аккош оцып бара,*
*Берсе бәйле, берсе – буш.*
*Төшемтә күрсәм – күңелем хуш,*
*Уянып китсәме – куеным буш.*

*Ике аккош очып бара,*
*Агыйтелтә кышлавы.*
*Җан бирүтән ауыр игән*
*Сөйгән ярның ташлауы.*

*Эскәтерем.*
*Һава Кучумова башкара*

*Мәдинәкәй.*
*Һава Кучумова башкара*

Һава мамайның әйтүенә караганда, бу җырны авылның Әбелхәер атлы кешесе яшь вакытта күз атып йөргән Шәрибә чибәргә атап чыгарган булган икән. Хәзер җырны туй-мәҗлесләрдә бик яратып җырлыйлар.

Җырның икенче өлеше интонацион агышы белән мәгълүм «Уракчы кыз» җыры көенә бераз тартым. Бу очраклы хәл түгел, әлбәттә. Мәсәлән, «Уракчы кыз» Омск өлкәсе Ишем Тамак районы Зур Тибенде һәм Илчебага авылларында популяр җырга әверелгән. Әмма бу очракта көйнең икенче өлеше беренчесенең логик дәвамы булганга күрәме, бу охшашлык әллә ни сизелми һәм көй мөстәкыйль булып кала. Җырның өченче куплеты киң таралган. Мәсәлән, Казан татарларының К. Насыйри туплаган халык әдәбияты үрнәкләре арасында да бар:

*Һавадан оча ике кош,*
*Берсе баулы, бер буш.*
*Төшемдә күреп, күңелем хуш,*
*Уянып китсәм, куеным буш.*

Бу якларда кыска көйләрне, авыл-урам көйләрен да сарын дип йөртәләр. Һава апа да безгә бер «Сарын» бүләк итеп җибәрде.

***Сарын***

*Бара торыгач мән улытыртым*
*Алмалы түтәлләргә.*
*Мәңге риса-бәхил түгел,*
*Карасаң бүтәннәргә лә,*
*Карасаң бүтәннәргә.*

*Яңа алган машинамның*
*Бинетләре бушаган.*
*Кичә көнтес бер яр сөйтем,*
*Сандугачка охшаган ла,*
*Сандугачка охшаган.*

*Аклы ситса күлмәгемне*
*Кеймәгән пулыр итем.*
*Синең яратмасын пелсәм,*
*Сөймәгән пулыр итем.*

*Аклы ситса күлмәгемнең*
*Түшенә манит төйтертем;*
*Югарыцларны сөйтертем,*
*Түпән оцны көйтертем.*

Экспедициядән кайтуга, «Эскәтерем» һәм «Мәдинәкәй» җырларын җырчы Миңгол Галиевкә күрсәттем. Һәм Казан телевидениесе аша үзем алып барган «Халык җәүһәрләре» тапшыруында аларны бергәләп яңгыраттык. Бу язма Татарстан радиосы фондында әле дә саклана һәм әледән-әле тапшырыла. Баянда Рәгъде Халитов уйный.

### ***Каргачи авылы***

Каргачи авылының русча атамасы – Таргачи. Әмма хәзер аны белгән кеше юк. Авыл күптән юкка чыккан.

Беренче информант – **Адишев Шаһбан бабай** (1888 елгы). 83 яшьлек бу карт Иртеш ярында ялгыз гына гомер кичерә. Безнең белән бик теләп аралашты. Уен-көлкегә бик юмарт. Өендә тәртип. Безне балык белән сыйлады, әле күчтәнәчкә – юлга дип биреп тә җибәрде.

Шаһбан бабай Тәвеш мәргән турында риваять сөйләде.

*Тәвеш мәргән белән Ийәнәк мәргән Йармакка каршы булганнар. Тубылдан Йармак боларны куган. Болар килеп туктадылар Вагайга. Тәвеш мәргән Катымкуй авылыннан булган. Ийәнәкне белмәйем, ни җирнеке булгандыр ул. Болар Вагайда көттеләр. Йармак кешеләре кораблар да ясаганнар, агып-чыгып киткәннәр. Вагай җирендә кырда Тәвеш мәргәннәр көткәннәр. «Ай-һай, Йармакның тимер шайтаныннан куркам», – дигән. Йармакның тимер мылтыгы булган.*

#### ***Шаһбан бабай җыры***

*Карамык бечән – каты бечән,*
*Нигәкәйләрне куй телгән мигән.*
*Мине куй ташлап барган ирең*
*Хәтерләреңне белгән мигән?*

*Кара ла нукта, кара мыек,*
*Әлләни атларның буента.*
*Минем сөйгән җанки ярым*
*Әлләни дошман куенынта.*

### ***Кызылбаево авылы***

1971 елның 24 июле. Су трамвае авылдан 3–4 чакрым ераклыкта туктый икән. Иртеш буеннан юл белән җәяүләп

киттек. Еракта (уңда) бер авыл күренде. Бара-бара мәчет манарасы калыкты. Авылга килеп җиттек. Кызылбаево авылында[1] 52 хуҗалык, 150 ләп кеше яши. Квартира хуҗаларыбыз – бик яхшы кешеләр. Хәсәнов Сәйфетдин абый белән җәмәгате Туктабикә апа якты йөз белән каршы алдылар. Биш балалары бар – Зөлфия, Зөлхия, Начия, Илсөяр һәм Әнвәр[2]. Казан кунаклары өчен тиз генә мунча өлгерттеләр.

Беренче информантым – **Хәсәнова Кәбирә апа** (75 яшь). Безгә яздырган беренче мөнәҗәтен Кәбирә апа Сәгадәтдинов Айса бабайдан отып алган.

*Әҗәл ширбәтен бергә эчәрбез,*
*Якты дөньядан бергә китәрбез.*
*Әҗәлем җитәр, көннәрем бетәр,*
*Ясин укырга вакытым җитәр.*

*Укый алмасмын, бетәр сулышым,*
*Булмас артымдин дога кылучым.*
*Җанымны алдың атна кичендә,*
*Азагы булмас хәбәр өчен дә.*

*Теләгем – сездән дога кылуны,*
*Җәннәт эчендә бергә булуны.*

Кәбирә апа «Хан мәчете» бәетен башкарганнан соң, «Хан мәчетен руслар алганнар. Шуны сагынып, кызганып җырлана», дип мәгълүмат бирде. Борынгы туй җыры «Кияүне “Биршахий” әйтеп алып киләләр», дип, «Биршахий»ны җырлады. Кәбирә апа тагын бер җырын «Әткәм көе» дип

---

[1] Кызылбаево авылы юкка чыккан авыллардан. Татарча атамасын таба алмадык. Себер татар авылларының рус һәм татар телләрендәге атамасы туры килми. Шуңа күрә Кызылбай дип, татарчалаштырып әйтү буталчыклык китереп чыгаруы бар. *(И. З. искәрмәсе)*

[2] Ходайның рәхмәте сезнең барчагызга да! Исән-саулар, ничек тә юлларын табып, хәбәр бирерсез дип ышанып калам! И. Кадыйров.

атады. Әтисе Мәмәй исемле булган, җырларга яраткан, борынгы җырларны да күп белгән.

Кәбирә апа бик кызыксынучан, күңелле кеше. Ул җор телле. «Кама кош – камышлыкта йөри торган кош ул. Мехы бик кыйммәтле. Суда оя ясый», ди. Кеше ышанмаслык эшкә бәя биреп, «Торнасы өстә булыр, тузаны җирдә булыр», дип тә куйды.

Ул төрле вакыйгалар, йола, ырымнар турында сөйләде.

*1924–1925 елларда Төмән өлкәсе Тубыл районы Кызылбаево авылына Кулларòводан Әтеш (Әтеч) исемле күремче килеп йөргән, авырулар дәвалаган. Иң элек кешенең пульсын тотып караган, температурасы бармы-юкмы икәнлеген белгән. Температура булса, дәваламаган, «чир инде дәвәеп киткән, миннән булмый ул», дип сылтау тапкан.*

*Ә дәвалау «кагу» дип йөртелгән. Анда ирләр генә катнаша. 4–5 биюче була, калганнары кул чабып, такмак әйтеп тора. Авыруны киендереп простыняга төрәләр дә биетәләр. Яфрак[1], җөгән яки камчы белән тукмыйлар, кыйныйлар – кагалар.*

*Бер хатынны ун көн какканнар. Мунча астыннан өч сөяк тапкач, җеннәрен таптык, дип туктаганнар. Ә авыру хатын терелгән, чөнки «җене» чыккан.*

*Имеш, ирләргә җен-пәри ияләшми, хатын-кызларга гына ияләшә. «Бас, дустым, Әпипә» көенә җырлап биегәннәр.*

Икенче информантыбыз безнең фатир хуҗасы **Хәсәнов Сәйфетдин** (1928 елгы) безгә гармунда «Урам көе»н һәм «Туй-мәҗлес көе»н яздырды.

**Динмөхәммәтова Хәбибҗамал** (1910 елгы) Олы Наратбашта туып үскән, **Солтанмәтова Рабига апа** (65 яшьтә) белән «Җирәнчәккәй атым», «Карчыга»ны җырладылар.

---

[1] Яфрак – мунча себеркесе, каен себеркесе.

## Вагай районы

### *Супра авылы*

Төмән өлкәсенең сазлыкта урнашкан икенче ягына күчтек. Бу Вагай районы **Супра авылы.**

Супра авылында **Сөләйманов Имаметдин абый** (1908 елгы) яши. Мулла гаиләсендә туган. Әтисе дин әһеле булса да, тирә-якта дан тоткан скрипкачы, өстәвенә биюче дә булган.

Имаметдин абый – Себер татарларының борынгы сарыннарын скрипкада башкарган музыкант. Ул – Бөек Ватан сугышында катнашып, контузия алган, II дәрәҗә «Бөек Ватан сугышы» ордены кавалеры. Орденны ул сугыш кырында алган! Сөләйман абый – Себер татарларының беренче профессиональ шагыйре Булат Сөләймановның әтисе Вәликәнең (Вәлиулла, 1907 елгы) бертуган абыйсы.

Безнең Казан тикле Казаннан эзләп килүебезгә Имаметдин абый башта бик тә гаҗәпләнде. Соңрак: «Минем җырларым, могамнарым Казан якта ишетеләчәк, без дә кемгәдер кирәк икәнбез!» – дип куанды.

Иң элек Имаметдин абыйның «могам»нарын яздырдык.

#### *Ат могам*

Имаметдин абый сөйләвенчә, *1860 елларда Супрада һәм тирә-як авылларда ясак җыючы Кармыш бай яшәгән. Үзенең байлыгын күрсәтү өчен, ул «Сөннәт туе» (3–5–7 яшьләрдә) үткәрә торган булган. Алыстан бик күп кунаклар дәшкән. Супра урамнарында хәтта йөреп тә булмаган.*

*Кармыш бай шул заманда көрәш һәм ат чабышлары үткәргән, җиңүчеләргә кыйммәтле бүләкләр биргән. Ул болай була.*

*Чабышка атларны тезеп куялар. Скрипкачы алга чыгып баса һәм атларны биетеп, «кыздырып» тору өчен махсус*

*«Ат могам» көен уйный башлый. Скрипка туктау белән, атлар алга ыргыла.*





*Ат могам.*
*Скрипкада Имаметдин*
*Сөләйманов башкара*

Халык арасында Кармыш бай турында бәет тә йөри. Имаметдин абый безгә аны сөйләп-көйләп яздырды.

### *Шайтан могам*

*Кеше авырып китсә, аның янына музыкант чакыралар, бишме-алтымы кеше җыелып, «Шайтан могам» башкарганнар. Өйне бик эссе итеп ягалар. Авырган кешене бик җылы итеп киендерәләр. Чөнки аның эченә, имеш, шайтанчир кергән, шуны «кагып» чыгарырга кирәк. Авыруны уртага алалар. Скрипкачы уйный, җыелган кешеләр кулларын шапылдатып чабып торалар. Каты авырып яткан кеше яткан җиреннән сикереп тора да кул чаба башлый, үзенең хәле юк, авызлары күперә, төшеп, гармунга бии башлый. Авыруны дәртләндереп биетәләр. Бу таңгача барырга мөмкин. Скрипкачы ял иткәндә, тегеләр «сарын белән әйтәләр», ягъни көйләп-җырлап, дөбер-шатыр тавыш куптарып, эчтәге шайтанны чыгарырга тырышалар. Авыру биеп-биеп егыла, җырлаудан туктыйлар. Ул кеше шуннан йоклап айный, авыруы да беткән була. Кеше иртән тазарып тора. Менә шушы такмакларны «Шайтан могам» сарнап җырлаганнар. Могамның сүзләрен 1971 елгы фольклор экспедициясе вакытында Тубыл районында Байнашев Рузмөхәммәттән Хуҗиәхмәт Мәхмүтов язып ала:*

*Бас-басалла, басыгыралла,*
*Баз өстендә басыгыралла.*
*Басма түшәкләр өстендә*
*Шайтан белән кысыгыралла.*

*Озын койрык саусканның*
*Койрык очын чабыгыралла.*
*Качып киткән шайтаннарны*
*Юкә күлдән табыгыралла.*

*Йерән атым йелшералла,*
*Йелеп тауга меншералла.*
*Әлеге шайтан килшералла*
*Яулык тулы илшералла.*




* притоптывание ногой



*) Притопы ногой.

*Шайтан могам.*
*Скрипкада Имаметдин*
*Сөләйманов башкара*

***Койгылык могам***

Бу көй исә аккош кебек булган, койгылык (койгы) дип йөртелгән кошка бәйле. Себер татарларында ул Изге кош санала. Аны атырга ярамый – табу. Муллалар бары тик хәтемгә (Коръән ашы) генә атырга рөхсәт биргәннәр. «Койгылык могам» ике төрле, икесе ике характердагы көй.

1 вариант





*Койгылык могам. 1 вариант.*
*Скрипкада Имаметдин*
*Сөләйманов башкара*

## 2 вариант





*Койгылык могам. 2 вариант.*
*Скрипкада Имаметдин*
*Сөләйманов башкара*

Сөләйманов Имаметдин абый скрипкада бик күп көйләрне уйнады.

*Турецкий марш.*
*Скрипкада Имаметдин*
*Сөләйманов башкара*

*Походный марш.*
*Скрипкада Имаметдин*
*Сөләйманов башкара*

*Көй. Скрипкада*
*Имаметдин*
*Сөләйманов башкара*

*Чичек. Скрипкада Имаметдин Сөләйманов башкара*

*Помос (По мосту). Скрипкада Имаметдин Сөләйманов башкара*

*Усакайлар җыры. Имаметдин Сөләйманов скрипкада уйнап җырлый*

Сөләйман абый әлеге могамнардан башка «Абыстайлар биегән көй» (хатын-кызлар биюе), «Борынгы бию көе», «Сибирская полька «Бабочка», «Чичек» (Чижик), «Көй» (танец), «Во саду ли...», «Турецкий марш», «Походный марш» «Иске пасхуд» (Иске болын). «Авыл көе» (туй-мәҗлес көе), «Башмагым», «Карурман», «Шахта» көйләрен башкарды, һәм скрипкага кушылып, «Авыл көе», «Усакайлар», «Сахралар» җырларын җырлады.

Бу көйләрне Имаметдин абый туйларда, сөннәт туйларында һ. б. махсус чакырылган урыннарда гына уйнаган. Үзенә күрә үз заманының чичәне булган ул! Репертуарының күп өлешен чама белән 1924–1925 елларда (аңа 16–17 яшь) Вагай районы Каенлы авылыннан Аккай картның уйнаганын тыңлап истә калдырган.

Аның башкаруында тагын берничә җыр язып алдым:

**Карлыгач**

*Карлыгач оча кагыеп,*
*Койрык очкайлары айрылып.*
*Китеп лә барам мин солдатка,*
*Туган-үскән илләрдин айрылып.*

*Яз килгән кошлар көз кайтадыр,*
*Энҗе-мәрҗән кебек тезелеп.*
*Иртә ләй уйлыйм, кич уйлыймын,*
*Ач үзәккәйләрем, әй, өзелеп.*

***Исәт***

*Без илләрдән чыккан чакта*
*Ай, Исәт урамнары тар булып;*
*Китеп барам мин солдатка,*
*Ай, әткәй-әнкәй күрергә зар булып.*

***Ямщиккәй***

*Иртән лә торып, тышка чыксам,*
*Сызгырыша ла ямщиккәй балалары.*
*Сызгырымас ла иде алар,*
*Бара алмыйдыр аларның атлары.*

***Карагай***

*Карагай төпләренә мин утырдым,*
*Әй, калаеплай карлар да яуганча.*
*Камзул, әй, бавың, әй, алды юк,*
*Ай, алдысы да аларның асылы юк.*

***Кәмә***

*Утырдым кәмәнең, әй, түренә,*
*Карадым лай суларның төбенәй;*
*Су төпләрентәй һич кара юк,*
*Аллам язган эшләргә чара юк.*

### ***Зәйнәп***

*Әйләнәек, дуслар, әй, шул яктин,*
*Шул яктин ла түгел – Тайлактин*[1]*,*
*Тайлактин,*
*Аермасын Аллам Зәйнәптин!*

*Раслап та гына мине сөяр булсаң,*
*Тектерәең күлмәк атаңдин.*
*Атаңдин,*
*Теләтәең йәнеңнән атаңдин.*
*(әтисенең ризалыгын алу).*

*Чынлап та гына мине сөяр булсаң,*
*Тектерәең тунны тиендин.*
*Тиендин,*
*Суырып үбәр идем телеңдин.*

### ***Эскадрон***

*Җибәр мине, әнкәй, син калдың ич,*
*Мин китәмен Урал тауларга;*
*Инде мылтык кулда, үткен кылыч, –*
*Безгә каршы килгән яуларга.*

*Сары та гына каез, җиз берәшкә,*
*Килешә генә бусаң билләргә;*
*Кара да чәчләр агармыйча*
*Кайтармайлар туган илләргә.*

*Карлыгандин кара, ай, күзләрең,*
*Бөрлегәндин кызыл йөзләрең;*

[1] Тайлак – урам исеме.

*Шикәрдин тәмле, балдин татлы,*
*Тел тибрәтеп әйткән сүзләрең*[1].

*Эскадрон.*
*Имаметдин Сөләйманов*
*скрипкада уйнап җырлый*

### ***Сахралар***

*Сахрага, уй, чыугып җыр йырыласам,*
*Кошлары түгел, ташлар моңыланай,*
*Кошлары түгел, ташлар моңыланай.*
*Сандугай сайрый таң иртәсеннән,*
*Төн уртасы, сәхәр ләи ваукытындай.*
*Йөрүмә лә би ярсыз, йөремәи малсыз,*
*Егет булып үскән ләй вакытындай.*
*Карурманда куян ята,*
*Төлке килеп уята.*
*Рәхмәт яусын шул кызларга, –*
*Кич куйнында йоклата.*

*Ике лә турчай,*
*Ике лә турчай мин симерттем,*
*Гөл яфраклары ашатып.*
*Инде лә, җаныкай, кемне сөям,*
*Син асылкайларыма охшатып.*

*Сахралар.*
*Имаметдин Сөләйманов*
*скрипкада уйнап җырлый*

[1] Җыр патша заманында чыккан дип әйтәләр.


Бүген 2023 елның 23 августы. Күптән түгел Имаметдин бабайның оныгы мине телефоннан эзләп тапты. Ул бабасын «Имаш» дип йөртә. «Себер татарларының скрипка сарыннары» дип исемләнгән тупланманы – дискны соратып алды. Димәк, Себер татарлары мәшһүр музыкантының даны әле озак сакланачак! Амин!

### ***Күләт авылы***

Күләт авылы (русча Аллагулово) Иртеш елгасы буенда утыра. Бу авылда Себергә ислам динен алып килгән яхшылар турында риваятьләр шактый күп. Авыл янында Абделхалик шәехнең кабере, ягъни астанасы бар. Шәехнең кабере янында яшел чапан. Башына кәләпүш киеп күренүен дә сөйлиләр.

Аксурка авылының җәйге кунакханәсендә тордык.

Төмән өлкәсе Вагай районы Күләт авылында балаларны сөннәткә утырту туе үткәргәннәр. Ул вакытта да «тип сугып» җыйган акчаны музыкантларга һәм балаларга өләшкәннәр. Туйда акча җыю эшенә биючеләр дә катнашкан. Биюче берәрсенең алдына килеп биесә, тегесе акча бирергә тиеш булган. Вагай районы Үләртеш авылыннан **Ишметов Әптелхәмит бабай** (1900 елгы) типнең зур икәнлеген хәтерли. Анда бернинди дә шылтыравык җиз тәңкәләр булмаган. Сорау туа: тип литавра формасында булганмы, әллә бубенга ошаганмы? Бу мәсьәләне ачыклау өчен, безгә яңадан күрше халыкларның уен коралларына




Бигрәк матур
Күләт тәрәзләре!
*М. Кадыйрова рәсеме*

мөрәҗәгать итәргә кирәк. Формасы, хәтта атамасы белән дә типкә ошаган уен кораллары турында мәгълүматлар шактый. Үзбәк халкының дойрасын хәтерләткән «дап» уйгурларда бубен хезмәтен үти икән. Чечен-ингушларда биегәндә киң кулланылган тэп гадәттәге бубен төзелешендә. Дагстанда да тэп бар. Ул агач кысадан тора һәм аның эченә кыңгыраулар һәм металл балдакчыклар эленә. Санап кителгән мисалларда типкә охшаш уен кораллары бубенны хәтерләтә. Себер татарларында да ул күп очракта шул рәвешледер. Мәсәлән, урам буйлап «кияү типсәп» килгәндә сугылган тип, әлбәттә, бубен кебектер. Югыйсә, аш казаны кадәр зур уен коралын күтәреп җырлап бару уңайсыз булыр иде. Кайбер төбәкләрдә типнең литаврага ошаган формалы булуы да мөмкин. Аларның, бәлкем, монголларда киң таралган литавралар белән бәйләнеше булгандыр.

82 яшьлек **Халиков Хәйдәр бабай** (1889 елгы) «Йалтыр-талалтир яки Әллер йар!» җырын җырлады. Хәйдәр бабай бу җырлар турында болай дип сөйләде: *«Йалтир-талалтир яки Әллер йар!» – егетне кыз өенә озату җыры. Моны «Йалтир әйтү» диләр. Егет капкадан кергән вакытта косык (кедр чикләвеге) өләшәте. Егетне көнтес алып кереп таныштырып алатылар. Ваклар «җизнә» дип килгәч, ул аларга косык өләшәте. Кич белән «Йалтыр әйтеп, Ай, әллерләп» киләләр бичәгә. Туй пулып тораты. Егет белән кысга аерым чатыр коратылар. Кысны анда саклап утыратылар туслары, җиңгиләре.*

***«Ай, әллер»ләп кияүне кергесү***
*(«Йалтир-талалтир»)*

*Ай, әллер, ай, әллер тип,*
*Тус әллер, тус әллер...*

*Кысылары беснең пигәбес,*
*Көл (гөл) ястыкка ятып сес;*

*Әй, әллер йар, әллер тус,*
*Әллер тус, әллер йар!*

*Әй!*
*Кыслар беснең пигәбес,*
*Көл ястыкка ятып сес;*
*Ай, әллер тус, әллер*
*Кыслар беснең пигәбес, ди...*

Хәйдәр бабай, өлкән яшьтә булуына карамастан, кулына чалгы алып, көн саен печән чабарга йөри. Яшь вакытта үзен шушы җырны җырлап өйләндергәннәр. Тик... хәзер инде «йалтир-талалтир»ны бөтенләй онытып бетергән диярлек. Дусларын кыз куенына керткәндә, нүгәр егете булып та йөргән әле ул.



Билгесез скрипкачы. Вагай районы, 1971 ел. *Фольклор экспедициясе вакытында Нәгыйм Ибраһимов төшергән фоторәсем*

## ҖИДЕНЧЕ ЭКСПЕДИЦИЯ

НОВОСИБИРСК ӨЛКӘСЕ
*(1972 елның 23–28 мае)*

### Куйбышев районы

### *Шагыр авылы*

1972 елның 23 мае. Мин Новосибирск өлкәсе Куйбышев районы Шагыр авылында **Садыйкова Салиха әбидә** (1905 елгы) фатирда. Бик чиста карчык, бөтен җире ялт иткән. Миңа «Кузы Көрпәч»нең берничә куплетын әйтте. Иртән кибеткә кереп, аңа тәмле әйберләр алып чыктык.

1972 елның 23 май көнендә блокнотка туй-мәҗлес җырларының 50 гә якын куплетын теркәп куйдык.

Мин бер кичне арып-талып кайтып кергәндә, Салиха әби бавырсак белән урама пешереп куйган. Ул ачы камырдан – күпкән аштан ясала. Кич буе чәй белән шушы тәмле ризыкларны ашый-ашый «Кузы Көрпәч белән Баян-сылу» куплетларын магнитофонга яздырып утырдык.

Бригадир Абдулов Сөнгатулла чәчү чәчкән җиргә алып барды. Колхозчылар белән бергәләп аш ашадык. Кырда, җил һәм төтен белән пешкән аш бик тәмле иде. Җирләре аз, уңыш та зур түгел икән. Җирнең яхшысын бирмиләр. Чәчүлек авылдан ун чакрым чамасы ераклыкта. Мин рәхәтләнеп арбада язып утырам. Әлегә черки күренми.

Авылда трактор бригадасы бригадиры Әюпов Зиннәт, мәктәп директоры Вахитов Камил, партком секретаре Фанцев Рил белән таныштым.

Мин китәсе көнне 300 дән артык яшь малны җәйләүгә куып алып киттеләр. Җәйләү Шагырдан 50–60 чакрым

ераклыкта. Җәй буе мал караучылар шунда җәйләүдә булалар. Анда аларның өйләре бар. Бөтен авыл, яше-карты озатырга чыкты. Тамаша!

**Рәхимов Габбас Нигъмәт улы** (1893 елгы, 78 яшьтә) «Кузы Көрпәч»не сөйләде. Сөйләгәндә сүзләре бик аңлашылып бетми. Шагыр бабай турында да әйтеп алды.

Бу якларда аккошлар һәм кыйгылык кошлар турындагы риваятьләр бик популяр. Шул риваятьнең берничә вариантын язып алдым.

Беренчесен **Садыйкова Салиха** (1905 елгы) сөйләде:

*Кыйгылык – зур кош. Аккоштан да зур булыр. Алар аз була. Бер аучы кыйгылыкны атып килгән. Инә кошны атып килгән. Ата кош килеп, әйләнеп очып йөри, бер йома, ягъни атна әйләнеп йөргән. Шуннан соң шул аучының бакчасына бәрелеп үлә.*

Салиха апа сөйләгән буенча, биредә кубыз популяр булган:

*Кызлар кумыска биегәннәр. Кумысны чүркәчеккә*[1] *салып, кесәгә тыкканнар (колодка – агачтан булган). Уңган кумыс булса, кешегә бирмәгәннәр.*

Салиха апа туй йолалары белән бәйле булган хәлләрне дә яхшы хәтерли:

*Азамзас белән Шагыр арасы тарма-тарма агач булган. Арба белән йөреп булмаган. Кысны алып киткәндә, махсус иярле ат белән алып киткәннәр. Ияр өстенә чатыр кебек нәрсә корганнар. Кеше кысны күрмәсен дип.*

*Ат койрыгы кисү булган. Әгәр дә егетнең яратып йөргән кысын башка җиргә бирсәләр, килгән кодаларның атларының койрыгын кисә торган булган ул егет.*

[1] Чүркәчек – тартмачык.

Салиха апа белән аралашканда, аерым сүзләрнең мәгънәләрен дә, мәкаль-әйтемнәр, канатлы сүзләр, кызыклы гыйбарәләрне дә терки бардык:

*Йөзеңне сәзетеп утырма!* – ургытып, булатып, сасытып, чыраеңны сытып утырма.

*Пердәләк* – Рәсәйдән килгән кеше. *Аларга кыс бирмәгәннәр, солдатка китә дип.*

*Катын алсаң, утын ал.*

*Күп сайлаган – тазга таянган.*

*Как сау кешегә җырлавы авыр була,* ягъни эчмәгән кешегә, димәк.

*Башыңа әвәрә булыр,* ягъни уй төшәр.

*Кешегә илем,* ягъни ягымлы.

*Тузйак* – туздан эшләнгән бавырсак сала торган савыт.

*Бөрмәк* – чабата кебек, ат, сыер тиресеннән, кругом тишеп, җеп тагып, аякка кигәннәр.

*Мәзәлдәр* – кием элү өчен ике таяктан ясалган вешалка.

*Байның малына, ярлының башына.*

*Кабы бер – карындаш, атасы бер – авылдаш.* Ягъни аталары бер булса да, инәләре икенче булса, бик якын саналмаган бу авылда.

*Лагаб сүз* – элеккедән, наданнардан калган сүз.

*Җырның оясы сезләр якта,* ягъни Казан ягында.

*Баяузыды* – эчүдән туктады.

*Баяз* – аз, ким.

*Авар-савар истә* – аңкы-тиңке.

*Ул якта булды-булмады, бу якта булды.*

*Чала-чула сүләшү* – алай-болай.

*Бер карт кеше әйткән имеш: «Картайдым инде, яр читенә килеп бастым, тәгәрәп кенә китәсе калды».*

*Юл тигез, ат симез. (Поезд)*

*Чибәр чибәр түгел, сөйгән чибәр.*

*Кайгы яттым* – яңадан яттым.

*Анда үргедем* – бер көн тордым.

*Йылы йызымас* – черемәс.

*Колач кискәле йөри* – утын кисеп йөри.

*Ил бетсә – идрәч баш.* Берни белмәгән надан кеше турында идрәч диләр.

*Самак, самаклау* – такмак, такмаклау.

*Кумыс сугу* – кубыз уйнау.

*Йыраучы* – җырчы.

*Сарын* – җыр.

*Айакуйынчы* – гармунчы.

*Айагуйын* – бию.

*Негә* – никах.

*Йалтау* – яллау, мәсәлән, музыкантларны яллау.

*Айак бирешү* – сыйлау.

*Ишек пасу* – ишек бавы тоту.

*Күц күцерү* – килен төшерү.

*Сарнау* – үзе җырлап бию.

*Өйәр кыцкыру* – кыз киткәндә капка төбендә «өяр-өяр» дип кычкыру.

*Тупса йырту* – килен кияү йорты бусагасына җиткәч, ике кызның ситсыны икегә аерып ертып җибәрүе.

*Йылгы* – ат.

*Чанук* – чана.

*Мөйөш* – өй почмагы.

Шагыр авылында төп табышыбыз – әлбәттә, туй җырлары. Аларны да Салиха ападан язып алдык.

***Йар-йар!***

*Килер-китәр юлыңа*
*Киндер чәчтем, йар-йар!*
*Киндер пешкәнче,*
*Килеп китең, йар-йар!*

*Үнә күсе сынганта*
*Улыктырган әнекәм;*
*Үнә сынлы мин киттем,*
*Инте тынгыл, әнекәм.*

*Чыбычык[1] буйлы яшь егет*
*Елып инәр[2], йар-йар!*

***Кызның җиңгәсе кияүгә җырлаган җыр***

*Ат җиксәң, бик тартма,*
*Дилбегәсен бик какма;*
*Ят баласын алдым дип,*
*Яфрак кебек саргайтма.*

*Башыңдагы түбәтәең,*
*Тәңкәләрдән түгәрәк;*
*Кашың-күзең, ай, мубәрәк,*
*Йөзең айдин түгәрәк.*

Соңгы кичтә Салиха апа яшь вакытта туй-мәҗлесләрдә җырланган 50 куплет җыр җырлады. Чәйләр эчтек, тәмле-

[1] Чыбычык – чыпчык.
[2] Йылып инәр – сиздермичә, иплэп керер.

тәмле мич ашлары белән сыйландык. Урының оҗмахта булсын, Салиха апа! Ярый әле бу дөньяда синең кебек ак апалар, ак әбиләр бар.

Икенче информантым **Әюпов Нургали абыйдан** (1909 елгы) «Кара да гына елан», «Тәфтиләү», «Җирәнчәккәй атым», «Явасы ла яңгыр» (йавасилә), «Иртә генә томан», «Әйтүкә», «Укый торган китабым», «Чит илләрдә йөргәндә», Әсмабибекәй» җырларын язып алдым.

***Җирәнчәккәй атым***

*Җирәнчәккәй атым, әй, билләрен*
*Чаналарга, чаналарга йеккәч дәй белерсең.*
*Бу дөньяларның, әй, рәхәтен*
*Кыс куйнына, кыс куйнына кергәч тә белерсең.*

***Ай яктылары***

*Ай яктылары бигрәк якты,*
*Бибием, сылуым, җанашым,*
*Ултырып ла мирҗәнләй тезәргәй.*

*Анатин сифа сес тугансис,*
*Бибием, сылуым, җанашым,*
*Әч үзәккәйләремней эсәргәй.*

*Карурманлардай очып йөри,*
*Бибием, ...*
*Карабакчай кошыларының баласы.*

*Телдин ләй үбәр, билдин кызар,*
*Бибием,...*
*Бикәйләрнең дә баласий.*

*Карурманлардай очып йөри*
*Бибием,...*
*Ала гынай билле үк саескан.*

*Бу дөньяларда барлар микән,*
*Бибием,...*
*Сөйгән матур ярына кавышкан.*

**Афзалов Мөхәммәтрәхим бабай** (1891 елгы) да койгылык кош турында сөйләде. **Мөхәммәдиева Тәйфә Шәймәрдән кызы** (1911 елгы) бераз җырлар белә.

**Асанов Иван Михайловичның** (1901 елгы) әтиләре Уфа губернасы Бәләбәй өязе Зәй районы Кабан авылыннан. Бирегә 1909 елда килгәннәр. Ул башкарган «Сарылы яулык – сандугачым» дигән җыр искиткеч!

«Кузы Көрпәч белән Баян-сылу» – Шагыр авылында тагын бер зур табышыбыз. Әлеге данлыклы дастан вариантын язып алу – музыкант өчен зур дәрәҗә. Филологларда бу дастанның дистәләрчә вариантлары тупланды. Безнең язмалар исә дастанның башкарылу үзенчәлеген ачыкларга ярдәм итә.

«Кузы Көрпәч белән Баян-сылу» дастанын Шагырда **Рәхимов Габбас Нигъмәт улы** (1893 елгы, 78 яшьтә) сөйләде.

Тагын бер информантыбыз **Әюпов Каюм абый Сәфәр улы** (1890 елгы, 82 яшьтә) койгылык турында гаять кызыклы һәм әһәмиятле мәгълүмат бирде:

*Койгылык – ул аккош, кошлар патшасы була. Аткач, аларның икесен дә, пары белән атарга кирәк. Берәүләр берсен генә аткан. Шуннан болар семьялары белән кырылып беткән.*

1967 елда Бараба якларына экспедициягә барган Рашат Гайнанов белән Һәнүз Мәхмүтовка Шагыр авылында балык

бәлеше пешергәннәр. Монда балыкны тоткан көе чистартмыйча гына камыр эченә салалар икән. Янәсе, балык үз шулпасында пешсен. Хуш исләре аңкып торган бәлешне ачып җибәргәннәр. Һәнүз абый тоташ балыкны күреп, урамга чыгып киткән, дип сөйләделәр Институтта.

Әюпов Нургали абыйларда көне буе җыр яздырып утырганнан соң, өстәлгә традицион балык бәлеше менеп утырды. Һәнүзне искә төшердек төшерүен. Мин рәхәтләнеп сыйландым балык бәлеше белән. Беренчедән, балыкны, тоткан көе салмыйлар, аның тәңкәләрен чистарталар, эчен алалар. Эчендә уылдыгы булса, ул кала. Тоз-борыч сибеп, суган турап пешерелгән балык бәлеше ашап туйгысыз тәмле була.

## СИГЕЗЕНЧЕ ЭКСПЕДИЦИЯ

ТӨМӘН ӨЛКӘСЕ
*(1973 елның 15–19 июле)*

### Тубыл районы

### *Алга авылы*

**1973 елның 15 июле.** Алга (икенче исеме Уба) авылында Казан ягыннан күчеп килгән татарлар яши. 1912 елда Түбән Каминкәдән (хәзерге вакытта Чирмешән районына карый), Столыпин реформасы буенча, 32 йорт чыгып киткән. Алар өч авылга таралганнар. Себергә «үз худлары» белән барып җиткәннәр. Андый күченүчеләрне Себердә самоходлар дип тә атыйлар. Алар Бехтерев елгасы буенда, куе урманнар эчендә Алга авылына нигез салганнар, авыл башта Уба дип аталган. Су алмый торган югары җирне Уба диләр. Соңрак аларга башка төбәкләрдән күчеп килгән татарлар да кушылган.

Алга авылында **Зарипов Мәүлет абый** (1906 елгы) курайда ике көй уйнап күрсәтте. Аның магнитофон тасмаларындагы язмаларын да үземә күчереп алдым. Мәүлет абый сугышта тугыз яра алган, сукырайган, әмма хәзер бераз күрә. Яздырып бетергәч, бик озак сөйләшеп-гәпләшеп алдык. Үзе сугышта үлеп калган Хәмит җизнәсенә багышлап шигырьләр дә чыгарган. Мәүлет абый пьеса да язган. 1931 елларда авыл советы председателе, избач булган.

Бу авылда «Канчәберләр көе» дигән көй бар. Ул Коренной Чалдун авылы икән. Бу авылда Салих бабай бер урысны, көрәшеп, җиргә егып салган. Кем-кемне ега – җир шуңа булган.

### *Теләк*

*Убада теләк теләү булган. Ул көнне ашлар пешергәннәр. Ашамлык алып барганнар. Куйлар суеп, теләк теләп, аш пешергәннәр, чәй эчкәннәр.*

*Кайвакыт аш та эчми каласың, яңгыр явып китәте.*
*Су сибә торган идек.*
*Яңгыр яу, яу,*
*Майлы ботка бирермен, дип.*

### *Аураг*

*Кешенең тәне һәм җаны аерым була. Кайбер кешеләрнең җаны гәүдәсеннән чыгып йөри. Шуны аураг диләр. Аураг – ул өрәк, үлә торган кешенең җаны чыгып йөри. Аураг, нәкъ кешенең үзе төсле булып, ул йөргән җирдә йөри, ул кеше кергән кешеләргә керә. Кешенең үтәлми кала торган эшләрен булдырып йөри икән. Иртүк кояш чыкканчы яки төнне үзенең аурагын күрсә, кеше үлә икән.*

### *Тарак сыздыру*

*«Тарак сыздыру» – кубызга кушылып, тарак белән көйләр чыгарып уйныйлар һәм биетәләр.*

**Фәрхетдинова Хәйри Җиһан кызы** (1903 елгы) «Мөнәҗәт» әйтте. Ул «Нужа күргән картлар җыры»н да белә икән; **Фәрхетдинов Миңнехарис** (1889 елгы) «Уел», «Картлар көе», «Мөнәҗәт» башкарды.

**Үтәшева Камилә** (1882 елгы, 91 яшьтә; Камилә әби яшен яшерә, чынлыкта ул 1875 елгы, аңа хәзер 98 яшь, диләр). Ул без яшь чакта чыккан көйләр, дип, бер «Борынгы көй»не көйләп күрсәтте:

*Озын көннәр, кыска төннәр,*
*Кычкыра кәккүк балалары.*

### *Арткавыл (Ирек) авылы*

1973 елның 17 июле. Авылның рәсми булмаган исеме – Ирек. Биредә Идел-Казан ягыннан килеп утырган кешеләр яши.

**Тусмөхәммәтова Шәмсия апа** (1901 елгы) Тубыл районы Торба авылында туган. Аңардан «Әҗәл мөнәҗәте»н, «Борынгы җыр»ны яздырдым.

**Суичбакова Зөләйха** (49 яшьтә) Татарстанның Кукмара районы Өркеш авылыннан күчеп килгән. «Ак каен» җырын җырлады.

*Быел үскән бодаемны*
*Урмый калырмын микән?*
*Читтә йөреп, бәхетемне*
*Күрми калырмын микән?*

Арткавылда (Ирек) яшәүче **Рәхимҗанов Әюп абый** (1905 елгы, 68 яшьтә) кияү типсәгәндә әйтеп йөргән җырның бер вариантын башкарды:

*Очып килгән ләкләгем бар,*
*Һавалап очар әле;*
*Шул бер егет буйга йетсә,*
*Йылмылтап усар, әй!*
*Шул бер егет буйга йеткәч,*
*Йылмылдап усар, әй, йанымай.*

Әюп абый Бөек Ватан сугышында Муса Җәлил белән очрашкан. Ул бу турыда болай дип сөйли:

*1942 елда Калининский фронтта Муса Җәлил белән хезмәт иттем. Командир отделения иде. 1942 ел апрель-май числоларында, кар эреп бетмәгән иде, пленга алдылар. Мин иптәшләрем белән качтым.*

**Мостафина Рәкия** (1914 елгы) – «Авыл көе»; **Азизова Халисә** (66 яшьтә), ул Яркәү районы Кызыл Яр авылыннан, – «Пүтәнәкәй[1]»; **Мостафина Хәерниса** (65 яшьтә) үзе чыгарган көй, «Зөләйха»; **Мөхәммәтьяров Әйтмөхәммәт** (Әйтүк) (1914 елгы) «Уел», «Тархан көе», «Урам көе» көйләрен башкарды.

**Мостафина Сания Бакый кызы** (1932 елгы) «Көчләп бирелгән кыз җыры»н яздырды. Сания апа – Яркәү районы Кызыл Яр авылы кызы. Бу җырны Кызыл Ярда җырлаганнар.

*«Бу авылда тип булган. Иләк формалы, шыңгырдаклары белән. Туйларда тип кагалар. Сөннәт туйларында кагалар»,* – диде Сания апа.

*Әтекәемнең ай капкасы,*
*Ярап типтем, ай, тактасыны.*
*Саклатың, әткәй, вай, саклатың,*
*Пирәсеңе нәү йерен тапматың.*

*Әткәм базарга барс(а)йде,*
*Мыскаллап куй ефәк алс(а)йде.*
*Сөймәгән ярга биргәненчә,*
*Таш бәйләп куй суга салс(а)йде.*

### ***Ахманай авылы***

1973 елның 19 июлендә бу авылга иртән машина белән килдем. Юл бик начар. Тубылның икенче ягына катер белән чыктым.

**Мөхәммәтшина Галимә ападан** (1906 елгы) түбәндәге үрнәкләрне язып алдым:

«Кияү типсәү»;

«Сәйфелмөлек» (пәри кызына гашыйк булган);

Үзе чыгарган бәет («Борнагы, кыз чагында үзем җырлаган көем»);

---

[1] Пүтәнәкәй – бытбылдык.

«Карчыга» («Абау, гөлкәем»);

«Мәдрәсәдә абыстай өйрәткән көем»;

«Суга баткан Гайшә бәете»;

«Авыл көенә» (бу бәет китапта булган);

Мөнәҗәт («Сак-Сок» көенә);

«Сикер әйтү» (китапны көйләп әйтү, сәхәр вакытында, авыз ачканда әйтәләр);

«Тәскирә» (динне мактап җырлау).

### *Тубылтура авылы*

1973 елның 10 июле. Тубылтура авылында читтән килгәннәр аз. Астанада әүлияләр күмелгән. «Ай, астанай!» – дигәннәр, «Ай, әттәнә!» урынына.

Тубылтура җырга-моңга бай авыл булып чыкты.

**Мостафин Кәрим Габделбасыйр улы** (1902 елгы) бик күп җырлар белә. Аның репертуарында «Кәшәмир чаршау», «Ямщиккәй», «Әрбинадан» (Хан мәчете; «Тәфтиләү» көенә), «Сак-Сок», «Мөнәҗәт» (Сак-Сок көенә) җырларын үзе генә «Мәрхәбә» (көйләү), «Әлбитә» (шул ук көй), «Агыйделнең аръягында» җырларын Мөнирә Мостафина белән бергә җырлады.

Кәрим абыйдан «Кияү типсәү» җырларын язып алдым.

### *Кияү типсәү*

*Йел өрсә, камыш башы*
*Шәүшарташыр, шәүшарташыр.*
*Кыс улан кәткә йетсә*
*Кызгылташыр, уай җанимай.*

*Һавата бер йолтыс бар, –*
*Нәкип йолтыс, нәкип йолтыс;*
*Шул йолтыс йергә төшсә,*
*Булыр көнтес, уай җанима.*

*Суга салсаң, батмас*
*Йанган күмер, йанган күмер.*
*Ат менеп кусаң йетмәс*
*Үткән гумер, уай җанима.*

Хөсния әби (67 яшьтә), Күкрәндедә кияүдә булган. Ул «Теләк үткәсү» – «Яңгыр теләү» турында сөйләде.

*Йарбашка апчыгып ат суйганнар. Бөтен авыл ашап-эчеп шунда утырган.*

Биредә түбәндәге сүзләр еш очрый:

*Көн күкрәй* – яшен яшьни.
*Ык йак* – Тубылдан төньяккарак.
*Мунчаны бикләгәннәр* – томалаганнар, димәк.
*Кәккүк ашлык башы өлгергәнче генә кычкыра, имеш.*
*Тора* – шәһәр, Тубыл каласы.
*Калап* – ит турый торган такта.
*Борнагы көн* – өченче көн, элекке көн.
*Аргалык* – матча.



Күкрәнде авылы күренеше. 1970 ел

*Комган* – чәйнек.
*Набулат* – сәндерә.
*Өннә* – әби, корткайак.
*Карт өннә* – әбинең әбисе.
*Олыата* – бабай.
*Түмән* – түбән.
*Ату* – читек.
*Чурагай* – чуртан.
*Әүлия* – алдан белүче.
*Чыганак бармак* – чәнчә бармак.
*Әүле* – кабер өстенә куела торган агачтан киртләп эшләнгән корылма.

**Абдуллин Равил абый да** (1937 елгы) Яңгыр теләү йоласы турында сөйләде:

*Ярбашта яңгыр теләү булган, «Шөкрана» дип аталган. Куй суйганнар, ашлар пешереп, казаннар утысып кылганнар (эшләгәннәр).*

Ул гармунда һәм «хромка»да уйный. «Русская плясовая», «Камаринская», «Авыл көе», «Камали бай көе», «Ссылкага куылганнар җыры» («Авыл көе»нә). «Шахтёр көе» (Себернеке) уйнады.

Информантларым **Назырова Айнелгаян** (1911 елгы), **Назыров Хәмидулла** (1911 елгы), **Юмашева Мәгърифә** (1900 елгы) җырладылар да, скрипкада да уйнадылар.

*Астана көтү*

*Авылда ике карчык бар, алар астана көтәләр. Ягъни Себергә ислам дине алып килгән изгеләрнең каберләрен – астаналарны саклап, карап, хәсиятләп торалар. Хәерне аларга бирәләр, алар – муллага. Кеше аларны өйгә чакырып та укыта.*

## ТУГЫЗЫНЧЫ ЭКСПЕДИЦИЯ

### ТӨМӘН ӨЛКӘСЕ
*(1974 ел)*

### Вагай районы

1974 елда Төмән өлкәсенең Вагай районына икенче тапкыр экспедициягә килдем. Бу Себердә узган соңгы экспедициям иде.

Беренче авыл – Бийек (Веселинская), икенче авыл – Картавыл (Одинарская), өченчесе – Аусак. Аусак атамасы усак агачыннан алынган.

Бу авылларда яхшылар турында күп ишетергә туры килә.

*Яхшылар*

*Борын заманнарда Бохара яктан бу тарафка 366 шәех килгән. Алар мондагы халыкны дингә өндәгәннәр. Шулай да халык үз ата-бабаларының йолаларын ташлап, яңа дингә күчәргә атлыгып тормаган. Биредә курчакка, утка табынганнар. Иштәкләр кебек булган. Соңрак шәехләргә бергә йөрмәгез, аерым-аерым йөрегез, халык арасында яшәгез, шулай итсәгез, халык дингә тизрәк килер, дип киңәш биргәннәр.*

*Болар шулай эшләгәннәр. Биредәге халык, аларның ялгыз булуыннан файдаланып, аларны берәм-берәм үтерә башлаган. Кайсын суга батырган, кайсын ничек инде. Күләт авылына күмелгән Абдулхаликъ яхшының да гәүдәсе юк икән. Бары бер кулы – баш бармагы белән учы гына бар икән.*

*Соңрак бу шәехләрне табып күмгәннәр. Ислам кергәннән соң. Аларны яхшылар дип атый башлаганнар.*

*Вагай районында Күләт авылында – Абдулхаликъ, Баишта – шәехләрнең башлыклары – Хәким ата, Көмешледә – Кәбәшали, Савыргачта ике хатын-кыз – Җырби дигән җирдә Салиха-биби һәм Ахут чокырында Гафифә Биби күмелгән.*

Вагай районының сазда урнашкан авылларына җәен самолёт белән генә барып була. Аусак, Пиек, Агытбаш, Олы күл авыллары Уват күле, ягъни Олы күл буена урнашкан. Олы күл чынлап та бик зур, аның озынлыгы да, киңлеге дә дистә километрларга сузылган. Дәрья дими ни дисең. Күл буенда урнашкан авылларның төп яшәү чыганагы да күл белән бәйле. Корылык булган җәйләрдә дә күл буенда, яңгыр сорап, корбан суялар.

Биредә кызыклы сүзләр дә язып куйдым.

*Табан* – карась.
*Албыга* – алабуга.
*Песнәк* – пескарь.
*Йелте* – алдан килгән атка бүләк.
*Тәтә* – бабай.
*Нәнә* – әби.

Аусак авылының авыл советы рәисе – Тимербулатов Тимергали Вахит улы. Биредә Тубыл балык заводы цехы да урнашкан. Бу цехның башлыгы – Абышев Булат Тусмөхәммәт улы. Бикчәнтәев Кармыш Калбай улы – бригадир.

Беренче информантым **Бухарин Әхмәтшәриф Усук (Хөснетдин) улы (**1934 елгы) Аусакта туган.

Әхмәтшәриф гармунда да уйный, җырлый да.

***Сәйнәп (Зәйнәп)***

*Тайлакта[1] гына урам – осын урам,*
*Сиңер[2] килгән айын айланган[3], айланган,*
*Сәйнәп матур бигрәк тә генә шайланган[4].*
*Теләп алайым[5] йәнеңнән атаңдан.*

**Сабиров Барсымөхәммәт Сабар улы** (1970 елгы) 7 яшьтән ятим калган. Сахалинга җибәргәннәр, илен сагынып «Кәшәмир чаршау» дигән җыр җырлаган.

**Абдуллин Бикмөхәммәт Абдулла улы** (1893 елгы) Картавылда (Одинарская) туган. Әти-әнисе Агытбашныкы. Әнисе – Казыйм бай кызы. Агытбаш белән Аусак арасы 25 км. Бикмөхәммәт абый бер «Борынгы җыр» җырлады. Бу якта «Зәйнәп», ягъни биредәгечә әйтсәк «Сәйнәп» җыры бик популяр, аны да җырлап күрсәтте. **Бухарина Бибифахидә (Бәйдус) Әхмәтгәрәй кызы** (1906 елгы) Омск өлкәсе Усть-Ишим районы Зур Тибенде авылында туып үскән. Ул «Йалтир-талалтир әйтеп киләләр» дип туй турында сөйләде. **Дәмимова Күләмдә Вахит кызы** (1928 елгы) авыл көен көйләде.

Бу якларда балага исем кушуның үз традицияләре бар. Ай башында туса – Айсылу; мәүлид аенда туса – Мәүлет, Мәүлия; сәфәр аенда туса – Сәфәр, Сәфәрбикә, Сәфәрия; шәгъбан аенда туса, Шаһбан дип исем кушалар. Гаиләдә бала тормаса, тимер яки таш компоненты кергән исем бирәләр – Таштимер, Миңтимер, Такташ, миңле булса – Миңсылу, Миңлебикә, Миңлекәй һ. б. Тугач та миң чыкса – Мөхәмметкалы, Калҗамал һ. б. дип исем алыштыру да бар.

---

[1] Тайлак – Иртеш буендагы авыл.
[2] Сиңер – мыс.
[3] Айланган – бормаланып утырган.
[4] Шайланган – бизәнгән.
[5] Теләп алу – сорап алу.

## ЙОМГАК

1967–1975 елларда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты Көнбатыш Себернең Омск, Томск, Новосибирск һәм Төмән өлкәләренә күпсанлы фәнни экспедицияләр оештырды.


Мин дә шушы еллар аралыгында Себер регионнарына оештырылган 9 экспедициядә булып, 5 өлкәдәге 12 районга караган татар авылларында 500 гә якын көй, җыр, бәетмөнәҗәт, дастан назымнары язып алдым. Себер татарларының җыр-көйләрен йөзләгән җырлаучы башкаруында магнитофон тасмасына яздырдык. Мин аларның һәрберсенә: «Сезнең бу җыр хәзинәгез киләчәктә радио-телевидение аша яңгыраячак, китапларга кертеләчәк», – дип ышандырдым. Мин үзем дә бу сүзләрнең хаклыгына нык инанып яшәдем. Әлбәттә, бу экспедиция вакытында язып алынган шактый җырлар мәшһүр җырчыларыбыз, җыр һәм бию ансамбльләре, Дәүләт фольклор ансамбле репертуарына керде. Шулай да, борынгы көйләребезнең күбесе озын-озак ярты гасыр көтеп ятты. «Сабыр төбе – сары алтын», дигән безнең бабайлар. Минем Себердә яшәгән милләттәшләребезнең музыкаль фольклорына багышланган мәкаләләрем фәнни җыентыкларда, вакытлы матбугат битләрендә дөнья күрсә дә, җыелган материалларны халыкка кайтару буенча эшчәнлек соңгы елларда гына башланды.

2018 елда музыка белгече Гөлназ Гыйлемҗанова шушы экспедиция вакытында язып алынган ике дистәдән артык көй-сарыннарны музыкаль диск итеп әзерләде.

2021 елда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Гыйльми советы карары белән «Татар

халкының туй җырлары. Себер ареалы» дигән ноталы җыентыгыбыз дөнья күрде. 2022 елда Илсөяр Закирова белән берлектә әзерләгән икенче китабыбыз – «Татар халкының музыкаль-эпик иҗаты. Себер ареалы» нәшер ителде. Бу җыентыкта татар халкының көй белән башкарыла торган эпик һәм лиро-эпик жанрлары турында бай мәгълүмат бирелә. Дастан иҗаты һәм аның башкарылу үзенчәлекләрен яктырткан мәкаләләр белән бергә дастан текстлары һәм аның сарыннары (ягъни көйләре) ноталар аша тәкъдим ителә. Бу ике китап та Фатих Ибраһим улы Урманченың укучысы, фольклорчы галим Илсөяр Закированың зур тырышлыгы һәм эчкерсез ярдәме белән басылып чыкты.

Менә сезнең кулыгызда өченче җыентыгыбыз. Бу китап башкалардан аерылып тора. Монда истәлекләр дә, экспедиция барышында аралашкан кешеләр турында мәгълүмат та, җыр-көйләр дә тупланды. Әмма бу китапның йөзек кашы 1968–1974 елларда язып алынган җырлар, шуларны башкаручыларның тере тавышы. QR-кодлар аша кереп шул вакытта язып алынган аудиоязмаларны тыңларга мөмкин. Бу китапны да



Халык музыкасы белгече Илгиз Кадыйров. 2025 ел

Илсөяр Гамил кызы Закирова белән Гөлназ Гыйльфан кызы Гыйлемҗанова әзерләделәр. Аларга рәхмәтем чиксез зур.

Сезнең игътибарга тәкъдим ителгән җыентык Себер киңлекләрендә яшәүче милләттәшләребезнең XX гасырның 60–70 нче елларындагы тормыш-көнкүрешен дә, рухи дөньясын да, музыкасын, җыр-көйләрен дә күзалларга мөмкинлек бирер дип ышанабыз. Шул ук вакытта моннан 50 еллар элек аралашкан кешеләр турындагы истәлекләр, аларның татар җырына мәхәббәте, тере тавышы балаларына, оныкларына зур истәлек, бүләк булыр, дигән теләктә калабыз.

Китапларымны дөньяга чыгаруда, Себер татарларының үзенчәлекле мирасын халыкка кайтаруда ярдәм иткән Ким Мөгаллим улы Миңнуллинга, Илгиз Илдар улы Халиковка, Олег Ришат улы Хисамовка олы рәхмәтемне җиткерәм.

*Милләтебез өчен зур эш башкаруыбызга сөенеп,*
*ихтирам белән Илгиз Кадыйров*

## ЭЧТӘЛЕК

**Сүз башы** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3

**БЕРЕНЧЕ ЭКСПЕДИЦИЯ**

ОМСК ӨЛКӘСЕ *(1968 елның 26 июне – 14 июле)* . . . . . . . 7

Ишем Тамак (Усть-Ишим) районы . . . . . . . . . . . . 7

Зур Тибенде авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7

Савыргач авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 22

Ихсиңер (Эбаргүл) авылы . . . . . . . . . . . . . . 37

Илчебага авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 43

**ИКЕНЧЕ ЭКСПЕДИЦИЯ**

НОВОСИБИРСК ӨЛКӘСЕ *(1968 елның сентябре)* . . . . . 52

Чаны районы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 52

Белекте авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 52

Кошкүл авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 61

Тармакүл авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 66

Куйбышев районы . . . . . . . . . . . . . . . . . . 81

Яргүл (Яркүл) авылы . . . . . . . . . . . . . . . . 81

**ӨЧЕНЧЕ ЭКСПЕДИЦИЯ**

ОМСК ӨЛКӘСЕ *(1969 елның 14 июне – 1 июле)*. . . . . . . 84

Большеречье районы. . . . . . . . . . . . . . . . . . 84

Үләнкүл авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 84

Тусказан авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87

Муромцево районы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 93
Юртбиргамак авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . 93
Чуртанлы авылы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 95
Инсәз авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 97

**ДҮРТЕНЧЕ ЭКСПЕДИЦИЯ**

ТОМСК ӨЛКӘСЕ *(1969 елның сентябре)* . . . . . . . . . . 102
Томск районы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 102
Абытай айыл . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 102
Кызылкаш авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . 109
Умавыл / Омайыл авылы . . . . . . . . . . . . . 117
Яүштә авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 122
КЕМЕРОВО ӨЛКӘСЕ *(1969 елның 26–27 сентябре)* . . . . 130
Юрга районы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 130
Кышлау авылы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 130

**БИШЕНЧЕ ЭКСПЕДИЦИЯ**

ТӨМӘН ӨЛКӘСЕ *(1970 елның 14–16 мае)* . . . . . . . . . 149
Ялутор районы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 149
Кашавыл . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 150
Рауды авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 159
Кактамак авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 165
Калмак яки Калмаклар авылы . . . . . . . . . . 169
Исәт авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 170
Сәел авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 175
Түбән Тәүде районы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 181
Киндер яки Киндерле авылы . . . . . . . . . . . 181
Балтан авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 187
Бохара авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 191

**АЛТЫНЧЫ ЭКСПЕДИЦИЯ**

ТӨМӘН ӨЛКӘСЕ *(1971 елның июле)* . . . . . . . . . . . . 194
Тубыл районы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 194
Лайтамак авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 194
Каргачи авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 214
Кызылбаево авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 214
Вагай районы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 217
Супра авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 217
Күләт авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 229

**ҖИДЕНЧЕ ЭКСПЕДИЦИЯ**

НОВОСИБИРСК ӨЛКӘСЕ *(1972 елның 23–28 мае)* . . . . 232
Куйбышев районы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 232
Шагыр авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 232

**СИГЕЗЕНЧЕ ЭКСПЕДИЦИЯ**

ТӨМӘН ӨЛКӘСЕ *(1973 елның 15–19 июле)* . . . . . . . . . 240
Тубыл районы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 240
Алга авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 240
Арткавыл (Ирек) авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 242
Ахманай авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 243
Тубылтура авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 244

**ТУГЫЗЫНЧЫ ЭКСПЕДИЦИЯ**

ТӨМӘН ӨЛКӘСЕ *(1974 ел)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . 247
Вагай районы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 247

**Йомгак** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 250

Научное издание

**Кадыров Ильгиз Шафикович**

**В МИРЕ НАРОДНОЙ МУЗЫКИ**
**Путевые заметки**

(На татарском языке)

Редактор *Л.Г. Шарифуллина*
Компьютерная верстка *Н.Т. Абдуллиной*
Дизайн обложки *Т.В. Семиной*

Подписано в печать 14.11.2025.
Бумага офсетная. Формат 60×84 1/16. Гарнитура «Таймс».
Усл.-печ. л. 14,9. Уч.-изд. л. 11. Тираж 500 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен в Институте языка, литературы
и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20